ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 8 (343)
АВГУСТ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

СӘЯХӘТЛӘР БУЕНЧА БЕРЕНЧЕ



4 612750 670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН:
БУ СИНЕҢ ВАТАНЫҢ, УЛЫМ!

Без хыяллана да алмаган нәрсә тормышка ашты бугай. Безнең балаларыбыз, смартфон-айфоннарга төбәлеп утырудан туеп, кинәт үзләрен әйләндереп алган тирә-якны күреп алдылар. Болын-тугайларны, диңгездәй елгаларны, чәчәкле җәйне. Пандемия тыюлары белән чикләнгән ата-аналар балаларына Татарстан буйлап сәяхәт бүләк иттеләр – чит ил җирләреннән матуррак, кызыклырак булып чыккан туган җирләр буйлап сәяхәт. Чыннан да үзеңнең гаджетларга береккән балаңнан «Кама диңгезе» күренешләренә, Лобач тавы мәгарәләренә, Балык Бистәсе маралларының кызыксынучан күзләренә карап, «Нинди матур!», «Шундый шәп!», «Нинди сөйкемлеләр!» дигән сокланулы сүзләрен ишетү рәхәт түгелмени? Һәм яшүсмер балаңның гаҗәпләнеп: «Ой, ә без кайда соң?» – дигән соравына: «Бу синең Ватаның, улым!» – дип җавап кайтару?

Сәяхәтләр буенча төп вазыйфаны үтәүче «Татарстан»ның әлеге саны Татарстан дип аталган Ватаныбыз буйлап сәяхәтләргә багышлана.

Сезнең патриот редакциягез.

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Катерина Котова, Алёна Кутыркина, Ксения Семина, Луиза Шарова
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Алёна Кутыркина фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1 150 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-2110
Басарга кул куелды: 13.08.2020
Басмадан чыкты: 19.08.2020

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 3500 данә
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә



ЭЧТӘЛЕК

6. Даһилар урыны
Пастернак үз романының төп героен кайда тапкан

10. Кыргый дөнья
Горур мараллар һәм нәфис боланнар арасында

14. Хайваннар дөньясында
Диңгез бөркетләре ВИП-резиденцияләрдә ничек оя корган

18. Аларның гореф-гадәтләре
Мегаполистан качучылар авылы турында

22. Көч урыннары
Кирмәнчек: борынгы ныгытма һәм рухлар

26. Маҗаралар эзләп
Мәчкәрәдәге борынгы ташлар ни сөйли

30. Шәһәрдә ике көн
Бөек рәссамга кунакка ничек барырга

36. Ашау, мин сине яратам!
«Изге Габдрахман» коесы янында Болгар музей-тыюлыгы директоры белән «Редакция кухнясы»

42. Әйдә барыйк, ашап карыйк!
Сөнчәле: чуваш кухнясы рецептлары

46. Минем арттан ияр!
Байлар Сабасында нинди хәзинәләргә юлыктык

52. Онлайн бәйрәмнәр һәм онлайн күңел ачулар турында
Чикләүләр чорында заманадан ничек артта калмаска

64. Тарих битләре
Ризаэтдин Фәхретдин: чорларны тоташтырган гыйлем иясе

68. Тормыш линиясе
Бездә кунакта – Ркаил Зәйдулла

72. Китап киштәсендә
Вакыт безнекеме, без вакытныкымы?

82. Татар авыллары
Борынгы Әтрәч

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

9.07

Михаил Мишустин, Россия Федерациясе Хөкүмәте рәисе, – Иннополиста Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашу вакытында:

– Илнең барлык төбәкләрендә, шул исәптән Татарстанда да вазгыять җиңел булмады. Әмма сез бүген пандемия белән бәйле катлаулы вазгыятьтә республиканың ничек эшли белүен күрсәттегез. Казанда Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсенең яңа корпусы 72 көндә төзелде. Бу – бүгенге шартларда, барлык технологияләр һәм инновацияләрне туплап, кешеләргә ярдәм итүнең иң мөһим мәсьәлә буларак хәл ителүенә ачык мисал. Минемчә, бу ил күләмендә үрнәк итеп таратылырга лаек проект.

18.07

Виктор Потуремский, ИНСОМАР социаль маркетинг институтының сәяси анализ буенча директоры, – «Волга» экспертлар клубы утырышында:

– Кешеләргә хакимият белән даими турыдан-туры аралашу кирәк. Һәм монда төп мәсьәлә – ышаныч. Әгәр кешеләрнең хакимияткә ышанычы булмаса, иң камил эшләнгән платформа да файдасыз булачак. Татарстанда хакимият һәм халык арасындагы коммуникация тәҗрибәсе илдә иң алдынгылардан санала. Кешеләр моны күрәләр һәм хакимиятнең үзләрен алдамавына ышаналар.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

9.07

Дмитрий ЧЕРНЫШЕНКО, РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – Казанда:

– Көзгә Ростуризм эчке туризмны үстерүнең милли программасы буенча тәкъдимнәр кертергә тиеш. Хәзерге вакытта Сочида һәм Татарстанда туристик продуктлар һәм сервислар булдыруның күркәм тәҗрибәсе бар. Бу тәҗрибә киң күләмдә таратылачак, шуңа күрә туризм өлкәсендә яңа милли проект эшләү турында күрсәтмәләр бар.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

23.07

Игорь Комаров, РФ Президентының И(б)ФО буенча вәкаләтле вәкиле, – Казанда, иҗтимагый киңлекләрнең сыйфат дәрәҗәсен бәяләп:

– Без республикада уңайлы шәһәр мохитенә зур игътибар бирелүен күрәбез. Без биредә үзебезне табигатьтәге кебек хис итәбез. Бер уйласаң, әллә ни катлаулы булмаган һәм бар кешегә дә аңлаешлы эшләр башкарыла, әмма алар халык өчен бөтенләй башка шартлар тудыра. Бүген безнең күргәннәребез, әлбәттә, тәэсирләндерә. Минемчә, бу тәҗрибәне Идел буе федераль округының башка төбәкләренә дә, гомумән бөтен Россия күләмендә өлге итеп алырга кирәк.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

27.07

Алсу, җырчы, – үзенең Instagram аккаунтында, Казан буенча виртуаль сәяхәтенә анонс ясап:

– Кадерле дуслар, мин нинди дә булса өр-яңа берәр нәрсә эшләп карарга булдым. Шуның өчен мин сезне 28 июльдә #TikTokka чакырам... һәм без сезнең белән искиткеч матур, минем йөрәгемә якын Казан шәһәре буйлап мавыктыргыч сәяхәткә кузгалырбыз, виртуаль сәяхәткә, әлбәттә...

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

10.07

Сергей Иванов, ТР Дәүләт комитетының туризм буенча рәисе, – Казанда, «Волга от истока до устья с высоты птичьего полета» фотокүргәзмәсе ачылышында:

– Идел елгасы – илебезнең транспорт артериясе генә түгел, төбәкләрне, мәдәниятләрне берләштереп торучы элемтә дә. Ул – вакыт сакчысы. «Бөек Идел юлы» проекты һәм бүгенге күргәзмә тагын бер тапкыр туган ягыбызның нинди гүзәл булуын күрсәтеп тора.

PRESSA

махсус проект

«ТАТАРСТАН»: СӘЯХӘТЛӘР БУЕНЧА БЕРЕНЧЕ,

яки

БЕР БАСМАДА 1001 ТУРИСТЛЫК ЛӘЗЗӘТЕ

Сәяхәтләргә багышланган күпме тапшыру җир йөзендәге гүзәллекләрне күрсәтер өчен сәяхәтчеләрне... телевизор экраннарына чакыра. Ләкин телевизион сәяхәтләр бөтен дөнья яшеллеккә күмелгән, чәчәккә төренгән җылы, якты җәй айларында алай ук кызык тоелмый. Туган як буйлап сәяхәтнең чит илләргә сәфәргә чыгудан бер дә калышмавын күргәндә бигрәк тә...

«Татарстан», телевизион сәяхәтләрне җирле шартларга яраклаштырып, сезне республикабыз буйлап сәфәр чыгарга өнди...

1 *Даһилар урыны*
ЧИСТАЙ:
НОБЕЛЬ ЛАУРЕАТЛАРЫ КУЛЪЯЗМАЛАРЫН КАЙДА ЯККАН

2 *Кыргый дөнья*
БАЛЫК БИСТӘСЕ:
НӘФИС БОЛАННАР ҺӘМ БАЛЫКБУРГЕРЛАР ДӨНЬЯСЫ

3 *Хайваннар дөньясында*
ИДЕЛ-КАМА ТЫЮЛЫГЫ:
ДИҢГЕЗ БӨРКЕТЛӘРЕ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ВИП-ОЯЛАРЫ

4 *Аларның гореф-гадәтләре*
АНТОНОВКА:
МЕГАПОЛИСТАН КАЧУЧЫЛАР АВЫЛЫ ТУРЫНДА

5 *Көч урыннары*
КИРМӘНЧЕК:
БОРЫНГЫ НЫГЫТМА ҺӘМ ҮЛЕМ ЮЛЫ. РУХЛАР НИ ТУРЫДА СӨЙЛИ...

6 *Маҗаралар эзләп*
МӘЧКӘРӘ:
ҖАН ХАЛӘТЕ, ГАЛӘМ ҺӘМ СЕРИАЛЛАР ТУРЫНДА

7 *Шәһәрдә ике көн*
АЛАБУГА:
СӘҮДӘГӘРЛӘРЧӘ ЧӘЙ ТАБЫНЫ

8 *Ашау, мин сине яратам!*
БОЛГАР:
«ИЗГЕ ГАБДРАХМАН» КОЕСЫ ЯНЫНДА «ТАТАРСТАН» РЕДАКЦИЯСЕ КУХНЯСЫ

9 *Әйдә барыйк, ашап карыйк!*
СӨНЧӘЛЕ:
ЧУВАШ КУХНЯСЫ РЕЦЕПТЛАРЫ

10 *Минем арттан ияр!*
БАЙЛАР САБАСЫ:
ТАТАРСТАННЫҢ БАРЛЫК АККАУНТЛАРЫНДА

Фото: Алексей Ушаков





ПАСТЕРНАКЧА КВЕСТ

Автор: Ольга Туманская

1958 елның 29 октябре. Нобель комитеты сәер телеграмма ала. Анда – әдәбият өлкәсендәге премиядән баш тарту. Телеграмманы җибәрүче – Борис Пастернак.

1960 елның 16 августы. Шагыйрь тормышындагы төп роман өчен чит ил гонорарларының бер өлешен васыять иткән Ольга Ивинскаяның йортында чекистлар эшли. Киләчәктә аны дүрт елга сузылган төзәтү колониясе көтә.

2001 елның 7 ноябре. Россия шоу-бизнесында истәлекле көн – Алла Пугачева беренче тапкыр үзенең «Свеча горела» хитын башкара.

Бу тарихларның барысы да даһи Борис Пастернакның урыны дип атарга мөмкин Чистай белән турыдан-туры бәйләнгән.

ШАГЫЙРЬНЕҢ ЧИСТАЙДАГЫ «БАЙЛЫКЛАРЫ»

Скарятин бакчасында йөрү, бигрәк тә эссе көндә – үзе бер рәхәт. Ә инде капкадан чыгып, һичкая борылмыйча, сукмак буйлап туп-туры барсаң, сине Борис Леонидович каршы алачак. Әлбәттә, үзе түгел, ә аның өч метрлы сыны. Хәер, минем игътибарымны ул түгел, ә сынның аргы ягында җәелеп үскән бер гасырлык нарат җәлеп итә. Чыннан да атаклы аклы-каралы фотодагы теге агач инде әллә?

1943 елның кышында төшкән фотографиядә Пастернак нәкъ шушы урында басып тора. Агачка җиңелчә сөялеп, каядыр еракка карый.

– Пастернак! Пастернак! – дип ерактан кычкыра аңа малайлар. Тиктормас бала-чага «Пастернак» сүзен кызыклы кушамат дип уйлаган. Ә ул, аларга җавап итеп елмая да, янә үз уйларына чума. Күптән көтелгән җиңүдән соң, дәреслекне яшереп, искечә язу мөмкин булмаячагы турында уйлана. Биредә, Чулман буендагы матур гына кечкенә шәһәрдә, аңарда бу ышаныч көннән-көн ныгый бара. Әйе, шагыйрьнең үзе әйтүенчә, аны сугыш һәм Шекспир үзгәртә. Ә болар барысы да Чистай белән бәйле бит!

«Боренька Пастернак, элекке кебек сәер һәм авыз эчендә ботка пешерүче Пастернак, «Ромео һәм Джульетта» тәрҗемәсен тәмамлаган, тыңлаганда һәркемнең күзенә яшь килде – шундый яхшы килеп чыккан!» – дип яза язучы Константин Федин драматург Всеволод Ивановка. Сүз уңаеннан, Борис Леонидович Европадагы бөтен телләрне камил белә: өстәвенә, хәзерге заман теленнән түгел, XVI гасырдагы телдән тәрҗемә итә. Моны менә дигән итеп башкара, бу өлкәдә илнең иң яхшы белгечләренең берсе буларак таныла. Пастернакның үзен бастырмый башлагач, нәкъ менә тәрҗемәләр аңа исән калырга мөмкинлек бирә: «Антоний һәм Клеопатра», «Ромео һәм Джульетта»... – болар дәүләт заказы була. Бу исә икенче фронтны ачарга җыену белән бәйле, сугышка Англия кирәргә тиеш. Бу ил белән революциядән соң югалган элемтәләрне торгызырга кирәк. «Ромео һәм Джульетта» әсәренең атаклы тәрҗемәсе, аның чиста варианты 1942 елның 26 февралендә әзер була. Федин аны шул ук кичтә ишетәчәк – шәһәрдәге Укытучылар йорты залында текстны Пастернак үзе укый. Нәкъ шул вакытта электр станциясендә авария килеп чыга һәм ут сүнә. Уку ике

керосин лампасы яктылыгында дәвам итә. Бу чыгыш өчен җыелган барлык акчалар Кызыл Армия сугышчыларына бүләкләр өчен тотыла.

Сүз уңаеннан, Нобель премиясе лауреатының акчага һәм төрле уңайлылыкларга беркайчан да исе китми. Пастернак музее хезмәткәрләре 1990 нчы елларда Чистайга экскурсиягә Санкт-Петербургтан бер кеше килгәнен искә төшерде. Сугыш вакытында әле бала гына булганлыгын, шушында эвакуациядә яшәгәне турында сөйләгән ул кунак.

– Пастернак бик бай кеше иде! – дигән ул. – Мин аның белән еш кына колонкага чират торуыбызны хәтерлим. Беләсезме, ул һәрвакыт шундый матур киенгән була иде!

– Мин хәзер сезнең күңелегезне төшерермен, ахры, – дип елмая шулчак музей мөдире Людмила Демченко. – Эш шунда ки, Борис Леонидович Чистайга бердәнбер костюмын киеп килгән. Шуны киеп суга да барган, язучылар алдында да чыгыш ясаган...

Бу шәһәрдә эвакуациядә уздырылган ике ел аның бар җанын айкап чыгачак, биредә ул эчке ирекгә ия булачак – Мәскәүгә Пастернак башка кеше булып әйләнеп кайтачак. Ә Чистайдан шигырьләр һәм матур тәрҗемәләрдән кала, ни алып китә соң ул? Иң мөһиме – «Доктор Живаго» романы өчен фикерләрен, караламаларын, геройларының прототипларын.

ВАКЫТ ТУКТАГАН ҖИРДӘ

1941 елның 18 октябре. Пастернак Чистайга иң соңгы төркем язучылар белән эвакуациягә килә. Биредә аны якыннары – хатыны Зинаида һәм балалары көтә. Борис Леонидовичка Вавиловлар йортындагы кечкенә генә бүлмәдә яшәп тору насыйп була. Бүген бу йортка эләксәң, анда вакытның туктап калганын тоярга мөмкин.

Менә ул, Ленин урамындагы 81 нче йорт. Икенче катта почмак яктагы ике тәрәзәнең берсе – шәһәр бакчасына, икенчесе «ромашкалар үскән халык суды ишегалдына» карый. «Бу ишегалдына еш кына төркем-төркем белән, чит шәһәрләрдән мондагы төрмәгә эвакуацияләнгән, йончыган тоткыннарны алып киләләр, монда яшәүчеләрнең берәрсен хөкем иткәндә шәрран ярып кычкыралар». Бүген монда – Пастернак музее, анда әйберләр, җиһазлар гына түгел, шул чор һавасы да саклана кебек.

Пастернакка бәхет елмаймаган да шикелле: якты, ә иң мөһиме – йорт җиһазлары булган бүлмәдә яшәп тору язучыга очраклы рәвештә генә тәти. Чынлыкта – хуҗалыкны утын белән тәэмин итүдә катнашырга вәгъдә биргән өчен генә. Ымсындыргыч тәкъдим, әмма асылда утын табу бик авыр була ул вакытта. «Мин баржадан өч көн утын бушаттым һәм шул зур бүрәнәләрне, күтәреп, тайгак ярга ничек чыгара алуымны хәзер үзем дә аңламыйм», – дип искә ала ул көннәрне Пастернак. Сүз уңаеннан, ул искиткеч матур тәрҗемәләр ясаган һәм әсәрләр язган арада да, берниди эштән куркып тормый. Шул ук вакытта авыр физик хезмәт аның көннәрен берничек тә ямьсезләндерә алмый.

«Мин төрле хәлдә яшәдем, әмма гомумән алганда, бәхетле гомер кичердем. Бәхетле диюем шул мәгънәдә, мин көнкүреш мәшәкатьләре, үзгәрешләр алдында югалып калмаска тырыштым (тьфү-тьфү, күз тимәсен) һәм гадәти хезмәттә, фикер саулыгында, крестьян абзарында булса да, чисталыкта кышладым, – дип яза ул үзенең Чистай тормышы турында. – Бу яктан мине бернәрсә дә туктатмады... Кирәк икән, бәдрәфен дә чистарттым, чабып алып, берничә чана адәм тизәген дә түктем. Мин монда көн саен кырынам, көн буе кара бәйрәм костюмында йөрим. Әйтерсең, болар барысы да төшемдә, һәм мин хәзер, менә шушында боларның барысын да төбенә кадәр йотып куйганмын да, каядыр Парк-Таунда утырам кебек иде». Менәтерә сезгә «бай кеше»!

Аның бу йорттагы соңгы фотосурәте 1943 елның җәендә төшерелә. Авторы – доктор Живагоның прототибы булачак табиб Авдеевның улы Валерий Авдеев. Җитмеш елдан артык вакыт узгач та, бу бүлмәдә һәрнәрсә элеккечә диярлек. Өстәлдә – теге вакыттагы кара савыты һәм каләм. Стеналарга да шул ук карлыгачлар «кунган».

Ышкылган, таушалган кушетка урынында баштарак тагын бер карават торган. Анысы – Пастернакның хатыны өчен. Тик Зинаида Николаевна эш урынында яшәргә ярата – Литфонд интернатында аңа балалар белән рәхәтрәк тә, тамагы да туграк. Фатир хуҗасының кызы Лидия искә алганча, Борис Леонидович янына кунаклар килгәч, алар нигәдер караватка утырмый, ә янәшә басып тора. Лидиягә бу хәл сәер тоела, чөнки

Пастернак эш вакытында. Чистай, 1943 елның 25 июне.

Пастернак музее.

арт якны караваткa терәп була бит, ләкин Мәскәү зыялылары үз дәрәҗәләрен төшерми. Шулай итеп, кушетка барлыкка килә.

Пастернак үзе исә караңгы кышкы кичләрне аш бүлмәсендәге самавыр янында уздырырга ярата. Фатир хуҗасы Василий Вавилов белән гәпләшкәннән соң, Гражданнар сугышы турында аның үз фикерләре барлыкка килә. Пастернакны партизан көнкүрешенең нечкәлекләре кызыксындыра, ә Вавилов яшь чагында кызыллар ягында сугышкан була. Ул гына да түгел, хәтта аңа бервакыт легендар партизан башлыгы Иннокентий Кожевников отрядында да сугышырга туры килә. Әлеге кичке әңгәмәләрдән туган хис-кичерешләрне «Доктор Живаго» романы сәхифәләрендә таба алабыз, анда баш герой ирексездән партизан отрядына эләгә.

Вавиловның хатыны бу әңгәмәләрне хуплап бетерми. Бигрәк тә аклар генералы Молчановка кагылышлыларын. «Ә җиткерсә, донос язса?» – дип пышылдый ул иренә һәр әңгәмәдән соң. Тик Василий Андреевич аңа: «Каршымда намуслы кеше икәнен күрәм мин», – дип кенә җавап бирә торган була.

Сүз уңаеннан, донослардан курку бу йортны әле берничә тапкыр биләп алачак. Ә бервакыт Пастернакның үзенә дә кагылачак. Нәкъ менә биредә Борис Леонидович үзенең «Этот свет» дип исемләнгән «заманча реалистик пьеса»сын яза. «Шигырьләр кебек иректә рухта, үзем өчен генә» дип язылa ул. Тик исеме үк якты бу әсәргә якты дөньяга чыгу насыйп булмый. Кульъязма Зинаида Николаевнаның үгет-киңәшләре белән мичкә озатыла. Бу хәл СССР Язучылар берлеге сәркатибе, «әдәбият генералы» Александр Фадеев килеп киткәннән соң була.

Ул Чистайга туганнарының хәлен белергә килә, бер уңайдан тылдагы язучыларны да «күреп» чыгарга җыена. Александр Фадеев Борис Леонидович янына да керә. Кадерле кунакны шәхсән үзе сәламләү өчен, Зинаида Александровна эштән сорап китә. Менә шул чакта, аның кишер, җиләк һәм гөлҗимешләрдән ясалган атаклы чәе белән сыйланганда, Фадеев әйтеп куя: «Борис, син дөрес пьесалар сайламыйсың! Ә берәрсе белеп алса һәм тиешле урынга хәбәр итсә?!»

Аның артыннан ишек ябылуга ук, куркыныч әсәреңнән котылыйк дип, Зинаида Пастернак иренә ялына башлый. Һәм ул котыла да, тик аның турында «Доктор Живаго»ны яза башлагач, һичшиксез, искә төшерәчәк әле.

Асеев Н.Н., Сельвинский И.Л., Пастернак Б.Л. Чистай, 1942 ел.

«АВДЕЕВ САЛОНЫ КӨННӘРЕНДӘ»

Карл Маркс урамындагы 76 нчы йорт. Бүген ул буш тора, кешеләр күчереп бетерелгән, тик бәхеткә, киләчәктә реставрацияләү өчен, ышанычлы рәвештә ябып куелган. Моңсу күзләр урынына караңгы тәрәзәләрен төбәп утырган зур зәңгәр китны хәтерләтә бина... Һай, нинди иҗади тормыш кайнап торган монда! Теге дәһшәтле сугыш елларында...

«Бергә җыелган көннәрдә язучылар анда пироглар һәм яшелчә ише белән сыйлана иде. Ләкин Авдеев янына, әлбәттә, шәпләп ашап алу мөмкинлеге генә җәлеп итми. Аларның барысын да бу йорт үзенә мәдәни үзәк буларак тартып тора. Анда шигырь укыйлар, әдәбият, сәнгать турында сөйләшәләр, бәхәсләшәләр. Анда килгәч, миңа кайчагында бу Чистай түгел, ә Мәскәү булып тоела иде», – дип искә ала бу йорт турында Зинаида Пастернак. Монда яшәгән Авдеевлар югары культуралы кешеләр була һәм Чулман буе шәһәренә эвакуацияләнгән барлык язучы гавамының күңелләрен яулап ала белә. Берәүләр аларның өен Мәскәү язучылар клубы филиалы, икенчеләре – әдәби салон, өченчеләре «клуб диярлек урын» дип атый.

Ә менә болары Пастернак үзе язган юллар: «Я вспомню длинный стол и залу, где в мягких креслах у конца таланты братьев завершала усмешка умного отца. И дни авдеевских салонов, где, лучшие среди живых, читали Федин и Леонов, Тренев, Асеев, Петровых». Борис Леонидович, башкалар кебек үк, сугыш

Авдеев Д.Д.



Авдеев йорты.

Иске сәүдәгәр йорты сакланып калган. Бүген анда Чистайның Үзәк китапханәсе урнашкан.



Литфонд интернаты бинасы. Ленин урамы. 1947 ел.

рухы барыннан да азрак тоелган бу йортка тартыла. Бертуганнарның берсе – галим-биолог Валерий, һәм аның әтисе Дмитрий Дмитриевич белән дуслыкны ул озак елларга саклап кала. Өстәвенә, Пастернак аларның образларын романның төп герое – Юрий Живагода берләштерә.

– Дмитрий Дмитриевич гади өяз табибы гына булмый, аның даны Казанга да барып җитә, – дип сөйли музейның өлкән фәнни хезмәткәре Рафаил Хисамов. – Аның әтисе, икенче гильдия сәүдәгәре, улы сайлаган һөнәрне хупламый, шуңа күрә Авдеев үз карьерасын туган шәһәре Чистайда түгел, ә Изгары авылында башлый. Анда ул Чистай районының беренче зур хастаханәсен оештыра. Клиника 90 нчы елларга кадәр эшли, аны аннары гына ябалар. Оптимальләштерү галәмәтләре!

Нәкъ менә акларны да, кызылларны да дәвалаган чын табиб – Дмитрий Дмитриевич үрнәгенә иярә Юрий Живаго. «Тимәгез, ул безнең өчен әүлия кебек!» – ди халык, үз вакытында Авдеевны сәяси караңгылык өчен стенага тери язган аклардан яклаганда. Хәер, табибның кызыллар белән дә шундый ук кыенлыклары килеп чыга – могҗиза белән генә атылмый кала. Дөресме-түгелме, Авдеевны пулядан кайчандыр үзен сифилистан дәвалаган югары дәрәҗәле НКВД табибы коткарган, диләр.

– Борис Леонидович белән аралашып йөргән кешеләрне барласак, язучыларны, актерларны, музыкантларны, рәссамнарны табарга була, әмма табибларны түгел, – дип сөйли Людмила Демченко. – Пастернак шактый нык, сәламәт кеше була. Бары тик биредә, Чистайда гына, ул табиблар белән якыннан аралаша.

Үзенең атаклы романын Пастернак ун ел әзерли. Билгеле булганча, ул бик озак кына аңа исем таба алмаган. Дмитрий Авдеевтан хат алганчыга кадәр. Һәм менә Борис Леонидовичның күзе хаттагы имзага төшә: «Искренне расположенный к вам, доктор Авдеев», һәм ул, күптән борчып йөргән табышмакны чишкәндәй, зур хәрефләр белән «Доктор Живаго», – дип язып куя.

КЫШКЫ КИЧЛӘРНЕҢ БЕРСЕНДӘ...

1943 елның февраль кичендә Чистай караңгылыкка чума – бөтен шәһәрдә ут сүнә. Әлбәттә, сугыш вакытында бу – сирәк күренеш түгел. Шулай да ул гаҗәеп кич була һәм күпләрнең хәтеренә уелып кала. Литфонд интернатында яшәүчеләр – аның хезмәткәрләре һәм фронтка киткән язучыларның балалары холлдагы рояль янына җыела. Барысы да музыка тыңлый, ә аннары актриса Людмила Кайранская «Анна Каренина»ны укый башлый. Шулчак салкын һәм буранлы урамнан Пастернак килеп керә.

– Бөтен җирдәге кебек, безнең өйдә дә ут юк, – ди ул, көйне тыңлап бетереп, Кайранскаяның кулын үпкәч. – Лампададагы керосин төкәнде, шәм дә янып бетте. Зинаида Николаевнадан запаста берәр яктылык бирерлек нәрсә юкмы, дип сорарга килгән идем.

Шунда ук аннан берәр нәрсә укуын сорый башлыйлар. Әмма Пастернак кыенсынып кына елмаеп, үз шигырьләрен яттан хәтердә калдырмавын белдерә. Хәер, берсе бар – әле яңа гына, шәм янып беткәндә язылганы. Һәм кесәсеннән язылып-сызылып беткән кәгазь бите чыгара. Халык күңелен яулаячак атаклы юллар була ул! «Мело, мело по всей земле, во все пределы. Свеча горела на столе, свеча горела…»

– Барысы да тып-тын калды – бу унике кыска гына шигырь юлына безне шул мизгелдә чолгап алган бөтен нәрсә сыйган иде! – дип соңыннан искә алачак танылган язучы-тәрҗемәченең кызы Изабелла Шамбадал. – Еллар уза торды. Мин, ниһаять, «Доктор Живаго»ны укып чыктым, һәм ул кич барлык нечкәлекләре белән хәтердә яңарды…

Атаклы «Кышкы төн» шигырен Пастернак доктор Живагога гына түгел, Ольга Ивинскаяга да бүләк итәчәк. Шагыйрьнең соңгы мәхәббәте, бу юллар сугыштан соң язылды һәм миңа багышланган иде, дип белдерәчәк. Әмма ул кичәнең шаһитлары, «Кышкы төн» астында 1946 ел дип куелса да, ул исемсез һәм калган биш строфасыз килеш 1942 нең февраль кичендә Чистайда туды, дип саный…

Әлеге вакыйга булган иске сәүдәгәр йорты сакланып калган. Вакыт җилләре аны әллә ни үзгәртмәгән диярлек. Бүген анда Чистай үзәк китапханәсе урнашкан. Аның холлда еш кына Пастернакның үги малае – киләчәктә танылачак пианист Станислав Нейгауз утырган һәм атаклы шигырьнең премьерасына шаһит булган ул рояль тора микән? Анысын белмим. Тик, әгәр сез дәһи Пастернак узган юлларга сәяхәткә чыксагыз, кереп тикшереп чыкмый калмагыз… T

2

КЫРГЫЙ ДӨНЬЯ

БАЛЫК БИСТӘСЕ

ЧУРТАН КУШУЫ БУЕНЧА БУРГЕР

Автор: Ксения Сёмина

Балык Бистәсе «Ял көннәрендә 1001 ләззәт» республика проектына керде. Без дә шул тарафларга юл тоттык.

Автор фотолары

– Иң беренче күмәч кисәген алабыз һәм аны кытырдап торырлык итеп кыздырабыз... Үзебезнең тозлы кыярлы махсус соусыбызны өстибез. Кәтлитне (ул чуртан итеннән), салат яфрагын (ул үз бакчабызда үскән) куябыз, тагын соус агызабыз, аннан соң маринадланган суган, түгәрәкләп киселгән помидор кисәге, тозлы кыяр тезәбез, сыр өстибез. Икенче күмәч кисәге белән каплыйбыз. Мичкә озатабыз – һәм балыкбургерыбыз әзер! – Олеся Караганова чит ил челтәр фастфудлары хитларының Балык Бистәсендәге көндәшен ясау буенча экспресс мастер-класс күрсәтә.

Ашап карыйбыз һәм чыннан да телеңне йотарлык тәмле: бернәрсә дә эшлисе килми, Олеся ясаган балыкбургерларны ашый-ашый, биредә, Балык Бистәсе яр буенда, Чулман елгасына карап хозурланып утыру теләге генә кала. Әмма шундый гади нәрсәләрдән мондый тәмле сыйны ничек әзерләп булганлыгын белү ихтыяҗы көчлерәк булып чыга.

РӘХМӘТ – БАЛЫККА

Балыкбургер, танылган кулинария ризыкларына хас булганча, шактый бай һәм кызыклы тарихка ия икән. Әгәр Олеся балыкчылар династиясенең дәвамчысы булмаса, ул бөтенләй дөньяда булмас иде. Олесяның әтисе – Юрий Караганов гомере буе җирле балык заводында эшләгән, бистәдә беренчеләрдән булып балык ыслый башлаган. Олесяның иң беренче һәм иң истә калган хатирәләреннән берсе әти-әниләренә булышу турында. Балык ыслауда катнашасы килгән балалар олыларны эш сорап интектерәләр. Ниһаять, мондый мөмкинчелек туа: аларга балык кидертелгән тимер таякларны ташырга кушалар. Балалар тырыша-тырыша эшли, тик олылар гына рәхәтләнеп көлә. Чөнки ярдәмчеләрнең буйлары метрдан аз гына югарырак, шуңа да балыкларының койрыклары җирдән сөйрәлә.

ХИКМӘТ – СОУСТА

2000 нче еллар башында Карагановлар үзләренең кафеларын ачалар. Менюда төп урынны, әлбәттә, балыкка бирәләр, өстәвенә, җирле балыкка. Чулманда хәзерге вакытта 15 төрле балыкны тотарга ярый, шул исәптән корбан балыгын, алабуга, кәрәкә, җәен, сула балыгын. Күп ашый торган һәм ләмләнгән суда да исән калырга әзер кисәүбаш балыклар пәйда булды. Әмма гадәти блюдоларга халыкның кызыксынуы акрынлап суына. Берничә ел элек Олеся туристлык юнәлешен үстерү белән шөгыльләнергә карар кыла. Кафе өчен нindидер яңалык уйлап табарга кирәк була.

– «Чуртан» сүзен ишетүгә, беренче булып, башка кәтлит килә, тәмле, сусыл! Һәм без бу кәтлитләрдән балыкбургер әчлегә ясарга булдык. Әмма ул сәяхәтчеләргә инде яхшы таныш булган кәтлитләрдән аерылып торырга тиеш. Мондый ризык, мәсәлән, Төркиядә бар. Әлеге кәтлитләрне тагын да тәмлерәк итәр өчен, соус уйлап табарга булдык, – дип сөйли Олеся.

Соусны уйлап табу өчен күпмедер вакыт таләп ителә. Карагановлар бөтен гаиләләре, кода-кодагыйлары белән бергә 6 ингредиенттан торган рецепт уйлап табалар. Нинди ингредиентлар – әйтмибез, фирма сере булып калсын, диләр. Бер нәрсәне генә атадылар – тозлы кыяр. Ул соусның бизәге генә түгел, бәлки, балыкка мәдхиянең бер өлеше дә.

Сырдан кала, барлык башка ингредиентларны Олеся үз бакчасында үстерә. Мөгаен, эпидемиягә каршы тыюлар бетерелгәннән соң һәм туристлык сезоны тулысынча ачылгач, әлеге тәмләткечләрне утырту мәйданнарын киңәйтергә кирәк булыр. Соус һәм балык кәтлитләренең искиткеч тәэсиренә бирешмәгәннәр өчен, Карагановлар балык ите белән ясалган чебурекилар әзерлиләр.

Тик барыбер безне балыкбургерлар әсир итте, алып кайтыр өчен без чебурекилар түгел, балыкбургерларны алабыз. Аларның һәрберсенә район гербы ясалган флаг беркетелгән. Ачык зәңгәр фонда – ак ятьмә, аның эчендә алтын кырпы балыгы. Ләкин минем никтер моны уңыш китерә торган чуртан дип әйтәсем килә.

90 нчы елларда, кризислардан һәм башка авырлыклардан курыкмыйча, әти-әниләре Чулманда балык тотар өчен лицензия алалар.

– Монда күпләр иртә таңнан яр буена балык тотарга чыгып утыра. Ә эти су коенырга бара. Ул суга керә генә, балык чиертә башлый. Чынлап, шаяртмыйм, – ди Олеся. – Ул гомере буе безгә балыкны тотарга гына түгел, аңа рәхмәт тә әйтә белергә кирәк, дип өйрәтте. Бездә, мәсәлән, шундый традиция бар, язын һәм көзен яр буйларын чүп-чардан чистартабыз.

Карагановларның балык тоту заводында 25 кеше эшли. Бер елда 200 тоннага якын балык тотыла, аны Мамадыштан Саескан Тавына кадәрге территориядә тоталар. Балыкның бер өлеше Карагановлар оештырган производствода эшкәртелә. Алар каклаган, пычкы чүбендә салкын ысул белән ыслаган, кайнар ысул белән ыслаган балыклар – Балык Бистәсенең фишкасы. Судак ите, чистартылган корбан балыгы ваклап сатуга китә. Чи итнең бер өлеше Казанга, Самарага, Ульяновскига, Ростов-на-Донуга озатыла.

– Әле күптән түгел генә республика буенча 16 балык тоту предприятиесе эшли дип санала иде, бүген исә 8 генә калды. Бик үҗәтләре генә исән кала. Балыкчы хезмәте – бик авыр. Кышын көне буе салкында һәм җилдә эшлисең, җәен – эсседә. Бу һөнәр бездә күбрәк буыннан буынга күчә. Безнең үзебезгә дә, вак җитештерүчеләр буларак, бик кыенга туры килә. Төрле инстанцияләрнең таләпләрен үтәргә кирәк, ә елга балыгының бәясе, диңгезнекенә караганда, күпкә арзанрак. Бер сүз белән әйткәндә, кул кушырып утырып торып булмый. Ә бит үсәсе, алга атлыйсы да килә! – ди Олеся.

НӘФИС БОЛАННАР ТАУ АРТЫНДА ТҮГЕЛ

Алтай таулары кыяларындагы петроглифлар арасында ау күренешләрен сурәтләгән рәсемнәр очрый. Аларның күпчелегендә болан мөгезләре өстендә – кояш билгесе, яңарыш, мәңгелек тормыш символы. Мондый кояш Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Шомбыт авылы янында да чыкты.

– Бэмби! Бэмбины күрәсем килә! – дип шыңшый безнең алда атлаучы алты яшьләр тирәсендәге кыз. Ул әнисенең кулыннан тарта, тик тегесе һич ашыгырга уйламый, дусты белән сөйләшүен дәвам итә. Безнең арттан тагын бер төркем балалар һәм олылар килә. Без барыбыз да июльнең бер эссе көнендә вак таш җәелгән сукмактан чыршы-нарат урманы буйлап ашыкмыйча гына атлыйбыз. Навигаторга караганда, Бэмби янына барып җитәргә бер чакрым тирәсе юл калган. Шомбыттан «Кыргый ферма»га кадәрге әлеге юлны менә-менә салып бетерергә тиешләр. Аннан соң боланнарга кадәр автомобильдә дә барырга мөмкин булачак. Ләкин миңа урман сукмагы бераз кызганыч: озаграк атлаган саен, үлән һәм агачларның шаулавы рәхәтрәк, җылы агач кайрысының хуш исе көчлерәк тоела, без кыскалык өчен табигать дип атаган мохит якынрак була бара.

Без зур кырны үтәбез һәм тимерчыбык белән тотылган биек койма янына килеп чыгабыз Аның артында – печән чүмәләләре өелгән, чыршылар һәм кечерәк кенә нарат агачлары утыртылган бик зур территория. Эчтә бернинди хәрәкәт юк, инде алга таба атларга ниятләдек кенә, кинәт мин койма артында безгә сагаебрак текәлгән коңгырт күзләрне күреп алам. Тимерчыбык артында ниндидер хәрәкәт барлыкка килә, һәм төсен югалткан салам өеме булып күренгән нәрсә кинәт кенә гаҗәеп мөгезле зур гына боланга әверелә. Кулыңны сузып аңа орынырга да була, әмма миңа бу әдәпсезлек, әрсезлек булып тоела. Болан үз дәрәҗәсен белгән кебек, горур гына торып баса һәм берничә мәртәбә безгә борылып карый – янәсе, ярар инде фотога төшерегез. Ә аннан соң ашыкмый гына китеп бара. Койма артындагы пейзаждан тагын берничә болан шул рәвешле пәйда була. Һәм алар тик тиз арада наратлар арасына кереп югалалар.



ТИМГЕЛЛЕ МОГҖИЗА

Википедиягә караганда, мараллар – чибәр боланнарның («Кыргый ферма»да беренче булып без нәкъ менә аларны очраттык) табигый шартлардагы тормышы – чын триллерга тиң. Әлеге сөйкемле затлар трофей өчен ауга йөрүчеләрне генә түгел, браконьерларны да кызыксындыра. Соңгылары әле ныгып җитмәгән болан мөгезләрен җыялар. Моннан тыш, яшь боланнарга селәүсен, Себер бурсыгы, аю һәм бүре һөҗүм итә. «Кыргый ферма»ның гамәлгә куючысы Альберт Камалиев, монда боланнар – тулы иминлектә, аларга бернинди дә куркыныч янамый, ди. Фермадагы хайваннарны аулау каралмаган.

– Берничә ел элек Карловые Варыда (Чехия) затлы боланнарны ничек карап тотуларын, аларны ничек үрчетүләрен күреп кайттым һәм бу безнең киләчәк дип уйладым, – ди ул.

«Кыргый ферма» максатларының берсе – биотөрлелекне саклау. Альберт Камалиев сүзләренә караганда,безнең территориядә затлы боланнарның бердәнбер вәкиле – кәҗә-болан (кечкенә кыз сораган Бэмби) яши. Ә тимгелле болан юкка чыгу алдында тора: алар табигатьтә өч меңнән дә кимрәк калган.

Ярымкыргый шартларда чибәр боланнарны (маралларны) һәм тимгелле боланнарны үрчетү буенча үз проектын Альберт Камалиев 2014 елда эшләтеп җибәрә. Башта хобби буларак. Барлыгы 17 тимгелле болан һәм 24 чибәр болан исәпләнә, алар Алтайдан кайтартыла. Өч елдан соң беренче үрчем пәйда була. Тулысынча җайлашкан хайваннарны иреккә чыгарырга булалар. Шулай итеп, Шомбыт заказнигында 11 болан барлыкка килә. Ә быел тагын 20 сен чыгарырга уйлыйлар.

Акция тагын да күләмлерәк проектка беренче адым була. Шомбыт артындагы урманда 60 вольер төзиләр. Алты ел эчендә баш саны 200 гә кадәр арта. «Кыргый фермада» тимгелле боланнар үз вольерларында яши. Алар аралашучан һәм кызыксынучан. Балалар гына түгел, олылар да сәгатьләр буена аларны иркәли, сыйпый ала. Дөрес, туристларның хайваннарны ашатуы хупланмый – боланнарның шактый төрлелеккә ия үз рационнары бар.

МОНДА ЭКОПАРК БУЛАЧАК

«Кыргый ферма»ның бөтен инфраструктурасы әлегә – 500 гектарлы төзелгән һәм төзелә торган вольерлар, 1 кунак йорты, кунаклар өчен 10 беседка. Россиядә туристлык-рекреацион кластерларны һәм экотуризмны үстерү буенча оештырылган Бөтенроссия конкурсының топ-10 лыгына керү («Шомбыт заказнигы» гаризасы буенча) проектка яңа импульс өсти. Булган базага таянып, тулыканлы экопарк төзү мөмкин булуы ачыклана. Мондыйлар әлегә Идел буе федераль округында юк.

– Паркның территориясе 14 мең гектарга якын булырга мөмкин. Без әкренләп хайваннарның төрлелеген арттырырга ниятлибез. Быел ук инде Белоруссиядән зубрлар һәм Калининград өлкәсеннән кыргый нәфис боланнар кайтартырга килешкән идек, коронавирус комачаулады. Якын киләчәктә монда джип-сафарилар өчен маршрутлар булдырырга уйлыйбыз, җирлек һәм мәйданнар моңа мөмкинлек бирә, – ди Альберт Камалиев. – Хәзер мәктәп укучылары өчен экоагарту программасына Шомбыт заказнигына баруларны кертү мәсьәләсе тикшерелә. Тагын бер зур максат – кыргый хайваннарны яклау буенча хәйрия фонды оештыру.

Ике-өч елдан соң тимгелле боланнарның һәм чибәр боланнарның баш саны 300 гә кадәр артырга тиеш, һәм ул вакытта «Кыргый ферма» башка милли паркларның һәм тыюлыкларның заказларын үти алачак. Ә татарстанлылар әлеге гүзәл җан ияләре белән бүген үк таныша, аларга карап соклана ала.

Урманда болан күрү – байлыкка, диләр. Ә болан мөгезендәге күпләгән үрентеләрне күрүне үзеңнең ярыңны табарга, дип юрыйлар. Теләкләрне үтәр вакыт җиткән түгелме?!

Фото: «Татар-Информ» МА (Владимир Васильев)

АК КОЙРЫКЛЫ ДИҢГЕЗ БӨРКЕТЕ БЕЛӘН КҮЗГӘ-КҮЗ

Автор: Алсу Троицкая

Кызыл китапка кертелгән, сирәк очрый торган ак койрыклы диңгез бөркетен күрергә. «Татарстан» хәбәрчесе алдына әнә шундый бурыч куйды. Нишлисең, үтәргә кирәк.



Диңгез бөркетләре күктә нинди генә трюклар ясамый, андыйны тәҗрибәле очучылар да булдыра алмый.

Без – дүрт кеше. Дүртебезнең дә кулында – бинокль, максатыбыз – Куйбышев сусаклагычы өстеннән оча торган диңгез бөркетен табу. Беренче тәэссоратлар: печән кибәненнән энә табу җиңелрәк булыр иде кебек. Су өстендәге колачка сыймаслык күк, акчарлакларны исәпкә алмаганда, көн үзәгендәге буш Сахараны хәтерләтә.

ҖИРГӘ ТАБА ТУП-ТУРЫ ПИКЕ

Зәңгәр күкне күзләр талганчы ярты сәгатьләп күзәтәм – файдасы юк. Бер сәгать үтә – нәтиҗәсез. Инде өметсезлеккә бирелдем дигәндә, күршем кычкырып җибәрә:

– Әнә ул!

Мизгел эчендә бөтенебез берьюлы биноклъләребезне дустыбыз әйткән якка борабыз һәм таң калабыз. Мәһабәт диңгез бөркете су өстеннән талгын гына әйләнә, нәрсәнедер күзли. Һәм тагын бер мизгелдән ул тырнакларын алга таба сузып, суга ташлана.

– Кара, кара, хәзер балык эләктерә!

– Әнә тагын икәү, күрәсезме?

Барыбыз да күреп ала. Европадагы иң эре кошларның берсе матур гына түгел, ул зифа! Хәзер ни өчен аны бик күпләрнең табигый мохиттә күрергә хыялланунын аңларга була. Бик күпләр хыяллана гына, ә бездә – Лаеш районында – бу хыялны тормышка ашыру бик мөмкин хәл икән. Орнитологлар безнең ко-

Бу кош яраклашу буенча могҗизага тиң. Кирәк булса, ак койрыклы диңгез бөркете аучы да була, кирәксә – үләксә дә ашый ала. Ау вакытында диңгез бөркете ашыкмый гына сулыкны өйрәнеп чыга, корбанын күзәтә. Ул күренүгә, диңгез бөркете үзенең көчле аякларын алга сузып, үткен тырнакларын тырпайтып, таштай аска ташлана.

Фотолар авторныкы һәм Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгыннан алынды

Диңгез бөркетен «ак койрыклы» дип чөйсыман формадагы ак койрыгы өчен атап йөртә башлаганнар. Шулай да аның койрыгындагы ак каурыйлар биш яшьтән соң гына барлыкка килә. Эре кош ул, озынлыгы бер метрга җитә, канатларын җәйгәндә ике ярым метр була, авырлыгы – 9 кг. Диңгез бөркетенең томшыгы сары төстә, бик зур – хәтта башына пропорциясез дә түгел. Горур профиль! Күзләре сары-охра, гәрәбәгә якын төстә.

манданы әзерләгәндә, диңгез бөркетен күрәчәгебезгә ышандырган иде. Безгә чыннан да уңыш елмайды!

Әйтергә кирәк, ак койрыклы диңгез бөркетен эзләргә чыгучы төркем өчен дүрт кеше – оптималь состав. Шуннан да артыгы кирәкми: табигать могҗизасын ыгы-зыгылы шартларда күзәтеп булмый. Шуңа да ул дүрт кешегә кадәр төркем белән генә мөмкин. Күзәтү пункты ак койрыклы диңгез бөркетенең оясыннан туп-туры понтонга таба урнашкан. Шул ноктадан кошларны борчымый гына күзәтергә була.

СУ БУЙЛАП – ТАБИГАТЬКӘ

Кама белән Идел кушылган урында үзеңне вакыт машинасында күпмедер вакытка артка илтеп ташланган кебек хис итәсең: иксез-чиксез су өсте, камыш һәм елга култыклары ярындагы куе урманнар. Бары тик моторның тыныч гүләве генә бүгенге көнгә алып кайта.

Безгә диңгез бөркетләрен су өстеннән дә күрергә насыйп булды. Ләкин алар тиз арада очып та киттеләр, күрәсең, мотор тавышыннан курыктылар. Ни генә әйтсәң дә, табигатькә чыккан кешеләр – шау-шулы һәм куркыныч күршеләр. Диңгез бөркетләрен аулау аларны Халыкара Кызыл китапка кертүгә кадәр китереп җиткергән вакытлар да бар иде. Бәхеткә, хәзер республикада бөркетләрнең табигый үрчем дәрәҗәсе үз хәленә кайтарылды.

Диңгез бөркете белән танышудан соң кордонга кайтабыз. Биредә безне учакта пешкән хуш исле балык шулпасы көтә. Төшке аш янындагы сөйләшкән сүз бары тик сирәк очрый торган шушы кош турында. Гәрчә сусаклагыч һәм аның култыклары буйлап сәяхәт иткәндә, ак койрыклы диңгез бөркетен генә түгел, кабан дуңгызын, кыр кәҗәсен, поши, кондыз яки янәшәдән йөзеп үткән кара еланны да очратырга була.

– Әгәр дә инде уңыш елмайса, кыргый хайваннар кеше күзенә болай гына күренми бит, – ди безгә Идел-Кама тыюлыгы хезмәткәре Евгений Прохоров. – Мисал өчен, ак койрыклы диңгез бөркетләре кешегә әллә ни илтифат бирми дигән фикер дә бар...

АК КОЙРЫКЛЫ ДИҢГЕЗ БӨРКЕТЕ – ЭЛЕМТӘДӘ

Ә хәзер күңелебез белән җәйдән кышка күчәбез. Февраль, әле кар ята, ә инде кышлаудан кайткан ак койрыклы диңгез бөркетләре ояларын ремонтларга керешә: аны март башына йомырка салыр өчен өлгертергә кирәк. Йомыркалары өстендә ата кош белән ана кош чиратлап утырып чыгара. Каты тавыш биреп, алар оя тирәли үз биләмәләрен билгели. Беренче кош баласы йомыркадан чыкканда, һава торышы начар булса, ана кошка ике бәләкәй ак йомгакны җылытырга да туры килә...

Табигатьтә, әлбәттә, без моны күрмибез. Шуңа да иң кызыксынучан натуралистларга тыюлык хезмәткәрләре уникаль проект тәкъдим итә: «Билгесез күршеләр – ак койрыклы диңгез бөркете элемтәдә».

Ояларның берсенә орнитологлар видеокүзәтү камерасы урнаштырганнар, һәм хәзер бәләкәй диңгез бөркетләренең ничек үскәнен күреп була. Үсә төшүгә аларның төсе сорыга алмашына. Ата кош алып кайткан балык әлегә җитеп бара. Кош балалары тук һәм тиз үсәләр. Ә аларның әти-әнисенең күңелсезләнергә вакыты да юк: исән калу өчен көрәш – мавыктыргыч шөгыль. Әйләнә-тирә мохит көтелмәгән сюрпризларын әзерләп кенә тора: әле яңгыр, әле кар ява, әле генә суыта, инде кыздыра...

Менә ана кош коеп яуган яңгыр астында балаларын канатлары астында саклап утыра, вакыт-вакыт канатларыннан суны коеп төшерер өчен җилпенеп ала. Вакыт сиздермичә дә үтә, яңгырлар артыннан кояшлы көннәр китә, менә ояда инде – үсмер кошлар. Аларның төсе коңгырт-сорыдан җете коңгыртка әйләнгән. Ә башлары – соры, койрыклары ак төскә кергәнче 5 ел үтәчәк әле.

Аста ниндидер аңлашылмый торган хәрәкәт сизелә. Тыюлыкның хезмәткәрләре кош балаларының аякларына балдак кидерергә килгән. Алар каршылык күрсәтмәсен, тешләшмәсен һәм тырнашмасын өчен

Яшүсмер кошлар, ашау турында уйламыйча, вакытларын күңел ачып, уйнап кына да үткәрә ала. Канатланып очарга өйрәнгәндә, алар гомер буенча җитәрлек кыйммәтле тәҗрибә туплый. Кошлар теләсә кайсы шартларга тиз ияләшә һәм иркен киңлекләрне үзләренә буйсындыра. Ашарга гына булсын.

Идел-Кама тыюлыгының Саралы участогы диңгез бөркете күзенә нәкъ шулай күренә.

башларына бейсболка кидерәләр. Кошлар тынып кала. Шунда аларның аякларына балдак кидерәләр – балдакка аларның кайда тууы турындагы мәгълүмат язылган, һәм ул – гомерлек.

Тыюлык сулыкларында балыкның күп булуы диңгез бөркетләренең бер парына 2–3 кошчык ашатып үстерү мөмкинлеге бирә, бу исә тыюлыктагы диңгез бөркетләренең саны югары дәрәҗәдә тора дигән сүз. Шулай ук аларның якын-тирәгә таралуын да тәэмин итә. Еш кына кош балалары очышка әзерләнгәндә канатларының ныклыгын тикшерә. Менә кунакка песнәк очып килә. Ояга сусар, урман тычканнары, чыпчыклар, сиртмәкойрыклар да керәп чыга. «Хуҗаларның» балыклы табыныннан калдык-постык белән сыйлангач, тагын үз юллары белән китеп баралар. Диңгез бөркетләре ояларын туганнан соң 150 көннән үткәч ташлап китә, ләкин аннан соң озак вакытлар кайтып йөри әле. *

VIP-МАКАР

Ак койрыклы диңгез бөркетләре үзләренә яңа офыклар ача. Ничек кенә әле! Моның өчен аларның мөмкинлекләре җитәрлек – дөньяның теләсә кайсы почмагына – ачык виза, тоташ хөррият һәм иксез-чиксез зәңгәр күк. Моннан Татарстанның Макар кушаматлы ак койрыклы диңгез бөркете бик яхшы файдаланган. Украинада кышлаган ул. Теләсә кайда түгел, ә президент резиденциясендә – «Конча-Заспа» комплексында. Биредә Макар өчен барысы да бар. 134 гектар биләмәдә пансионатлар, парклар, күлләр урнашкан... Бөркет оҗмахы инде. Ә диңгез бөркетенең күршесендә – югары дәүләт вазыйфаларындагы vip-әфәнделәр.

Бу турыда Идел-Кама тыюлыгының хезмәткәрләре бик яхшы белә: алар бит үзләренең канатлы дусларын компьютер мониторы аша күзәтә. Татарстанның җиде диңгез бөркетенә, аларга ике ай тулуга ук, орнитологлар трекер-тапшыручылар беркетә.

– Нигә кешеләр дә кошлар кебек оча алмый икән? – дип кычкырасы килә. ■

Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгының Саралы территориясенә эксклюзив экскурсия маршрутын экотуристларга аның хезмәткәрләре тәкъдим итә: биредә диңгез бөркетләренең Идел буенда күпләп оя корган урыны.

*Ак койрыклы диңгез бөркетләренең тормышы турындагы видеофильмны «Татарстан» журналының һәм Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгының сайтыннан карый аласыз.

МЕГАПОЛИСТАН – ЕРАККА

Автор: Ольга Туманская

Үзеңнең иҗади идеяләреңне һәм бизнес-проектларыңны тормышка ашырып, табигатьтә яшәргә. Хыялмы? Мин, ыгы-зыгылы шәһәрләрдән качарга курыкмыйча, шул хыялны чынбарлыкка әйләндергән кешеләр янына кунакка барам.

БУ ЙОРТНЫ ТӨЗҮЧЕЛӘР...

– Идеябез шундый иде: Антоновкадагы гаиләләрнең нормаль яшәү, төзелеш алып бару, үсү һәм, елга ике тапкыр булса да, сәяхәт итү мөмкинлеге булсын өчен, биредә хезмәт итү ноктасын булдырырга кирәк, – дип сөйли миңа Владимир Болжеларский. – Үз тормышыбыз мисалында шуны күрсәтергә телибез: авылда моны эшләргә мөмкин!

... Ниндидер техник зирәклекләрдән бик ерак торган кеше буларак, мин эко-төзелеш турындагы мавыктыргыч хикәяне исем китеп тыңлармын, дип башыма да китермәгән идем.

– Бу салам белән аралаштырылган үзле балчык, аннары – һава үткәрүчән калын штукатурка катламы. Аннары инде – финиш штукатуркасы...

Әйе, мин Антоновкада, ул Кама Тамагыннан әллә ни ерак түгел. Мин Владимир белән аның хатыны Мариядә, аларның Андерсен әкиятләрендәгедәй хыял йортында кунакта. Менә аның фотосы да бар – комод өстендә генә тора. Кайчандыр алар шушы рәсемне бер журналда күргәннәр дә, рамга куеп, хыяллана башлаганнар. Биредә, Антоновкада, аларның хыялы чынбарлыкка әверелгән.

– Эко-төзелеш идеясе миңа күптән ошый иде. Мин һәрвакыт үз кулларым белән ни дә булса эшләргә яраттым, һәм бу эшнең тә кулымнан килеренә шикләнмәдем, – дип сөйли Владимир. – Технологиясен өйрәнә генә башлаган идем, тормышыма Евгений Иванович Широков килеп керде.

Халыкара экология академиясе (Минскида) вице-президенты Широков совет елларында космос өлкәсендә – анда тормышны тәэмин итүнең автоном системалары лабораториясендә эшләгән, ә соңыннан

Автор фотолары

БДБ киңлекләрендә «straw-bale» ысулы, ягъни төзелештә салам кулланып, беренче эко-йортны ул салган. Күп нәрсәне Владимир аннан өйрәнгән.

– Бу йорт – минем эксперимент, – дип, ул мине экскурсиягә алып китә. – Миңа бик кызык! Үз кулларым белән канализация – анаэроб бактерияләр белән септик эшләдем, өченче куышлыкта инде чиста су. Җил двигателе идеясен кулланып карамакчы булам… Каты салкыннарда йортны тоту мең ярым сумга төшә, ә Казанда өч бүлмәлегә алты мең сумга якын түлибез. Авылда бу сумманы 600 гә кадәр төшерәсем килә.

Әле 2012 елда ук Владимир өйрәтү-агарту лагерьлары оештыра башлый: кешеләргә төзелешнең башка мөмкинлекләре булуын да җиткерү максатында.

– Ул чакта Татарстанда барлыгы дүрт кенә шундый йорт бар иде, ә хәзер – утызга якын. Идея дөньяга чыкты! Әгәр сез анда яшәп карасагыз, аның ничек сулавын тояр идегез…

Яшьләр үз өйләре өчен урынны шактый озак эзлиләр.

– Ни өчен Антоновка, дисезме? – дип елмая Мария, үзе чынаякларга биредә җыелган үләннәрдән пешерелгән чәй агыза. – Беләсезме, кешеләр гадәттә авылга күченүдән курка, чөнки социаль элемтәләрне югалтырбыз, дип уйлыйлар. Безнең өчен бу урынның кыйммәте шунда: биредә безнең фикердәшләр яши, алар белән дус булу, бергә балалар үстерү, идеяләребезне тормышка ашыру, бер урында таптанып тормау, үсештә булу… Мөгаен, тормышта берни дә очраклы түгелдер. Кешеләр кызыксынуларның уртаклыгы, җаннарының бердәйлеге аша бер-берсенә тартылалар.

Алар бергәләп «Круглый год» дип аталган Авыл территорияләрен һәм күп балалы гаиләләрне үстерү буенча коммерциячел булмаган үзәк ачканнар. Максаты – авыл балаларын төрле һөнәр-күнекмәләргә өйрәтү, күбрәк булган саен, яхшырак. Киләчәктә кем булырга теләүләрен тизрәк ачыклый алсыннар өчен. Гомумән алганда, профориентация – гамәлдә!

ТОРМЫШ УЛ – ТЕАТР!

Мин көлүдән тыела алмыйм. Хәер, кирәкми дә! Тамашачының елмаюы – балалар өчен иң яхшы бүләк. Сәхнәдә чып-чын хисләр кайный. Эшләүчегә караганда, ашаучылар күбрәк булу очрагын балалар татар телендә «Тавык, Тычкан һәм Көртлек» театраль миниатюрасы аша күрсәтәләр. Аны «Антоновка» гаилә ЭКА театрының кечкенә артистлары искиткеч итеп башкара. Хәер, аларның сәхнә осталыгына мондый бәяне мин генә түгел, сәләтле балалар һәм яшьләр өчен июль башында Биләрдә узган ARTS BILER FORUM экспертлары да бирә. Анда Антоновка театры «драматик сәнгать» номинациясендә лауреат исемен алган.

Театр – авыл яңарышының йөрәге, дип ышаналар коллективның сәнгать җитәкчеләре Мария белән Михаил Алексашиннар. Сүз уңаеннан, галим-социологлар да алар белән килешә.

– Коллектив гаилә театры дип атала, чөнки анда өлкәннәр дә, балалар да катнаша, – ди Михаил. – Труппада утызлап кеше – болар актёрлар гына әле! Безгә әле волонтёрлар да булыша – костюмнар, декорацияләр, яктылык, хореография ягыннан. Казаннан, Санкт-Петербургтан, Мәскәүдән, Түбән Новгородтан киләләр… Игътибар итегез: бу импровизацияләнгән тамаша залы Казандагы «Бәхетле Тукай» граффитие авторы – рәссам Bozik белән бергә эшләнгән. Театр берләштерә!

Салам кушылган төзелеш материлы

Узган ел бу проект «Кече шәһәр һәм авылларның мәдәни мозаикасы» юнәлешендә Тимченко хәйрия фондының грантын откан. Шулай итеп Антоновканың үз сәхнәсе барлыкка килгән, анда төп театраль премьералар куела, алар арасында җитди драматик әсәрләр һәм хәтта пластик спектакль дә бар. Өстәвенә, коллектив үзенең җирле тамашачысы белән генә чикләнми. Гастрольләр географиясе ел саен киңәя бара – инде күрше авыллар, Кама Тамагы, республика шәһәрләре һәм, әлбәттә инде, башкала да яулап алынган. Ә быел ЭКА театр чит илләргә гастрольләр турында да уйлана башлаган.

– Әйе, безнең планда Болгариягә, Бяло шәһәренә бару хыялы бар иде, – дип сөйли Мария. – Бяло һәм Кама Тамагы бистәсе арасында мәдәни күпер сузмакчы идек. Коронавирус барысын да бутады! Ләкин берзаман бу афәтнең дә үтәсенә ышанабыз!

Элек Миша белән Маша Санкт-Петербургта яшәгән. Антоновка аларның язмышына бик тиз килеп кергән. Отпусктан кайтканда, матур урыннарны күрергә дип, очраклы рәвештә генә борылып кергән булганнар…

– Мондагылар белән таныштык, барысын да күрдек һәм тиз генә хәл иттек тә – күченәбез! – дип көлә Михаил. – Безнең икенче балабыз туарга тиеш иде, һәм Маша, һавага чыгар өчен, унтугызынчы каттан бала арбасы төшерергә кирәклеге турында уйлыйсы да килмәвен әйтте. Югыйсә анда, Питерда, безнең яхшы фатирыбыз бар иде, ремонт… Тик менә бөтенләй күрешми идек дияргә була – мин көннәр буе эштә. Мин үзем… гади экологик тормыш, үз умарталыгым турында хыяллана идем. Һәм иҗат турында да, билгеле! Барысын да Антоновкада таптык.

Хәзер алар театрны акрынлап мәдәни үзәк дәрәҗәсенә күтәрү турында хыялланалар. Аннары Антоновкада, ниһаять, үз клубларын булдыру турында уйлыйлар. Быел Антоновка тагын бер грант откан – авыл арт-студиясендә элеккеге кәсепләрне торгызачаклар һәм аларны балаларга өйрәтәчәкләр. Әмма актуаль вариантта – бу кәсепләр «сандыкларда» тузан җыеп ятмаслык, ә җиңел генә заманча тормышка кушылып китәрлек итеп.

– Ә шулай да ни өчен ЭКА театр? – дип, ниһаять, үземне кызыксындырган соравымны бирәм.

Миңа шунда ук җавап кайтаралар: «Эка мы еще сделаем, эка сотворим!» – «Әле без эшләячәкбез, әле без булдырачакбыз!»

«Безнең балаларны бәхет басты, – диләр биредәге ата-аналар. – Без алар белән экспериментлар ясыйбыз – биибез дә, җырлыйбыз да, төзибез дә, бакча да үстерәбез». Менә тормыштан бер мисал: малайлар Димадан шалаш коруын сораганнар, ә ул тоткан да аларга чын каркаслы йорт төзергә тәкъдим иткән, әмма миниатюрада! Фундаменттан алып, түбәгә кадәр – барысы да үз куллары белән эшләнгән. Биш атналык үзизоляциядә төзеп өлгергәннәр. Хәзер кечкенә террасалы бу өй малайларны җәй буе шатландыра, кунакларга да тукталыр урын бар. Әмма яшь төзүчеләрнең фантазиясенә чик юк, алда төзелешнең икенче чираты – Идел киңлегенең искиткеч күренешен ача торган түбәдә кечкенә җәйге кафе ясау.

– Аннары алар үсәчәк тә шәһәргә китеп барачак, – дип, үземнең моңсу уйларымны белдерәм.

– Монысы да нормаль хәл! – дип җавап бирә Дима шунда ук. – Һәркемнең үз язмышы. Чөнки алар бүгенге көндә без, ата-аналары, алар өчен сайлаган

ОСТА КУЛЛАР

Бер әти белән әни яшәгән, ди. Һәм аларның берсеннән-берсе уңган-булган бик күп тәти балалары – уллары булган, ди. Алар, дус булып, күңелле яшәгәннәр, бергәләп китаплар укыганнар, театр уйнаганнар, бәрәңге казыганнар, урман утыртканнар... Бервакыт алар арасына бөтен җиргә дә өлгер интернет сихер-михер килеп кергән дә игътибарларын яулый башлаган! Бу хәлне күреп алган әтиләре: «Димәк, балалардан чын осталар ясар вакыт җитте! Ә теге сихер-михерне бу эшкә җигәргә кирәк», – дигән, ди.

Әйткән сүз –аткан ук, шулай итеп, авылда агач эше буенча гаилә остаханәсе барлыкка килгән. Аңа «лес» дигән сүздән «Лесница» дип исем биргәннәр. Аңа да күз салырга булдык!

Олеся белән Дима Бабкиннар өендәге һәр квадрат метрны җентекләп карыйсы килә. Аларның «кечкенә генә, иске генә» өйләре, ни гаҗәп, бик иркен һәм заманча тоела. Хуҗабикәнең зәвыгы һәм стиле, хуҗаның алтын куллары күренеп тора.

– Бу безнең гаилә эко-проекты, – дип сөйли Олеся. – Монда барысы да агачтан ясалган. Бизәлешләре – вагонка калдыклары, егетләребез аларны өстәп фрезерда шомарттылар. Затлы булып күренә.

Антоновкага бу гаилә Түбән Новгородтан күчеп килгән. Дима Түбән Новгород политехник институтын тәмамлаган, үлчәү системалары институтында инженер-технолог эшен калдырып килгән. Олеся үз урынын балалар белән эшләүдә тапкан. Эш аның шул сәләтеннән башланган да инде: 2012 елда Олесяны Антоновкага балаларның палаткалы лагерена вожатый итеп чакырган булганнар. Менә шушы очрак яңа тормышның башлангычы булып киткән...

– Син биредә аның агышын тоярга өлгерәсең, – дип сөйли Олеся. – Ул яныңнан очып үтми, ә чыннан да чишмә булып тибә. Экологик яшәү рәвеше – бу безнең нигез. Әлбәттә, идеалга ерак әле, әмма максатка ирешергә омтылу – үзе үк мавыктыргыч процесс.

шартларда яши. Әмма аларның, ким дигәндә, сәламәтлеге күбрәк булачак. Һәм төрле һөнәр күнекмәләре! Бу – безнең аларга бирә алган нәрсәләребез. Ә инде болардан ни дә булса ошамый икән – без шатланачакбыз гына.

Остаханәдә хәзерге вакытта 10 яшьтән 13 яшькә кадәрле алты малай шөгыльләнә. Үз куллары белән агач уенчыклар, конструкторлар һәм гаҗәеп пазллар ясыйлар. Алар ясаган әйберләрне тотып карау да рәхәтлек бирә. Дизайн, сызымнарын үзләре эшләгән, ә башкару техникасын остаханәдә үзләштерәләр.

Күптән түгел бу проект «Татнефть» грантын откан. Озаклямый Антоновкада токарьлык, кисү һәм циркуляр станоклар барлыкка киләчәк... Булачак кышкы остаханә өчен Владимир үзенең әкияти йортының цоколь катын бирә. Уку елы башлануга барысы да әзер булачак!

– Әлбәттә, бу эшкә үзебезнең генә көчебез җитмәс иде – бу коллектив хезмәт, – дип сөйли Айгөл. Үзе миңа шул арада җыеп өлгергән мәтрүшкә бәйләмен суза. – Арттырып әйтмим, ярдәм бөтен җирдән килә. Урманчылыкка һәм Император питомнигына үсентеләр өчен рәхмәтебез зур, ә алар – утыртканымибыз өчен безгә рәхмәтле. Әмма бу эштә дә ярдәмчеләребез күп. Антоновкада дусларыбыз белән оештыра торган урман утырту бәйрәменә Россиядән генә түгел – бөтен дөньядан волонтёрлар килә! Кушылыгыз – сезгә ошаячак! Һәркем агачны үз уйларын, хыялларын кушып утырта. Агач үсә – хыял да үсә. Күпләр яңадан да күрергә, су сибәргә килә. Эшләргә туры килсә дә, кешеләр монда җаннары белән ял итә. Ә бездән – сый, мастер-класслар, кызыклы мәдәни программа. Менә сезгә танышу өчен дә бер сәбәп!

– Ә үзегезнең нинди хыялларыгыз, киләчәккә планнарыгыз бар? – дип сорашам.

– Балаларга иркенләп йөрер, саф һава сулар урыннар булсын, җиләк-җимешләр, кедр чикләвеге җыяр урыннар... – дип йомшак кына елмая Айгөл.

– Без монда, Антоновкада, үз тормышыбыз эшен сайладык, – дип, җитди итеп җавап бирә Ренат.

– Тәҗрибә туплыйбыз, үзебезнең сирәк төрләр питомнигын үстерәбез. Мәсәлән, Кызыл китапка кергән аю чикләвеген үстерергә тырышабыз. Яки татлы Канада өрәңгесен. Ул инде Раифа дендрариендә безнең климатка адаптация үткән һәм орлыклар да бирә башлаган. Күз алдына китерәсезме, әгәр ул бездә, Антоновка тирәсендә үсеп китә алса? Хыял түгелмени бу?

ЙӨЗ ГЕКТАР БӘХЕТ

Бу карагайның тарихы гадәти түгел. Кайчандыр аристократ һәм дворянин Владимир Молоствов Долгая Поляна утарында яраткан хатыны Елизаветага бүләк итеп әлеге Себер гүзәлләреннән ике аллея утырткан булган. Елизавета Владимировна үзенең мәхәббәт тарихының Антоновкада үз дәвамын табачагы турында башына да китермәгәндер. Һәм аның яңа үсенте рәвешендә инде икенче парның мәхәббәт билгесе булып чиксез матурлык киңлекләрендә үсәчәген. Айгөл һәм Ренат Шәйхәйдәровлар, Молоствова кебек үк, үзләренең тормыш эше итеп табигатьне, үсемлекләрне, урманны сайлаганнар.

– Безнең балалар, – дип елмая Ренат, карагайның йомшак энәләрен сыйпап. – Ун ел элек, әле без урманны утырта гына башлаганда, беренче кызыбыз Айсел туды. Бервакыт аның исемен кире якка укысам, «лес» сүзе килеп чыкмасынмы! Мистика, билләһи!

Ул чакта, 2010 елда, Антоновка ярлары табигый ландшафт һәйкәле территориясендә урманчылар чыршылар утыртты. Әмма ел коры килеп, бер генә чыршы исән калды. Пейзажны күзәткәндә, үлән арасында йомшак энәле агач очларын күреп алдым – монысы инде Антоновка балалары эше иде. Димәк, монда урман булачак – әле ниндие генә!

– Беренче киң күләмле агач утырту эше биредә 1965 елда ук үткәрелгән. Кырлар булган, хәзер урман үсә. Ә кайда урман, анда – гөмбәләр, җиләкләр, артыш агачлары. Кабан дуңгызларына, пошиларга, боланнарга йөрер җир бар, – дип сөйли Ренат. – Без өстәп агачлар утыртабыз, бу урынның биологик төрлелеген баетабыз. Менә, мәсәлән, безгә каршы якта, елга аша, Идел-Кама тыюлыгы, анда орланнар – диңгез бөркетләре яши. Бу кошлар безнең якка да очып чыккалыйлар, әмма монда оя корыр урыннар юк. Димәк, шартлар тудырырга кирәк!

Урман турында алар барысын да беләләр ахрысы! Аның турында сәгатьләр буе кызыклы итеп сөйләргә әзерләр. Киләсе сезон алар өчен юбилей булачак. Нибары ун ел дәвамында, тирән ярларны да кертеп, йөз гектар урман утыртырга өлгергәннәр. Карагай, чыршы, пихта, кедр, юкә агачлары, шулай алмагач, слива, чикләвек, кура җиләге, бөрлегән, карлыганнар да онытылмаган...

ЭПИЛОГ УРЫНЫНА

Йомшак йонлы җирән төлке минем йөземә төбәлгән: «Йә, нәрсә, хәзер хыялланырга курыкмыйсыңмы?» – дип сорарга тели кебек. Без җирле җәнлекләр ратып оялый торган текә кыялы, мәгарәле ярлар тирәсеннән очып диярлек үтәбез. Салкынча Идел суларын ерып, байдаркада.

Байдарка – Миша эше. Ул аңа геолог-әтисеннән калган. Һәм Миша миңа Антоновканы башка яктан күрсәтү өчен, елга буйлап алып бара. Шәп сәяхәт булды бу! Әйе, гаилә эко-туризмын оештыру – хисабы булмаган күпсанлы идеяләрнең тагын берсе.

– Безнең идея – иерархиянең булмавы, барысы да бергәләп хәл ителә, – ди Владимир. – Менә элек артельләр ничек эшләгән – һәркем үз компетенциясе буенча. Безнең Антоновкадагы гаиләләребезнең тормышы – зур социаль проект кебек. Безнең илнең территорияләре искиткеч зур, анда яшәргә теләүчеләр Көнбатыштан булсынмы, Көнчыгыштанмы – һәрвакыт табылачак. Ә ни өчен без түгел? Элек кешеләр авыллардан качкан. Минемчә, озакламый кире процесс башланачак. Һәрхәлдә, коронавирус һәм үзизоляция мондый тормышның рәхәтлеген күрсәтте.

Чыннан да, бәлки, тотарга да мегаполистан качаргадыр? Һичьюгы ял көннәренә генә булса да...

Автор: Катерина Котова

АЯНЫЧ ТАРИХЛЫ ОҖМАХ ПОЧМАГЫ

«Сөйкемле сөякле» Мамадыштан якынча утыз чакрым читтәрәк төрле сер-табышмаклар, борынгы артефактлар, риваятьләр һәм мистикалар белән тулы гаҗәеп дөньяга эләгергә була. Кирмән тавында кем җаннары яшәве турында безнең репортажда укырсыз. Идел буе Болгарының соңгы форпостларыннан берсе нинди булган? Ни өчен, гасырлар узгач та, Сөембикә-ханбикәнең күз яшьләре әле һаман да дәвалый? Сафагәрәй Казан ханлыгы байлыгын кая яшергән?

МОНДА ӘРВАХЛАР ДОГА КЫЛА

Менә ул биек Кирмән тавындагы крепость. Әмма кирмәнгә элэгу – нәкъ борынгы заманнардагы кебек – бер дә җиңел түгел. Иң кулае – таудагы Изгеләр чишмәләре аша җәяүләп юл тоту. Могҗизалар менә шушында – Кирмән елгасы үзәнендә башлана да инде.

Чишмәләрдәге су бәллүрдәй чиста. Җиде чишмәнең боздай салкын суы җир астыннан бәреп чыгып, текә, куе карурман каплаган калкулыктан түбәнгә омтыла. Изге чишмәләр бик шифалы, дип сөйли халык.

– Аларның һәркайсы кеше организмына үзенчә тәэсир итә, – дип бәян кыла безгә Урта Кирмән мәктәбенең тарих укытучысы Ринат Хәйруллин. – Суны уң кул белән генә эчәргә кирәк, әүвәл кулны өч тапкыр чишмә суында чайкап алу шарт. Шул вакытта дога укырга да була.

Беренчесеннән башлыйбыз. Кулны суны салкыны өтеп ала, тик мин шулай да инде җиденче – иң мөһим чишмә – Җан чишмәсенә барып җиттем. Ә аның янәшәсендәге куе агачлар күләгәсенә эскәмия корганнар. Монда килеп утыруга эсселектән җилләр иcте, яфраклар лепердәве һәм су чылтыравы гына ишетелә – чын-чынлап көч өсти торган урын бу!

– Кешеләр бу су белән дәваланып кына калмый, – дип сөйли юламаныбыз. – Явыз рухлар өйгә кермәсен өчен, шуның белән ишек-тәрәзәләрне дә юалар.

Бу чишмәләр турында күп риваятьләр сөйләнә. Менә шуларның берсе. Борын-борын заманда җиде кыз мондагы Кирмән елгасына суга китә дә әйләнеп кайтмый. Алар ниндидер явыз колларга эләгә. Аннары ни булганы билгесез, ләкин шунысы хак: кызлар әсир төшкән җирдә җиде чишмә бәреп чыга.

Моннан берничә ел элек бу урыннарга бер күрәзәче килеп киткән, диләр. Аның әйтүенчә, җир астындагы чишмә юллары кешедәге кан әйләнеше системасын кабатлый икән. Урманлы Кирмән тауларында борынгы әрвахлар яшәгәненә халыкның ышануы юкка түгеллеген дә әйтеп биргән күрәзәче. Дошман кысрыклавыннан качып, мондагы урманнарга чигенгән болгар сугышчылары икән алар. Шунда качып котылганнар да шунда ук калганнар да...

Автор фотосы





1993 елда Урта Кирмән мәктәбе укучылары чишмәләрдән ерак түгел генә манаралары һәм ярымае булган каплаулы ял урыны корып куйган. Ул әрвахларга бик ошаган дип әйтәләр, үзләренең мәчете дип уйлап, намаз укырга киләләр икән. Җирле халык бу корылманы «әрвахлар мәчете» дип йөртә. Ә менә ак таштан ясалган яңасы берни белән дә игътибарны яуламый. Шул күгәрченнәрнең аны бик яратуын искә алсак кына инде, «әрвахлар мәчете»нә керергә курыккан кошкайлар монысын бик үз иткән. Хәтта кошлар да әрвахларның тынычлыгын бозарга теләми...



КИРМӘН ДӘШӘ...

Тимер очлыклар, Ираннан китерелгән нефрит сәйләннәр, Кавказдан килгән сланец кисәкләре... Ринат Миңнегаян улы безгә бу тирәләрдәге казу эшләре вакытында археологлар юлыккан табылдыкларның фотоларын күрсәтә. Күрәсең, монда сак кирмәне генә түгел, сәүдә үзәге дә булган, чөнки хәзерге Мәскәү–Уфа юлы нигездә кайчандыр Шәрык белән Көнбатышны тоташтырган борынгы сәүдә юлын кабатлый бит.

Сүз уңаеннан, бу шәһәрне табу җиңел түгел, чөнки аның бер корылмасы да сакланмаган. Болгар шәһәре Кирмәнчек турында беренче булып, әле XIX гасырда ук, Казан университеты профессоры Сергей Шпилевский телгә ала. Аның фикеренчә, «кирмән» сүзе кергән өч авыл янындагы борынгы ныгытма калдыкларын XIV гасыр рус елъязмаларында телгә алынган «Кременчук (Кирменчук-крепостца)» хәрабәләре дип кабул итәргә мөмкин. Тарихчыларның бу ныгытма турындагы фикерләре кайбер мәсьәләләрдә аерылса да, Кирмәнчекне бу төбәкнең монголларга кадәрге тарихы белән дә, Алтын Урда чоры белән дә бәйләп карап була. Мөгаен, иң киң таралган фикер шушыдыр: Кирмәнчек Болгар дәүләтенең төньяк чигендә зур гына шәһәрлектән гыйбарәт сак ныгытмасы булган, ә аның янәшәсендә авыллар урын алган.

Изге чишмәләрдән кирмәнгә кадәр – бер чакрым ярым чамасы ара. Өстәвенә, тауга күтәрелергә кирәк. Әмма ару турында уйлап та карамыйсың. Кояш кыздыра, төрле үләннәр һәм җир җиләге аяктан егарлык хуш ис тарата. Ә тирә-ягы! Моннан да матуррак урын

юктыр, дип уйларга өлгермисең, йөз метр узуга, бөтенләй башкача манзара ачыла. Гаҗәп!

Һәм менә килеп җиттек. Офыкларга кадәр сузылган хозурлык! Бу тирәдәге бөтен матурлыклар – уч төбендәге кебек кенә, шулар арасында нечкә җеп кебек М-7 юлы күренә, анда исә кырмыскалар хәтле генә булып машиналар чабыша. Кыскасы, әлеге хозурлыкны бер күрүгә үк шикләнми әйтергә мөмкин: кирмән өчен моннан да яхшырак урынны бу якларда һич табып булмас иде.

Сүз уңаеннан, шәһәрнең гомуми мәйданы – 8,5 гектар чамасы, ә ныгытылган өлеше 1,5 гектарны тәшкил иткән. Кирмәнчекне төньяктан – урман, көньяктан – ул чакта мул сулы Кирмән елгасы, көнбатыштан текә яр чикләгән. Дошманнан шәһәрлекне өстәмә рәвештә махсус урлардан гыйбарәт чокыр-ерымнар системасы саклаган. Аңлашыла ки, безнең көннәргә анысы сакланмаган диярлек – бу тирәләр күп еллар сөрелгән-эшкәртелгән. Әмма археологлар аның калдыкларын үҗәтләнеп эзли. Һәм табалар да. Бу эшнең нәтиҗәсе – каршымдагы ур, аны шул борынгы замандагыга бик якын рәвештә торгызалар. Күз алдына да китерү кыен – бу урга мең ел! Әмма бу аның кечкенә бер өлеше генә. Калганы исә җимерелүдән ышанычлы итеп каплап куелган.

Ә ур артында – казык читән. Х гасырда юан имәннән булган ул, хәзер – нараттан. Ике күзәтү манарасының кыяфәте үк анда сакчылар яшеренгән кебек хис тудыра. Бераз алга атлап, күпер, капка аша узасың да кальга эченә килеп тә керәсең. Әмма текә баскычтан өскә – манараның иң очына менми калырга мөмкинме соң? Кыскасы, күгәрченнәрне куркыта-куркыта, бөтен җитезлегемне җыеп, югары үрмәлим. Икенче манара тагын да биегрәк, шулкадәр өскә менү күпләрнең хәленнән килерлек түгел. Кызганыч. Югарыдан ачылган манзараны тел белән сурәтләп бетереп булмый, аны күрергә кирәк!



– Әлбәттә, бу – күзәтү манарасының имитациясе генә, чынбарлыкта аның нинди булганлыгы билгеле түгел, – дип аныклый иkенче юламаныбыз, Мамадышның туган якны өйрәнү музее җитәкчесе Минзилә Садриева.

– Әлбәттә, бу – күзәтү манарасының имитациясе генә, чынбарлыкта аның нинди булганлыгы билгеле түгел, – дип аныклый икенче юламаныбыз, Мамадышның туган якны өйрәнү музее җитәкчесе Минзилә Садриева. – Шуңа да карамастан, бу корылмага карап, без ул вакытта нинди күзәтү манаралары булуын күз алдына китерә алабыз.

Шунысын да искә алып үтик: Кирмән шәһәрлеге – Россиянең мәдәни мирас объекты статусына ия археология һәйкәле санала. Биредә ел саен диярлек барган казу эшләре Кирмәнчектәге мәдәни катламның тирәнлеге нибары 40 сантиметр булуын күрсәтте. Бу исә монда хәзерге заман катламы кушылмаган борынгы җирлек турында сүз барганлыгын раслый. Кешеләр биредә ничек яшәгән, ни белән шөгыльләнгән, нәрсәгә табынган? Бу сорауларга җаваплар аяк астында ята.

– Биредәге халык игенчелек, терлекчелек, чүлмәкчелек белән гомер кичергән. Монда иртә язда килсәгез, чүлмәк ватыклары табарга мөмкин, – дип сөйли Ринат Хәйруллин һәм, үз сүзләрен раслап, кувшин кисәкләре салынган тартма ала. – Рәсемне күрәсезме? Нигездә, бу – су сурәтләре. Аңа карата хөрмәтле, изгеләштерелгән мөнәсәбәт, әле мәҗүсилек чорыннан ук килгән. Авыл зиратларын елга аръягына урнаштыру гадәте юктан гына килеп чыкмаган бит, борынгылар исәннәр белән үлеләр арасында һәрвакыт су агып торуын хуплаган...

Совет елларында биредә бу гореф-гадәтне бозарга һәм ике дөнья арасына... машина юлы салып куярга булганнар. Дөресрәге, ике арада түгел, ә нәкъ борынгы хан зираты – Кирмәнчекнең тагын бер тарихи урыны өстеннән. Кешеләр изге урынны яклар өчен хәтта сәнәкләр күтәреп чыкканнар дип сөйлиләр, тик аларның сүзләренә колак салмаганнар. Трасса салынгач, юлны «үлем юлы» дип атый башлаганнар – биредә үлем-җитемнәр белән тәмамланган аварияләр санап бетергесез. Бүген исә М-7 юлы яманаттан котылган, хәзер ул, әрвахларның тынычлыгын бозмыйча, башка маршрут буенча үтә.

«Ханнар зиратын» шәһәрлектән дә күреп була, мондагы биеклек мөмкинлек бирә. Борынгы каберлек Урта Кирмән авылыннан ерак түгел, Кирмән елгасының уң ярында урнашкан. Анда егермедән артык кабер ташы һәм таш кисәкләре сакланган. Күбесендә XIV гасыр уртасына караган гарәп язулары бар. Танылган совет археологы, тюрколог һәм этнограф Һарун Йосыпов шулкадәр сандагы кабер ташларының бергә җыелып торуы Кирмәнчекнең «зур феодаль үзәк» булганлыгын раслый дип саный.

Ачык һавадагы заманча музей эчендә борынгы Болгар дәүләте чикләрен саклап, биредә яшәгән һәм эшләгән кешеләр истәлегенә зур таш куелган. Кирмәнчек соңгы тапкыр 1396 елгы елъязмаларда искә алына. Билгеле булганча, аның сугышчыларына Урда гаскәрләре һәм юлбасар ушкуйниклар һөҗүменә күп тапкыр каршы торырга туры килгән. Шәһәр янган, һәм дошманнар аны кабат яндырганчы, яңадан төзелә торган булган...

Совет елларында биредә бу гореф-гадәтне бозарга һәм ике дөнья арасына... машина юлы салып куярга булганнар. Дөресрәге, ике арада түгел, ә нәкъ борынгы хан зираты – Кирмәнчекнең тагын бер тарихи урыны өстеннән. Кешеләр изге урынны яклар өчен хәтта сәнәк күтәреп чыккан булган дип сөйлиләр, тик тырышлыклары бушка киткән.

ШИФАЛЫ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ

Мин басма буйлап урман эченә, чишмә тавышына таба атлыйм. Тагын бераз баруга, боздай салкын саф су кулларымны өтеп ала. Җирле халык аның тегендимондый гына түгел, ә бик шифалы су икәнлегенә ышана. Күз чишмәсе – Кирмәннең тагын бер могҗизасы. Аны эзләп табар өчен, изге чишмәләрдән бераз гына уңгарак каерырга кирәк.

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, бу урыннарга еш кына Гәрәй хан һәм аның хатыны – Казан ханбикәсе Сөембикә килә торган булган. Бик мөмкин! Моннан ерак түгел, Нократ белән Чулман кушылган урында, Грахань авылы бар, имеш, аны Гәрәй хан хөрмәтенә шулай атаганнар да. Янәсе, үз урдасына юл тотканда, хан кораблары белән шунда туктаган. Ул вакытта Шәрык белән Көнбатышны тоташтырган юл турында да онытмыйк, бу юлдан хан кәрваны да узган булырга мөмкин бит.

– Риваятьтә хәбәр ителгәнчә, дошман гаскәре Казанны алыр алдыннан, Сөембикә биредә килгән. Яман хәлләр булачагын сиземләп, бәлки, ханбикә озак кына елаган. Күз яшьләре җиргә тамган урыннан чишмә бәреп чыккан, – дип дәвам итә Кирмән фольклоры белән таныштыруны Ринат Хәйруллин. – Чишмә суы, чыннан да, чип-чиста, моны пробалар да раслый. Бу тирә авыллары халкы хәтта кыярны да шушы салкын суда консервлый!

Әлеге чишмә суы күз авыруларын дәвалый дип санала. Дәвалану рецепты бик гади: зур савытка чишмә суы алып, йөзне шунда чумдырырга да күзләрне ачкалап-йомгалап торырга кирәк.

Сүз уңаеннан, тагын бер риваятьтә биредәге урыннар шулай ук ханнар, патшалар белән бәйләнгән. Имеш, кайдадыр шушында – һич тә Кабан күле төбендә түгел – Казан хәзинәсе бик ышанычлы итеп яшереп куелган. Хәзинә эзләүчеләр әле революциягә кадәр үк Кирмәнчектән ерак түгел бер җир асты юлы тапкан, дип сөйлиләр. Тоннель тау авызына илткән. Казан ханлыгы хәзинәсен алар барыбер таба алмаган, хәер, шул вакыттан соң ул байлыкны һичкем эзләмәгән дә. Менә сезгә тагын бер Кирмән маршруты! Дөресрәге, тарихи-экстремаль квест.

ЕРАК ҺӘМ АННАН ДА ЕРАГРАК

Автор фотосы; Мөнир хәзрәт Йосыпов архивыннан

Автор: Ольга Туманская

Без Мәчкәрәдә, Татарстанның иң борынгы җәмигъ мәчетләренең берсе янәшәсендә басып торабыз. Менә шунда басып торганда аңлашыла да инде: Кукмарадан ерак түгел генә урнашкан шушы авыл аша туристик маршрут, һичшиксез, үтәргә тиеш. Тарихка кагылып алырга теләүчеләр өчен, нәкъ менә тотып карарга.



КҮЗЛӘРНЕ АЧАБЫЗ

– Әйдә, барысын да керт! Тиз бул! – дип кычкыра Кызыл армия солдаты.

...Күп тә үтми, мәчетнең гөмбәзле залында дога укыган тавышлар ишетелә башлый. Һәм такта идәнгә зур балта белән чапкан тавыш колакны яра.

– Ә нишләп алар аяк киемнәрен салдылар? – дип сорый мылтык тоткан егет иптәшеннән.

– Мәчеттә шулай тиеш.

– Хәзер абзар бит инде бу...

– Киребеткәннәр!

«Зөләйха күзләрен ача» фильмының беренче сериясендә без күргән кадрлар бирердә – Мәчкәрә авылының Беренче җәмигъ мәчетендә төшерелгән. Ничек кенә кызганыч булмасын, фильм әлеге гаҗәеп урынның тарихын ничек бар, шулай кабатлый.

Фильмда мулла ролен Мәчкәрә авылының хәзерге мәчетенең имамы, Кукмара районының аксакаллар шурасы рәисе Мөнир хәзрәт Йосыповка уйнарга туры килгән. Ул бүген безнең гидыбыз.

– Әни белән беренче тапкыр шушы мәчеткә кергәндә, миңа биш яшь иде – мондагы ярымтүгәрәк матур баскычны әле дә хәтерлим! Бер кадаксыз эшләнгән иде ул. Озак вакытлар мәчеттә колхоз амбары булган, аннан соң инвентарь, ашламалар саклаганнар, – дип, балачак хатирәләре белән уртаклаша Мөнир хәзрәт. Ул безгә чүкеп ясалган борынгы ишекне ача. Аның сүзләре рас килә – икенче катта ындыр табагыннан калган эзләр саклана әле. Ә инде гыйбадәт кыла торган зур залда бераз җимерелә башлаган түшәмә астыннан бодай бөртекләре табып алам. Ничә еллар ята икән инде болар бирердә?

Мәчкәрәдәге Беренче җәмигъ мәчете 1791 елда ул вакыттагы танылган эшкуар Габдулла Үтәмешев акчасына төзелгән. Беренче намаз ике елдан соң укыла.

Чүкеп ясалган ишекләр артында ниләр бар соң? Бу урынның фотоларда сакланып калган тарихы. Зур булмаган стендка куелган фотолар арасында – Мәчкәрәнең борынгы күренеше, ерактан анда мәһабәт мәчетне дә шәйләргә була. Янәшәдәге фотода исә бөтенләй башка күренеш – мәчетнең ае да, манарасы да юк, тәрәзәләре буш, түбәсендә чүп үләне үсә. Гыйбадәтханә 1920 елда ябылган, 1940 елда манарасыз калган.

Мәчкәрәдә «Зөләйха күзләрен ача» фильмының беренче сериясе төшерелде. Актерлар арасында Мөнир хәзрәт тә бар.

Мәчет каршында урнашкан борынгы кибет, ул да элеккеке заманнардан сакланып калган. Кайчандыр анда керосин, шырпы, тоз сатканнар. Хәзер бирердә авыл кибете урнашкан.

– 2005 елда мәчетне реставрацияли башлагач, күпләр манара нигә бик кыска дип сорады. Фотога карагыз – ул шундый булган бит. Тарихи дөреслек!

Кызганычка каршы, Мөнир хәзрәтнең хәтеренә уелып калган теге матур баскычны күрә алмадык – сакланмаган. Әмма гыйбадәт кылу залындагы коеп ясалган бизәкләрнең калдыклары бу урынның элек нинди матур булуы турында аннан да яхшырак сөйли. Баш очында, биектә – фигуралы гөмбәзләр. Штукатуркасы коелган урыннан түбәнең кирпечтән икәнен күреп алам! Элек зур-зур бетон плитәләрдән башка да төзи белгәннәр.

Классицизмның башлангыч чоры, барокко элементлары кушып төзелгән – тарихи архитектура белгечләре мәчетне шулай дип тасвирлый. Һәм бу гайбадәтханәнең республикадагы иң иске дини кирпеч корылмаларының берсе булуын да өстиләр. Әмма бер генә белешмәлектә дә сез бирердә вакыт сулышын тоя, кояш нурларының ни рәвешле зәңгәр гөбәзләрдән кайта-кайта төрле якларга чәчелүен күрә, аяк астында идән сайгакларының шыгырдавын ишетә һәм сезнең тавышларның тыныч кайтавазының заллар буйлап тәгәрәвен ишетә алмассыз.



Үтәмешевләр гаиләсе (1929 ел) һәм аларның туган йорты.

ГАЛӘМ? ҺӘРНӘРСӘДӘ!

Бүген Мәчкәрәдә нибары 65 ихата, ә XIX гасыр ахырында биредә 130 булган. Гомумән, бу авыл беркайчан да зур булмаган. Ә менә бер квадрат чакрымга исәпләгәндә, тарихи артефактлар саны артыгы белән куе. Алар танылган Үтәмешевләр нәселенең башлыгы – Туктар бабай улы Ишман исеме белән бәйле.

Әлеге тарих XVII гасыр уртасыннан башланып китә. Риваять буенча Ишман ул вакыттагы удмурт Мәчкәрәсенә Бурбаш авылыннан күчеп килә. Ни өчен күчә дигәндә, тегендәгеләр белән сүзгә килә. Үзе генә күчеп килмәгән, хәтта Бурбашта төзегән агач мәчетне дә үзе белән алып килгән – сыерларга сөйрәтеп китерткән! Бик җитди, гайрәтле кеше! Нәселе дә шундый ук көчле булган.

Бу тарихны безгә Кукмара районы ягын өйрәнүче белгеч Фәрит Вәлиев сөйли һәм бер очтан Үтәмешевләрнең утарын да карап чыгарга чакыра. Сүз уңаеннан, утардан Җәмигъ мәчете бик яхшы күренә, мөгаен, бу яктан иң отышлы урындыр.

– Бу йортны Габдулла Үтәмешев төзегән. XVIII гасыр ахырында ул иң бай татар сәүдәгәрләренең беренче бишлегенә кергән, – ди Фәрит Вәлиев. – Бирердә, Мәчкәрәдә, тукыма мануфактурасына нигез салган, тукымалар җитештергән. Үзендә җитештерелгән китайканы (мамык тукыманың бер төре – авт.) һәм комачны хәтта Азиягә кадәр илтеп сата торган булган. Аның эшен улы Муса белән оныгы Исхак та уңышлы дәвам иткән – алар да беренче гильдия сәүдәгәрләре була. Алар сәүдә белән шөгыльләнгән, шул исәптән зәркан әйберләре дә саткан. XIX гасыр башында Үтәмешевләр бакыр заводын арендага ала, гасыр ахырында исә сабын кайнату эшенә дә нигез сала, төзелеш белән шөгыльләнә башлый...

«Тирә-яктагы иң эре эшкуарларның берсе була ул, аңа байлыгы ягыннан да, юмартлыгы ягыннан да тиңнәр булмый, өстәвенә, тәкъвалыгы да көчле, фән һәм мәгърифәтчелек дип җан ата» – Габдулла Үтәмешев турында Шиһабетдин Мәрҗани шулай дип язып калдырган. Безнең көннәрдә дә аны фабрикалар һәм заводлар төзегән эре эшкуар гына түгел, ә мәчет һәм мәдрәсәләр салдырган хәйрияче буларак та искә алалар. Россия буйлап дистәләрчә мәчет, шул исәптән Казанның энҗесе булып санала торган «Иске таш» мәчете дә Үтәмешевләр ярдәме белән ачылган.

Аның Мәчкәрәдәге йорты 1826 елда төзелгән, ул бүген дә бик матур күренә әле. Йортның алгы ягы чиста, ак төстә, шул җирлектә зәңгәр йөзлекле тәрәзәләр елмая. Икенче катка агач баскыч буйлап менәсе. Эклектика стилендәге тере архитектура һәйкәлендә татар халык төзелеш сәнгатенең бизәкләрен дә табарга була. Йортның диварлары метрга якын калынлыкта, нигезе берничә метрга тирәнгә казылган. Гасырларга җитәрлек итеп төзелгән!

Өй каршында – гаҗәеп матур аллы-гөлле чәчәкләрдән торган гөлбакча. Боларның барысына да карыйсың да менә-менә баскыч буйлап Габдулла Үтәмешев төшәр дә чәйгә дәшәр төсле тоела. Әлбәттә, безне ул каршыламый, ә Мәчкәрәнең сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен интернат-мәктәбенең директоры урынбасары Фәния Галиәхмәтова каршы ала. Сүз уңаеннан, бу утарны балаларга сугыш вакытында ук биргәннәр, беренче итеп, Ленинград блокадасыннан кайткан балаларны урнаштырганнар. Бәлки, утарның варисларын сөргеннәргә озатылганнан соң, бу һәйкәл таланудан нәкъ шуның аркасында сакланып калгандыр да... Нәрсә генә дисәк тә, бүген без, шөкер, әлеге утарны күрә, карый алабыз.

Әйе, Үтәмешевләр нәселенең язмышы, Исмәгыйль Үтәмешевнең хатыны (эре китап нәшрияты тоткан Мөхәммәтҗан Кәримов кызы) тәвәккәллеге булмаса, бик фаҗигале тәмамланырга да мөмкин булган. Ул үзләрен сөргенгә илтә торган эшелоннан балалары белән кача алган, шулай итеп, тормышын фаҗигагә әйләндергән шушы ил өчен ул улы Рөстәмнең гомерен

саклап калган. Киләчәктә Рөстәм космос, авиация һәм медицина техникасы өлкәсендә академик һәм зур белгеч булачак. Әйтергә кирәк, нәкъ менә ул Юрий Гагаринны галәмгә очышка әзерләү буенча төп эксперт һәм җаваплы кеше була. Бу турыда мин Мәчкәрәнең 2013 елда интернат-мәктәп хезмәткәрләре тарафыннан булдырылган музеенда ишетәм.

Музейга эләгер өчен, йортның биек баскычы буйлап икенче катка менәргә кирәк, һәм анда чын-чынлап тарих белән очрашасың. Бер гасыр дәвамында шомарган баскычлар баскан саен җырлый, диярсең. Түшәмәләр, ишекләр, тәрәзәләр, хәтта җылыту системасы да – барысы да шул вакыттан бирле үзенеке калган. Җиһазлары сакланмаган, әмма кайбер предметларны «Үтәмешевләр дәвере»нең кайбер экспонатлары кебек үк музей залында күрергә була.

– Авыл кешеләре күп кенә әйберләр бирде безгә – революциягә кадәрге коллекция шулай тупланды, – дип сөйли Фәния Галиәхмәтова. – Ә менә бу шкафлар һәм сандык Үтәмешевләрдән үк калган!

Сандык серле булып чыга – үзенең сигналы бар! Белмичә ачсаң, үзенә бер тавыш чыгара. Шуның өчен генә дә килеп карарга була аны.

Дипломат, Чыңгыз Айтматовның улы һәм язучы исемендәге халыкара фонд президенты Әскар Айтматовның Мәчкәрәдә бернічә тапкыр булганы бар. Бирелә, борынгы зиратта, аның әнисе ягыннан туганнары – күренекле Үтәмешевләр нәселе вәкилләре җирләнгән.

КАТЫП КАЛГАН ТАРИХ

«Биредә үзеңне Аустерлица кырындагы Наполеон кебек хис итәсең. Һәркайда үлем тантанасы, бронза корал күплеге, картинадагы кебек таралган каберләр...», – дип яза Борис Акунин танылган некрополь Пер-Лашез турында. Мәчкәрәдә нарат инәләре түшәлгән сукмаклар буйлап атлаганда, бирелдәге зират архитектурасының нәзакәтлелегенә гаҗәпләнеп туймыйм.

Таң калырлык манзара ачыла торган биек калкулык – әлеге иске татар зираты әнә шундый урында җәйрәп ята. XVII гасырның урыны-урыны белән ишелгән таш коймасы артында тынлык. Борынгы кабер ташлары белән бер яшьлек агачлар гына шаулаганы гына ишетелә. Биредә дин әһелләре, хәйриячеләр, галимнәр җирләнгән... Алар арасында – Габдулла Үтәмешев, кабер ташына 1832 ел дип куелган...

– Зиратның иске өлеше яхшы сакланган. Без бу урынны карап-җыештырып торабыз. Шушы көннәрдә төзекләндерү эшләре башланырга тора, – дип сөйли Мөнир хәзрәт.

Мәчкәрәдә бер квадрат чакрымга артефактлар саны артыгы белән куе! Һичшиксез, биредә туристик үзәк булырга тиеш. Музейлары, кунакханәсе, сувенир кибетләре һәм башка шундый инфраструктурасы белән.

Бер кабер ташыннан икенчесенә үткән саен тарих сулышы ныграк тоемлана. Иң борынгы кабер ташы биредә 1801 елга карый, Фатыйма Монасыйпованыкы ул.

– Игътибар итсәгез, һәр ташның үзенең архитектурасы бар – без барлыгы тугыз стиль санадык, – ди Мөнир хәзрәт. – Менә монысы – Оренбургтан, шундагы оста ясаган. Һәм биредә Оренбургтан килгән шәкертнең җәсәде ята, ташка Габдулла Назин Оренбурлы дип язылган.

Совет хакимияте каберләргә тимәгән, күрмәгән ул аларны – кабер ташларына чокып язылганнарны укый алмаганнар. Һәм иске зират онытылган. «Шулай яхшырак та булгандыр әле!» – дим эчтән генә, мәчет тарихын искә төшереп. Биредә барлыгы утызга якын борынгы кабер ташы сакланган. Күпчелегенең янәшәсенә татарчага әйләндереп язылган исем-шәрифләре һәм үлгән вакытын күрсәтелгән такталар урнаштырылган.

– Ә менә монысы Мәрхәбәнең кабере – Габдулла Үтәмешевнең хатыны. Ул күренекле мәгърифәтче Габеннасыйр Курсавиның бертуган сеңлесе булган! – дип күрсәтә ташка Фәрит Вәлиев.

Габдулланы мәгърифәтчелек белән туганлык җепләре генә бәйләми. Туган Мәчкәрәсенә ул мәгърифәт утын алып килә – тирә-яктагы иң яхшы мәдрәсәләрнең берсен булдыра. Анда укып чыкканнар арасында билгеле фикер иясе һәм ислам реформаторы Габденнасыйр Курсави, Каюм Насыйриның әтисе – хаттат остасы Габденнасыйр бин Хөсәен, тарихчы Хөсәен Әмирхан, Шиһабетдин Мәрҗанинең бабасы Сөбхан бин Габделкәрим әл-Мәрҗани...

– Әйтергә кирәк, Мәрҗани китаплары бу зират буйлап чын мәгънәсендә юл күрсәтә ала! Икенче килгәндә, үзегез белән алмый калмагыз аларны, – дип искәртә Фәрит Вәлиев. ■

ШИШКИН ЯНЫНА – ЧӘЙГӘ!

Автор: Әскәр Сабиров

Музей бинасы янында сувенирлар сатучы концерт куя: курайда рус көйләрен көйли. Уен коралы бик борынгы, татар бизәкләре белән бизәлгән һәм... полипропилен торба кисәгеннән ясалган. Мондый хәл кайда мөмкин соң? Әлбәттә, Алабугада!

Фото: Әскәр Сабиров

Әгәр сез вакыт буйлап сәяхәт итәргә ниятлисез икән, бирегә рәхим итегез. Парадокслардан тукылган шәһәр борынгылыкны яратучылар өчен – хәзинә. Алабугадагы Казан, Яр буе, Зур Покров урамнарында XIX гасыр өяз каласының йокымсыраулы рәхәт патшалыгына эләгәсең. Купшы-пөхтә сәүдәгәр утарлары, табыш йортлары, сәүдә рәтләре – вакыт аларга бөтенләй кагылмаган диярсең. Такталарга кызыклы атамалар язылган – «Хлебец», «Мясная лавка», «ТрактирЪ». Сакланып калган әлеге гүзәллеккә үзенең ике метрлы буе биеклегеннән хуҗаларча караш ташлап чуен башлы городовой басып тора.

Алабуга белән танышуымны мин Александр II нең тәхеткә утыруы хөрмәтенә әле 1856 елда ук ясалган тарихи шәһәр паркы янындагы кунакханәдән башларга ниятләдем. Шәһәрнең нәкъ үзәге, әмма икенче көнне иртән мин әтәч тавышына уянып киттем. Әйтегез әле, тагын кайсы билгеле халыкара челтәргә караган кунакханәдә кешеләрне портье түгел, ә якын-тирәдә урнашкан ишегалларында берсен-берсе уздырып кычкыручы әтәч тавышлары уятыр иде?

Беренче көн, музейлар буйлап

БОРЫНГЫЛЫКНЫ ЭЗЛӘП

Казан урамындагы «ТрактирЪ» дигән язу кешене магниттан да көчлерәк тарта кебек. Шәһәр белән аралашуны нәкъ менә шуннан башларга дигән акыллы уйга килеп, кыю гына әлеге бина бусагасы аша атлыйм. Таныша башлагач, сәфәрем белән бер өч йөз елга соңга калганымны аңлап алам. Өч йөз ел элек бушлай берәр чәркә тәкъдим итсәләр, бүген түләргә кирәк икән. Чәркәсе үзләренеке, мондыйны биредә генә бирәләр, русчалатып «муха» дип атыйлар.

– Петр Беренче, гади халыкны трактирларга йөрергә өйрәтү максатыннан, беренче чәркәне бушлай, трактир исәбеннән тәкъдим итәргә боерган. Хуҗалар, әлбәттә, патшага каршы килә алмаганнар, шуңа да үз чәркәләрен уйлап табарга мәҗбүр булганнар – аңа көчкә 10–15 грамм сыек сый кергән. Халык арасында шуңа күрә дә аны «муха» дип атый башлаганнар, – дип аңлата миңа бар, гафу, трактир хуҗабикәсе, шулай ук «Трактир» музей-театры мөдире Татьяна Сираева. – Әмма бу уткенрәкләргә, бушлай сыйланып, исереп китәргә комачауламаган – моның өчен бер-бер артлы берничә трактирга гына кереп чыгасы булган. «Под мухой» дигән гыйбарә дә шуннан калган.

> “
>
> – Петр Беренче, гади халыкны трактирларга йөрергә өйрәтү максатыннан, беренче чәркәне бушлай, трактир исәбеннән тәкъдим итәргә боерган. Хуҗалар, әлбәттә, патшага каршы әйтә алмаганнар, шуңа да үз чәркәләрен уйлап тапканнар – аңа көчкә 10–15 грамм сыек сый кергән, – дип аңлата миңа «Трактир» музей-театры мөдире Татьяна Сираева.

Аңлавыгызча, әлеге трактир – музей да. Әлбәттә, трактир да инде. Мөгаен, илдә бердәнбер шундый урындыр. «Екатеринача» пилмән, «мещан» коймагы, пешерелгән бәрәңге, «трактир» пәрәмәче... – болар барысы да менюда каралган, җитмәсә, борынгы рецептлар буенча әзерләнә, заказ биреп пешертергә була.

Ә ашауны сезнең өчен зур агач өстәлләргә коралар, урындыклары да коеп ясалган. Гарднер һәм Кузнецов фарфорларына сокланып, борынгы савыт-саба кирәк-яраклары арасында тәмләп ашый аласыз. Ләкин биредәге иң кыйммәтле, кадерле нәрсә, әлбәттә, әлеге дә баягы «муха» – чыны, яңа ясалганы түгел. Аны берничә ел элек музей запасникларыннан табып чыгарганнар һәм тәңгәлләштереп караганнар: нәкъ үзе, трактирныкы!

Менә хәзер чәркәнең чыны, оригиналы музей-трактир уртасындагы аерым витрина пыяласы астында, Кораллар палатасындагы империя таҗы кебек, үзенең мактаулы урынын били. Музей хезмәткәрләренең әлеге тарихи чәркәгә аерым мөнәсәбәте аңлашыла. Берничә ел элек аңа патент алганар, хәзер мондый чәркәне сувенир буларак бары тик Алабугада гына сата алалар.

Сувенир, сүз уңаеннан, яхшы сатыла. Ә инде милли сыйның микроскопик дозасы салынган «муха» бөтенләй могҗизалар тудырырга сәләтле. Менә шундый сюрприз белән каршы алганнан соң, Удмуртиядән килгән туристлар төркеме минем күз алдында Алабуга борынгылыгы белән чын-чынлап кызыксынучыларга әйләнде дә куйды.

Барысы да яхшы кебек, әмма мондый төркемнәр аерым йөрергә яраткан туристларга җитди кондәшлек тудыра. «Дежа вю» фильмын хәтерлисезме: «Ну, иностранца-то мы, может и покормим...» Менә монда да оештырылган төркем килә, трактир аларга хезмәт күрсәтү өчен ябыла... Сез каласыз, әлбәттә, чит ил кунагы булмасагыз...



Иван Шишкинның «Жатва» картинасы.

ИСӘНМЕСЕЗ, ИВАН ИВАНОВИЧ!

Трактирдан чыгуга, югары сәнгатькә тартылдым. Ярый әле моннан, Казан урамыннан, бөек рәссамның музей-йортына кадәр ара кул сузымы гына. Җәяү ике минутлык юл – һәм мин инде рәссам Иван Иванович Шишкин, кайчандыр иртәнге пленэрдан кайтып, ял итеп утырырга яраткан террасада рәхәтләнеп чәй эчеп утырам. Кызганыч, хөрмәт белән рәссамның зур кулларын кыса алмыйм – арада гасыр ярымлык вакыт. Зур кул дигәннән, аның шундый икенлеген тәгаен беләм. Останың «Утро в сосновом лесу», «Среди долины ровныя», «Перед грозой» һәм башка шедеврлар тудырган кулының исән вакытында төшерелгән күчермәсен менә әле күрдем генә. Биредә, рәссамның Алабугадагы музеенда саклана ул.

Террасада чәй эчү (әгәр алдан заказ биреп куйсагыз) – мөгаен, әлеге йортта рөхсәт ителгән бердәнбер хөрлектер. Ни дисәң дә, бу йорт – яңа төзелгән йорт түгел, аны әле рәссамның әтисе – икмәк белән сәүдә итүче икенче гильдия сәүдәгәре һәм шәһәр башлыгы Иван Васильевич Шишкин төзеткән булган. Йорт безнең көннәргәчә ничек төзелгән булса, шул килеш, бернинди үзгәртүләрсез диярлек сакланып калган – революциядән соңгы елларны кичергән башка күп кенә дворян һәм сәүдәгәр йортларыннан аермалы буларак.

Менә шактый иркен кунак бүлмәсе, монда рәссамның атасы үзенең яхшы танышы, атаклы кавалерист-кыз Надежда Дурова белән гәп корган. Кече кунак бүлмәсендә кичләрен бөтен гаилә җыелган, алар монда рәссамның бертуганының фисгармониядә уйнаганын йотлыгып тыңлаганнар. Һәм менә тагын бер кадерле урын – әтиләренең кабинеты, кәнәфи куелган һәм ул вакытта модада булган ау этләре төшерелгән гобелен фонында аучылар быргысы эленгән бүлмә. Ә ашханә диварын элеккегечә үк күкеле һәм бүдәнәле сәгать бизи, аны кайчандыр Иван Васильевич Мәкәрҗә ярминкәсеннән алып кайткан, дип сөйлиләр. Аны «тыңлар» өчен ул заманнарда Алабуганың бөтен почмакларыннан җыела торган булганнар, ди...

Иван Иванович Шишкинның музей-йорты.

Сәгать бүген дә – вакыт санарга, ә күке белән бүдәнә көн уртасында концерт бирергә әзер. Олы яшьтә булуы сәбәпле, сәгатькә зур бәйрәмнәрдә генә эшләргә мөмкинлек бирәләр. Күрәсең, утарга дөньяның төрле почмакларына сибелгән Шишкиннар нәселе вәкилләре җыелгандадыр...

Алар, менә бүген минем кебек, могҗиза белән сакланып калган яисә математик төгәллек белән кечкенә детальләренә кадәр җентекләп торгызылган XIX гасыр уртасындагы сәүдәгәр йортына эләгә. Мәсәлән, пейзаж остасының үз бүлмәсенә, андагы җиһазлар, бүлмәнең кыяфәте безнең көннәргә килеп ирешкән «Комната в Елабуге» рәсеменә карап торгызылган.

Пролетариат юлбашчылары тарихы белән бәйле бар нәрсә җимерелгән (Ленинның бабасының Кокушкинода крестьяннар тарафыннан яндырылган утары – моңа ачык мисал) революцияләр һәм диктатуралар вакытында рәссамның йорты ничек исән калган соң? Ихтимал, монда халык хәтере һәм мәхәббәте үз ролен уйнагандыр. Һәм бөек рәссамга карата гына түгел, аның әтисенә карата да, чөнки шәһәр башлыгы буларак башкарган эшләре өчен Иван Васильевичны

хөрмәт иткәннәр, әйтик, Алабугада беренче сууткәргечне ул салдырган. Һәм, әлбәттә, бәхетле язмыш: 1935 елга кадәр йорт Шишкинның туганнарыныкы саналган...

Ә картиналар белән ни хәл? Әлбәттә, останың иң уңышлы эшләре Третьяковкада, Рус музеенда, Казан, башка эре шәһәрләрдәге галереяларда саклана. Монда иң беренче оригиналь эшләрнең берсе – «Жатва» картинасы саклана.

Сез башка беркайда да бирелдәге кебек Шишкин буаларын күрә алмассыз. Алар иксез-чиксез болыннарга, бормаланып аккан Тойма елгасына, Шайтан каласы манарасына һәм кайдадыр бик еракта Чулман елгасына барып тоташа. Әйе, йөз җитмеш еллар элек булачак бөек рәссамны илһамландырган матурлыклар бүген дә искиткеч.

Әмма манзараны заманча детальләр генә бераз боза кебек: ерак офыктагы нефть химиясе гиганты факеллары. Нишлисең – болары замана тамгалары...

Рус сәүдәгәрләре шәһәре моннан мең еллар элек болгар кенәзе нигез салган җирлектә барлыкка килгән. Һәм ул заманнардан калган истәлекле урын – атаклы Шайтан каласы Алабуганың иң кызыклы нокталарыннан санала.

КУРАЙ ҺӘМ РУС КӨЙЛӘРЕ

Кояшта янып, чуендай каралган сувенир сатучы Гали Хәкимов музей-йортыннан ерак түгел, Шишкин буаларына төшү урыны тирәсендә үк сәүдә итә. Бизнесы тыйнак кына, ләкин булдыклылык һәм үткенлек ягыннан – Алабуга икмәк сатучыларының турыдан-туры варисы диярсең! Урыны да иң шәбе, Шишкин картиналары белән магнитлар да аңарда (үзе ясый!), кояшта янып, төсләрен җуймыйлар дип, раслый ул. Сувенир курай да (шулай ук үзе ясаган) башка төрлерәк яңгырый.

– Менә сез тыңлап карагыз, – ди Гали Хәкимов һәм, курайны иреннәренә китереп, рус халык көен уйнап җибәрә. – Авазы нинди чиста, көчле. Ә ни өчен шулай? Чөнки агачтан түгел, ә сууткәргеч торбадан, полипропилен материалдан ясалган. Сүз уңаеннан, экологик яктан иң чиста материал...

Туристлар мондый сөйләшүдән соң шок хәлендә калалардыр, дип уйлыйм. Сәүдәгәр Стахеевлар, Ушковлар, Шишкиннар шәһәрендә татар кураенда рус көйләре яңгырый. Җитмәсә, борынгы халык уен коралы... сууткәргеч торба кисәгеннән ясалган...

Ләкин бу – Алабуга, кемнәргәдер гайре табигый тоелган нәрсәләр – монда гадәти хәл.

Рус сәүдәгәрләре шәһәре моннан мең еллар элек болгар кенәзе нигез салган җирлектә барлыкка килгән. Һәм ул заманнардан калган истәлекле урын – атаклы Шайтан каласы Алабуганың иң кызыклы нокталарыннан санала. Аның турында, Идел буе болгарлары тарафыннан монголлар һөҗүменә кадәр салынып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән бердәнбер корылма дип сөйлиләр. Сүз уңаеннан, әлеге манара нәкъ менә Иван Васильевич Шишкин тырышлыгы белән һәм, әлбәттә, шәһәрлеләр катнашлыгында торгызыла.

Тагын бер факт. Аңа кадәр унҗиде ел элек шәһәрдә зур янгын чыга, шәһәрнең руслар яшәгән өлеше тулысынча диярлек янып бетә. Татар өлешенә ут элми, анда яшәгән халык исә янгыннан зыян күрүчеләрне үзләренә сыендыра...

Яңалыкка һәм экспериментларга тартылу алабугалыларда, күрәсең, бүген генә уянмаган.

– Алабуга Россиянең электр уты кергән унынчы шәһәре санала. Бу хәл 1902 елда була, – дип сөйли шәһәр музее экскурсоводы. – Ә электр станциясен инженер Федор Стахеев проектлаштыра һәм төзи. Федор Стахеев – Россиядә алтын приисклары, заводлар, пароходлар хуҗалары һәм Чулманда икмәк сату эшен үз кулларында тоткан атаклы сәүдәгәрләр һәм сәнәгатьчеләр династиясе вәкиле. Әлеге нәселгә караган тагын бер бай – Дмитрий Стахеев, илдә беренче булып, Америка «фордлары» белән сәүдә итә башлый...

Бүген «фордларны» чит илдән кайтарырга кирәкми, аларны биредә, Алабугада, төгәлрәге, шәһәрдән ерак түгел ачылган «Алабуга» махсус икътисади зонасында җыялар. Полипропилен курай – бу очракта, кәсеп, үзешчәнлек. «Алабуга» исә – композитлар өчен чимал, автокомпонентлар, пыяла сүс, башка дистәләгән иң яңа материаллар һәм технологияләр, хәзерге заманның соңгы сүзе белән оештырылган җитештерү – безнең киләчәк.

Шунда ук боларның барысын да күрәсе килү теләге уяна. Әмма булмый, әлегә монда экскурсияләр үткәрелми икән. Үз сувенирларына өстәп, теләге булган бар кешене бушлай мәгълүмат белән тәэмин итеп торучы Гали Хәкимов, кәефем кырылганны күреп, алга таба план төзергә булыша. Надежда Дурова музей-йорты, Өяз медицинасы музее, Марина Цветаева истәлекләре музее, ниһаять, гаҗәеп Портомойня – XIX гасырга караган җәмәгать кер юу урыны. Мондыйны бары тик биредә генә очратырга мөмкин...

Инде бер көндә барысына да ничек өлгерергә, дип баш ватам. Туктале, борынгы урамнар велосипедта сәяхәт итү өчен махсус ясалган кебек. Тик туристлык-мәгълүмати үзәктә кәефне кырдылар: якында велосипед һәм самокатлар прокаты каралмаган. Тагын бер уңайсызлык: музейлар төгәл кичке алтыга кадәр генә эшли. Һәм бу җәйге чорда, бөтен кичке күңел ачулар тыелган «коронавирус эпохасында»?

Шәһәр тарихы музеенда сәүдәгәрләр гаиләсе янәшәсендә фотога төшәргә була.

Кичке алтыдан соң нишләргә? Бер юл кала – табигатькә. Шишкин буалары янына төшкәч, ун минуттан соң Тойма елгасы ярына эләгәм. Басма аркылы чыгуга, билдән үләнгә чумам, җәйнең бөтен хуш исләре аңкыган иксез-чиксез болынлыкка чыгам. Алабугадагы тагын бер парадокс: шәһәр үзәгеннән әлеге гаҗәеп аулак урынга кадәр – җәяү ун минутлык юл.

Күз алдына китерәм: йөз җитмеш ел элек кулына палитрасын һәм пумалаларын тоткан яшь Ваня Шишкин әлеге сукмаклар буйлап йөргәндер. Шунда ук башыма тагын бер уй килә: нишләп әле Алабугага дип билгеләнгән икенче көнемне шәһәр кырыенда – Шишкин шедеврлары туган урыннарда үткәрмәскә, ди?

Икенче көн, урман буйлап

ПЛЕНЭРДА ОЧРАШКАНГА КАДӘР

Танай урманына юл тотабыз. Шәһәр үзәгеннән машинада – ун минут, һәм мин мәһабәт наратлар арасында басып торам. Ылыс, сумала исе сеңгән урман һавасы башны әйләндереп җибәргәндәй була. Урманның менә бу почмагы рәссамның «Опушка леса» картинасында мәңгеләштерелгән пейзажны хәтерләтмиме соң? Ә менә мондарак тезелеп киткән төп-төз нарат агачлары арасыннан урман эченә кояш

Иван Шишкинның «Кама близ Елабуги» картинасының фрагменты.

нурлары үтеп керә икән... Бәлки, кайчандыр Иван Иванович бу чытырманлыкка «Утро в сосновом бору» шедеврын ясар өчен килгәндер? Дөрес, монда ауган агачлар юк кебек. Алар өстендә шаярышкан аю балалары да күренми. Әмма чынлыкта алар Шишкинның картинасында булмаган да, диләр бит – белгәнебезчә, аю балаларын рәсемгә «керткәннәр», рәссамның рөхсәтеннән башка...

Шишкинның гаҗәеп матур рәсемнәре турында уйлый-уйлый, мин наратлар патшалыгында йөрим. Һәм инде «Опушка» картинасын шулкадәр төгәл хәтерләткән – бишенче урынны, «Утро» картинасы туарга мөмкин булган җиденче урынны тапкач, үземнең уемның өметсез икәнлегенә төшенәм. Гаҗәпләнергә кирәкми – профессиональ сәнгать белгечләре, бер гасыр дәвамында эзләнеп тә, кайбер шедеврларның кайда, наратлыкның кайсы урынында иҗат ителүен төгәл билгели алмаганнар. Җитмәсә, рәссам картиналарын Алабуга янындагы урманнарда гына түгел, Валаам, Вологодчина, Санкт-Петербург тирәләрендә, Карелиядә һәм хәтта ки Швейцариядә дә ясаган...

Шулай да төшенкелеккә бирелмик. «Кама близ Елабуги», «Жатва», «Разливы рек, подобные морям», ниһаять, атаклы «Рожь» картиналары ... Болары бердә – Иван Шишкинның туган ягында иҗат ителгән. «Түбән Кама» Милли паркында (Танай урманы – аның бер өлеше) бөек рәссам этюдларын ясаган урыннарга хәтта экологик сукмаклар да салынган. Төп ориентир – «Түбән Кама»ның офисы.

Менә ул әлеге ориентир. Монда, чытырманлыкка керә торган урында ук, «Экологик маршрут» дигән күрсәткечкә тап булам. Маршрутның башында зур стенд урнаштырылган: анда хәрәкәт схемасы һәм Шишкин картиналары язылган дип уйланылган урыннар билгеләнгән.

Иң яхшы юл күрсәткеч картиналарның үзе булганда, мондый карталарның һәм схемаларның нигә кирәге бармы соң? Әгәр сез киндергә сыланган буяулар әле кибәргә дә өлгермәгән вакыттагы беренчел натура белән хозурлансагыз, кирәкми, әлбәттә... Ә инде йөз утыз яисә йөз кырык елдан соң, урман үзгәрә, ул бөтенләй башкача күренә. Шишкин үзенең «Кама близ Елабуги» картинасын ясаган урынны тапкач (моның өчен никадәр көч сарыф итүемне сөйләп тормыйм), мин кабат фикеремнең дөреслегенә инанам. Иске генә койма, еракка сузылган бормалы грунт юл... – Шишкин беренче планга чыгарган күп нәрсәләр инде, вакыт тузаны астында калып, юкка чыккан. Офыкта мул сулы киң Чулман елгасы калган кебек, әмма ул хәзер күпкә киңрәк, пейзажда сурәтләнеп калган елга үзәннәрен һәм күлләрне үзенә йоткан. Һәм рәссам ясаган манзарадан аермалы тагын бер күңелсез күренеш: картинадагы томан күтәрелгән урыннарда бүген завод торбалары һавага сөрем чыгарып утыра...

Урманда Шишкин эзләре буйлап йөрү, әйтергә кирәк, чын квест, аның да ниндие генә әле. Күңелле, әмма шактый көч, җитди әзерлек һәм вакыт таләп итә торган сәяхәт. Бер көн эчендә иң ерак урыннарда булырга өлгерү – ялгызыңа авыр бурыч. Мин бер көн эчендә күрергә өлгергән нәрсәләрне сугышчан разведка дип атар идем. Сезгә бер киңәш – Шишкин урыннарын өйрәнү өчен экскурсовод ярдәменә таяныгыз, мондый сәяхәтләрне милли парк хезмәткәрләре үткәрә.

Сүз уңаеннан, «Түбән Кама» табигать музее мөдире Ринур Бикмансуров теманы шулкадәр яхшы белә, бу турыда хәтта документаль фильм да төшергән. Рәссам этюдларын ясаган урыннарны эзләп табар өчен, Ринур аның рәсемнәрен, хатларын, табигать ландшафтларын, иске карталарны өйрәнгән. Шуңа күрә атаклы «Рожь» ясалган Лекарево авылы янындагы ноктаны, шулай ук Татар Чаллысы янында «Жатва» туган урынны Бикмансуров төп-төгәл итеп күрсәтәчәк. Тагын әле «бәхәсле» пейзажлар, ягъни бер чыганакка караганда – каядыр Мәскәү янында, икенчеләре буенча каядыр монда ясалганнары турында да сөйләр. Хәер, аларның төгәл кайда ясалулары, бәлки, алай ук мөһим дә түгелдер. Һәрхәлдә, аның иҗатының чишмә башы бирердә – Алабугада һәм аның тирәсендәге табигать кочагында икәнлеге бәхәссез. Ул мондагы мәһабәт урманнарда һәм иксез-чиксез кыр-болыннарда үзенә илһам тапкан. Аның гаҗәеп картиналары исә, ул илһамланган манзара кебек үк, бүген безгә көч, яшәү яме өсти.

– Гаҗәп бит, һәр урман авызында, агачларның һәр кызыклы формасында, нарат ботакларында уйнаган кояш нурларында без Шишкин картиналарындагы сюжетларны күрәбез, – дип, соклануын яшерми Ринур Бикмансуров. – Шишкин безне табигатькә башка төрле карарга өйрәтә.

Сезнең әле Алабугада булганыгыз юкмы? Димәк, пленэрда очрашканга кадәр!

БОЛГАРЧА ХАННАР УХАСЫ

Фото: Александр Ефремов

Автор: Руфия Фазылова

Болгарны күрмәгән кеше сирәктер. Әйе, Ак пулат, Кара Пулат, Ханнар төрбәсе, Икмәк музее, аның янәшәсендәге Ак мәчетне, һичшиксез, күрергә кирәк. Шуның белән бергә Габдрахман коесын да читләтеп үтмәгез. Суы шифалы, теләкләр кабул була, диләр. Ә безгә шушы изге урында уха пешерү бәхетен насыйп итте...

Журнал
ТАТАРСТАН
Обращение
к народам всего мира
Татарстан
ТАТАРСТАН
ЖИЗНЬ
ЛЕНИНА
и история РКП(б)
СПУТНИК
ТАТАРСТАН
ВЕСТНИК
К 50-ЛЕТИЮ ТАТАРИИ
TATARSTAN
BOL'ŞEVIGE
КРАЙ НЕСМЕТНЫХ
БОГАТСТВ

«Татарстан»: сәяхәтләр буенча беренче

Рамил Җиһаншиннан уха рецепты:
Кирәк булачак (10 литрлы казанга):

- Тавык – 1 түшкә
- Җәен – 1 балык
- Судак – 2 балык
- Кызыл балык – 2 кисәк
- Бәрәңге – 4–5 данә
- Кишер – 2 данә
- Куертылган сөт өсте – 50 мл
- Тоз, борыч, лавр яфрагы – тәменчә

ТАВЫК ШУЛПАСЫНА... – БАЛЫК

Корбан бәйрәме алдыннан Габдрахман коесы янында ризык әзерләү, алдан планлаштырылган эш түгел иде. Моны Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы җитәкчесе Рамил Җиһаншин үзе тәкъдим итте.

– Биредә гаиләләр белән килеп корбан чалалар, быел әле язылган кеше юк, – диде ул безгә.

Корбан чалу, аннан соң шул иттән ризык әзерләү өчен биредә бөтен шартлар да тудырылган.

Тик Рамил Җиһаншин сарык итеннән түгел, ә балыктан кайнар ризык пешерергә булды.

– Корбаннар әле чалынмады. Ә балыкны көн саен тотабыз, – диде ул өстәлдә яткан балыкларга ишарәләп.

Әйе, Идел елгасыннан тотылган җәен балыгы, мыекларын «бөкләп», өстәлдә киерелеп ята иде. Аның янындагы судак исә, киресенчә, бу манзарадан азрак «оялган» төсле тоелды.

– Җәенне егетләр кичә тотты, – диде Рамил әфәнде.

Балыклар янәшәсендәге тавык исә азрак гаҗәпкә калдырды.

– Ухага тавык ите дә кирәкме? – дип сорап куйдык.

– Әйе, балыкны тавык шулпасына салсаң, телеңне йотарлык була! Менә күрерсез...

«Телеңне йотарлык» булсын өчен, тавыктан кала, ухага куертылган сөт өсте дә салырга кирәк икән.

– Сөт белән балык? – дидек, янә аптырап. – Әбиләр балыктан соң сөт ризыклары ашамаска куша иде. Имеш, тәнгә балык тәңкәләре чыга...

– Юк инде, – дип елмая Рамил әфәнде. – Уйдырмадыр ул. Аннан, без бит сөт түгел, куертылган сөт өсте салабыз. Кайнар шулпада эремчекләнеп килмәсен өчен, сөт өстен башта җылытабыз.

– Мондый рецепт белән Болгарда гына уха пешергәннәрдер, – дибез. – Бик үзенчәлекле бит.

– Дөресен генә әйткәндә, миңа уханы болай пешерергә дустым өйрәтте. Ул Казанда яши. Болгарда, ханнар шулай әзерләгән, дип, ниндидер уйдырма хикәяләр сөйләү бик үк матур булмас анысы. Хәер, ханнар ухасы дигәндә, бик затлы ризык бит. Өчдүрт төрле балык кына кирәк. Бу көн саен пешерә торган ризык түгел. Зур бәйрәмнәрдә, кунаклар җыелганда, бик рәхәтләнеп пешерергә була. Ханнар сый табыны, бәйрәм ясаганнар бит. Бәлки, анда менә шушы затлы ризык та булгандыр.

«ТУРИСТЛАРНЫ САГЫНДЫК!»

Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы җитәкчесе учак ягып җибәрде. Казанга ул 8 литр чамасы су салды. Һәм шуннан балыкларны чистарта башлады. Без исә, гадәттәгечә, эш барышында әңгәмәне бүлмәдек.

– Башка еллар белән чагыштырганда, быел вазгыять ничек? Туристлар саны нык кимедеме? – дибез.

– Әлбәттә, коронавирус үзенекен эшләде, туристлар саны нык кимеде. Мисал өчен, узган ел бу вакытка 216 мең турист килеп киткән булса, быел ул 53 мең тирәсе генә. Узган шимбәдә халык шактый булды – өч меңгә якын кеше санадык. Мин көне буе бу күренешкә сөенеп йөрдем, кызымны да үзем белән алган идем. Һәр кунакны колач җәеп каршы алабыз. Яшермим, безнең бюджет туристларга бәйле. Халык күп булган саен, акча эшләү мөмкинчелегебез арта. Шуның өчен туристларга бөтен шартларны тудырырга тырышабыз. Кунаклар өчен нәрсә кирәк? Беренчедән, бөтен җирдә чисталык булу мөһим. Икенчедән, бөтен кешегә бәдрәф кирәк.

Өченчедән, кунаклар өчен экскурсиянең ничек узуы, экскурсоводның ни дәрәҗәдә оста сөйләве зарур. Дүртенчедән – туклану. Ә боларның барысы да бездә исәпкә алынган, югары дәрәҗәдә оештырылган.

Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында эшләүче кем белән генә сөйләшсәң дә, туристларны, халык белән аралашуны бик сагындык, диләр. Пандемия шартларында алар күп үзәкләр кебек яңача – онлайн эшләргә өйрәнгәннәр.

– Камерага карап сөйләргә өйрәнү өчен вакыт кирәк булды, – ди җитәкче. – Без бит күзгә-күз карап аралашырга өйрәнгән. Мәсәлән, үземнең дә камера алдында каушый торган гадәтем бар. Ярый әле бездә эшләүче кызлар өлгер, бар нәрсәгә тиз төшенәләр. Аларга карап мин дә сынатмаска тырышам.

Җитәкче, кул астында эшләүчеләрне шулай мактый-мактый, кайнап чыккан суга тавык салып җибәрде.

– Озак пешми ул, – дип куйды.

Коллектив дигәннән, биредә 200 ләп кеше хезмәт куя икән. 500 гектар җир – алар карамагында.

– Бу кадәр җирне карап, тәртиптә тотарга да кирәк бит, – диде җитәкче.

– Сезгә үзебезнең Татарстан туристлары ешрак киләме, әллә инде башка төбәкләрдәнме? – дип кызыксынам.

– Күбрәк Россиянең төрле өлкәләреннән киләләр. Дөрес, быел үзебезнең Татарстан кешеләре күп булды.

– Димәк, сезне Россия төбәкләрендә беләләр?

– Әйе, беләләр. Ерак Көнчыгыштан башлап, Калининградка кадәр. Санкт-Петербург, Ярославль, Мәскәү, Түбән Новгород, Самара, Ульяновск – бу шәһәрләрдән килгән кунаклар еш булалар. Хәзер Урал ягы активлашты, Чиләбе, Пермь... Якынча 200 туроператор белән эшлибез. Алар белән турыдан-туры килешү төзелгән безнең.

– Ә чит ил туристлары киләме?

– Ни кызганыч, бик юк. Барлык туристларның биш процентын тәшкил итәләрдер. Без әле халыкара баскычка күтәрелмәдек. Әлбәттә, Казанда зур чаралар булганда, чит ил туристлары да килә. Ә болай...

«СЫЙЛАРГА СЫЕБЫЗ ҖИТӘРЛЕК»

Уха пешергәндә гүзәл затлар да бар иде. Алар – Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгының үсеш буенча директор урынбасары Лилия Сафина һәм гыйльми сәркатип – Гөлнара Бирюкова.

– Ир-атлар ризык пешергәндә, хатын-кызлар кысылырга тиеш түгел, әлбәттә, – диде алар. – Шуның өчен без, кирәк булса, ярдәм генә итәрбез. Бәрәңге әрчегәндә, кишер тураганда...

– Мин ризык әзерләргә алынам икән, бүтән кешегә эш калдырмыйм, – диде Рамил әфәнде. – Дуслар, туганнар белән табигатькә еш чыгабыз. Учак янында аларга ризык әзерләп ашату миңа ошый.

Аш-су остасы шулпадан тавыкны алды да җаен белән судакны салды.

– 15 минуттан балыкларны алырбыз да яшелчә салырбыз, – диде.

Һәм Рамил Җиһаншин оста итеп бәрәңге әрчергә тотынды.

Без, хатын-кызлар, бу хәлгә мөкиббән китеп, эш барышын күзәттек. (Ир-атлар көн саен ризык әзерләми бит! Шуның өчен дә алар пешергән ризык иң тәмлесе кебек тоела.)

– Бәрәңгене бик оста әрчисез икән, – дибез.

– Әйе, армиядә хезмәт иткәндә өйрәндем. Ризык әзерләү буенча осталыгым бар дисәм, арттыру булмас.

– Көндәлек тормышта да ашарга пешерәсезме?

– Кирәк булса, әзерлим. Тик минем әле хатыным бала ялында, кайткан җиргә кайнар ризык пешкән була. Ул яктан бик рәхәт әле.

– Ә нинди ризыклар яратасыз?

– Барысын да ашыйм, ризыкны аермыйм. Шулай да бәрәңге шулпасына мөкиббән китәм. Әнием дә, хатыным да бәрәңге шулпасын мин ярата торган итеп әзерли.

Бәрәңгене әрчеп тураганнан соң, кишергә чират җитте. Рамил әфәнде аны тиз генә чистартты да түгәрәкләп кисте.

– Болгар музей-тыюлыгында туристларга тәкъдим ителә торган аерым бер ризык бармы? – дим.

– Беренчедән, шуны әйтим: бездән берәү дә ач көенчә кайтып китми, сыйларга сыебыз җитәрлек. Ә аерым ризык дигәндә, «Болгарча азу» популяр. Туристларның бит кая барса да, шул якка хас ризык ашап карыйсы килә. Белгәнебезчә, безнең бабайлар итле ризыкларга өстенлек биргән. Шуңа да әлеге традициягә тугры калырга тырышабыз. «Ханнар ухасын» да пешерәләр, камыр ризыклары – меню төрледән-төрле. Тагын бер бик үзенчәлекле ризыгыбыз бар, анысы турында соңрак. Өстәл янына утыргач сөйләрбез. Тик әйтеп куям, рецептын берәүгә дә әйтмибез. Бу – безнең сер…

«ЭКСКУРСИЯЛӘР КҮБРӘК РУС ТЕЛЕНДӘ»

Рамил Җиһаншин, шулпадан балыкны алып, яшелчә салды. Хатын-кызлар исә табын әзерләү хәстәренә керештә. Без дә алар янына елыштык.

– Безнең коллектив бик тату, – диде Лилия Сафина. – Үзе ура, үзе суга дигәндәй, барысын да үзебез булдырабыз. Кирәк икән, төрле геройлар булып киенеп, театральләштерелгән күренешләр ясыйбыз. Кирәк икән, видеога яздырып, сюжетлар эшлибез яки, киемнәрне алыштырып, җыелышып эшкә чыгабыз. Универсаллар дим үзебезне. Ә башкача була да алмый. Заман белән бергә атларга кирәк.

Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында экскурсияләр күбрәк рус телендә бара икән. Ни өчен шулай дигән сорауга:

– Татарча экскурсияләрне сораучылар аз, – диде җитәкче урынбасары.

– Туристларны Болгар кайсы ягы белән кызыксындыра: дин, тарих, миллилек?

– Тарихи яктан күбрәктер. Хәзер халык бик кызыксынучан. Туристлар күбесе конкрет сораулар бирә, чөнки алар алдан өйрәнеп, нәрсә күрергә теләүләрен үзләре өчен хәл итеп киләләр. Бу безне бик сөендерә!

Ул да түгел, Рамил Җиһаншин безне үз янына чакырып алды:

– Карап торыгыз, хәзер бик җаваплы мизгел, – диде.

Җаваплы мизгел дигәне куертылган сөтне, калай савытка салып, учакта җылыту икән.

– Димәк, уха әзер? – дибез.

– Әзер дияргә дә була. Тәмләткечләр салдым. Бер генә минут торсын да, алабыз…

Куертылган сөтне читкәрәк куеп, пешекчебез самовар янына килде.

– Кайнап чыга инде, – диде ул.

Без исә сабый бала кебек шатландык. Әле бит ниндидер серле ризыктан да авыз итәсе бар! (Аны кызлар әзерләп йөргәнен күз читебез белән күреп алдык).

БАЛМАЙ – ЧӘЙ РИЗЫГЫ

Өстәл артына утырыштык. Рамил Җиһаншин уханың бүлүне дә үз өстенә алды. Әлеге дә баягы, монда да эш тәртибен белергә кирәк. Тәлинкәгә кайнар аш салгач, ике-өч кисәк тозлы кызыл балык һәм куертылган сөт өсте өстәде.

– Яратсагыз, кызыл балыкны күбрәк тә салырга була, – диде җитәкче.

Авыз итәбез… Телеңне йотарлык дию бу очракка нәкъ менә туры килә. Мондый ухаһы чынлап та ханнар гына ашагандыр!

– Безнең якларның үзенчәлекле ризыгы – юка белән ашагыз. Аны безнең хезмәткәр, кунаклар өчен дип, гел шулай пешерә, – дип, Лилия ханым тәлинкә сузды. (Без редакциябез кухнясында юка пешергән бар. Ул баллырак була. Ә Болгарда авыз иткән юка, бүтәнчәрәк, Азия халыкларының ризыгына охшаган димме).

Уха шулкадәр тәмле булды ки, табында утыручылар тагын бер тәлинкә сорап алды. Әллә урыны тылсымлы, әллә пешерүчесе шундый булды, аңламассың…

Кызлар кайнар чәй ясады – монысы да гади түгел, үлән чәе. Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында Самоварлар музее бар. Аның ишек алдында төрле шифалы үләннәр үсә икән. Рамил әфәнде махсус иртән барып, шуннан үләннәр җыеп килгән икән.

Кайнар үлән чәе янына балмай да чыкты. Алда телгә алынган серле ризык шушы икән. Сап-сары, йомшак, баллы бу ризыкны татар халык ашлары китапларында очратырга мөмкин. Бүген дә килен төшергәндә, иң кадерле кунакларга бал белән май каптыралар. Ләкин ул аерым була, ә монда бал белән майны бергә кушканнар. Нәтиҗәдә бик тәмле ризык килеп чыккан.

– Безнең Болгарның «йөзек кашы» бу, – диделәр кызлар. – Шуңа да аның ничек ясау серен берәүгә дә әйтмибез, ачуланмагыз.

– Өйгә кайткач, яңа аертылган бал белән майны кушып ясап карыйбыз әле, – дибез.

– Ясап карагыз, безнеке кебек үк килеп чыкса, – дип серле генә елмайды Лилия ханым.

– Ә сез аңа, бәлки, тагын бүтән әйбер дә кушасыздыр? – дибез.

– Юк, юк, кушмыйбыз. Анысын төгәл әйтәбез. Монда хикмәт бал белән майны күпме кушуда…

– Ярар, остарганчы ясап карарбыз алайса, – дип көлештек без үзара.

… Бик рәхәт, бик тәмле сәяхәт булды бу. Хәзер Болгар дигәч, күз алдына аның тарихы урыннары белән бергә, «ханнар ухасы» да, балмае да килеп басар, мөгаен.

Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгының үсеш буенча директор урынбасары Лилия Сафина:

– Габдрахман коесы турындагы риваять 922 елда мөселманнарның исламны рәсми дин буларак кабул итүе белән бәйле. Габдрахман – кеше исеме. Тарихтан беләбез: монда Болгар шәһәре булган. Көннәрдән бер көнне шушы дәүләт белән идарә итүче Айдар ханның кызы Туйбикә авырып китә. Ханның кызын дәваларга юлдан узып баручы сәхабәләрне чакыралар. Арадан берсе – Габдрахман сәхабә – җиргә таягы белән суга. Һәм әлеге урында чишмә тибеп чыга. Шушы су белән юындырганнан соң, Туйбикә терелә. Айдар хан сөенеченнән:

– Нәрсә сорасагыз, шуны үтим, – ди.

Сәхабәләр ханның һәм ханлыкта яшәүче халыкның ислам динен кабул итүен сорыйлар. Айдар хан ризалаша.

Әлеге легенданың бүтәнчәрәк варианты Таҗеддин Ялчыголның «Тәварихе Болгария» әсәрендә дә китерелә. Әсәрдә вакыйганың булган вакыты, геройларның исемнәре бирелә. Шуңа күрә ул риваять кенә түгел, ә чынлыкта булган хәл буларак кабул ителә:

«Тарих тукыз сәнәсендә хут елында вә йолдызында рамазан мөкәрәмнең тугызынчы көнендә, ул заманда Айдар хан ирде, хәзрәте Сәйеде галәм салләллаһу галәйһи вәссәлам Болгарга өч сәхабә җибәрде. Берсе – Габдерахман бине Зөбәер, икенчесе – Зөбәер бине Җәгъдә, өченчесе – Тәлха бине Госман».

Бу өч сәхабә үзләрен табиблар дип игълан итеп, күп кешеләрне дәвалый. Айдар ханның кызы Туйбикә дә авырып китә. Сәхабәләр кызны ничек дәваларга икәнен әйтә. Алар бер таякны кара савытына куеп дога кыла. Таяк яфрак ярып утырган каен агачына әйләнә. Кыз мунчада яңа каен себеркесе белән чапканнан соң терелә. Бу могҗизаны күргән халык ислам динен кабул итә. Сәхабәләр Болгарда өч ел яши. Халыкны дингә өйрәтә, мәчет салдыра, мәдрәсә ача, Коръән өйрәтә. Өч елдан соң ике сәхабә кире Мәдинәгә китә. Хәзрәте Зөбәер бине Җәгъдә Болгарда кала, хан кызы Туйбикәгә өйләнә, егерме биш ел Болгарда яшәп вафат була.

Әлеге риваятьнең бүгенге көнгә хәтле халык хәтерендә сакланган бүтән вариантлары бар. Аларда конкрет даталар күрсәтелми.

1 Учак ягабыз!

2 Пешерәбез!

3 Турыйбыз!

4 Салабыз!

5 Чистартабыз!

6 Бүләбез!

7 Кисәбез!

8 Алабыз!

9 Салабыз!

10 Ваклыйбыз!

11 Турыйбыз!

12 Җылатабыз!


13 Теләк телибез!

14 Бүләбез!

15 Сыйлыйбыз!

ЧУВАШ ВЕРСИЯСЕ

Автор:
Алсу Троицкая

Хезмәт сөючәнлек, тыйнаклык, өлкәннәргә ихтирам... – гади чуваш гаиләсендәге иң күркәм сыйфатлар шушыдыр, мөгаен. Һәм, әлбәттә инде, кунакчыллык, аның да бер үзенчәлеге – милли ашлар. Барып ашап карыйбызмы?

УҢГА КАРАСАҢ ДА – ЯР, СУЛГА КАРАСАҢ ДА – ЯР

Республиканың Аксубай районындагы Сөнчәле авылына юл тотабыз. Бирегә чувашлар берничә гасыр элек килеп төпләнгән.

– Безнең көннәргә килеп җиткән риваятькә караганда, агалы-энеле өч туган – Сөнчәк, Үзи һәм Мокша Сөнчәле, Үзи һәм Мокшино авылларына нигез салган. Тарихчылар әйтүенчә, бу урыннарга беренче тапкыр болгавыр еллардан соң – 1600 нче елларда килеп утырганнар. Чувашларның кайбер гаиләләре Сөлчә елгасына кадәр килеп җиткән, аларга бу елганың исеме мәгълүм булган, һәм алар биредә Сөнчәле авылына нигез салган. Әйләнә-тирәдә карурман булган, шуңа да баштарак алар уң як ярдагы аланга урнашканнар. Яз көне елга ярларыннан чыгып, су баскач, алар биеккәрәк – урманлы сул як ярга күченергә мәҗбүр булган. Биредә инде аларга урманны төпләп, чәчәр өчен җир чистартырга туры килгән, – Сөнчәле Мәдәният йорты директоры Сергей Крайнов әнә шундый сүзләр белән безне чуваш традицияләре дөньясына алып кереп китә.

КӨЧ БИРӘ ТОРГАН ЭЧЕМЛЕК

– Кунакларны сүз белән сыйлыйсың, Сергей, озын юл узып килгәннәр, иң яхшысы безнең чуваш квасы белән сыйла, – дип, хуҗаның хатыны Валентина безгә ата-бабалары чәчү, урып-җыю, печән өстендә эчәргә яраткан эчемлекне өләшә.

– Сӑра – теләсә кайсы йоланың мәҗбүри эчемлеге, – дип сөйли хуҗабикә. – Рецептымы? Аны, гадәттә, колмакта ясыйлар. Әмма андые яраткан кешегә генә. Мин колмаксыз ясадым, курыкмыйча эчегез…

Әчкелтем эчемлекне эчеп карагач, аның сырамы, квасмы икәнен аңламадым: тәме тегесенеке дә, монысыныкы да түгел. Әмма караҗимеш белән йөзем тәме сизелә.

– Аны төрле гаиләдә төрлечә әзерлиләр, – дип аңлата Валентина, – исерер өчен генә эчмиләр. Ул сусауны баса, көч бирә. Һәр гаиләнең үз рецепты бар. Мин әбиемнең рецепты буенча ясыйм.

Юлда әлсерәп килгәннән соң, көч кереп киткәндәй булды, ишегалдына чыктык. Өйгә керә торган ишекләр ачык, лапталар, чигүле иконалар һәм сөлгеләр арасында тумбочка өстендә чуваш хатыннарының баш киеме – хушпуны күреп алам.



Хушпу –хатын-кызлар баш киеме, ул катлаулы итеп эшләнгән. Ул башны каплый торган башлыктан һәм хатын-кызның аркасы буйлап төшә торган озын, турыпочмаклы койрык өлешеннән тора. Башлык куннән, киездән, өйдә тукылган берничә кат киндер яки йон тукымадан тегелә. Аңа рәт-рәт итеп, көмеш яки көмешкә охшаш тәңкәләр тезәләр. Хушпуның баш очы өлеше күп вакытта кызыл төстәге сәйлән бөртекләреннән җыелган кайма белән каймалана. Хушпу бик кыйммәтле әйбер саналган һәм әнидән кызга күчә торган булган. Элекке заманнарда шундый бер хушпуга ике сыер яки бер ат алып булган. Гаилә ядкаре буларак, ул буыннан-буынга тапшырылган.

Автор фотосы

ДӨРЕС ИТЕП ЯСАЛГАН ОКРОШКА

Чуваш милли киемен кигән хуҗа безне җитез генә верандада куып тота: кулында самавыр, хәтта төтене чыгып тора. Ишектән туп-туры кунак бүлмәсенә үтәбез, ә анда табын корылган. Чувашларның төп ризыгы – хуплу янәшәсендә – өлгереп җиткән карбыз, ә стаканда урман җиләкләреннән күз явын алырлык бәйләм. Җәй! Шушында ук турахка ясалган чуваш окрошкасы.

– Дөресен әйткәндә, миңа кваска ясалган окрошка күбрәк ошый, – ди Сергей, – әмма чувашча булсын, дисәң, аны турахта (әчкелт сөт әчемлеге – авт.) ясарга кирәк. Яшел суган белән укропны алдан ук яртылаш кое яки чишмә суы кушылган турахка салабыз. Тагын пешереп төйгән бәрәңге өстибез. Куе булсын өчен. Шуннан соң барысын да ярты сәгатькә суыткычка куябыз. Суыткычтан алгач, шакмаклап туралган пешкән ит, йомырка, редис, кыяр салабыз да, окрошка әзер! Җәйге челләдә ашар өчен шуннан да яхшысы юк.

> – Дөресен әйткәндә, миңа кваска ясалган окрошка күбрәк ошый, – ди Сергей, – әмма чувашча булсын, дисәң, аны турахта (әчкелт сөт эчемлеге – авт.) ясарга кирәк.

БАРЫБЫЗ ДА ӨЙДӘ ЧАКТА

– Әгәр дә ашарга әзерләү кәефне күтәрә торган шөгыль түгел икән, ул тәмле дә булмый. Ризык – чуваш гаиләсендәге бәхетнең бер шарты, – ди Валентина, хуплуның өстеннән суган башын алып куеп. – Бездә, чувашларда, өй эшләрен дә, ихатадагы эшләрне дә ирен белән бергәләп эшләү кабул ителгән. Бәрәңге чүбен бергәләп утыйбыз, печәнне бергәләп чабабыз, яшелчә бакчасында да бергәләп эшлибез. Шулай да ашарга пешерү күбрәк хатын-кызга кала, ирләргә эш болай да җитәрлек.

Хуплуның хуш исенә караганда, хуҗабикә аны яратып пешерә. Өстәл янына утыргач, сусыл пирогтан авыз итәбез. Мин тәмле ризык булганда һәм дуслар җыелган җирдә була торган рәхәтлеккә чумам. М-м-м... Авыз тутырып чәйни-чәйни, күзләремне әйләндерә-әйләндерә, миңа ничек рәхәт икәнен күрсәтәм. Хуплу, син миңа бик ошыйсың...

ТРАДИЦИЯЛӘР ТУРЫНДА

– Чувашлар милли ризыклар буенча гына түгел, көндәлек тормышта да миллилекне саклый, – ди Сергей. – Аларның иң мөһиме, минем, – хезмәт сөючәнлектер. Безнең авылны гына алыйк. 126 ихатада 170 сыер бар. Мал-туарны күпләп тотабыз. Мин биш савым сыеры, дуңгызлар, казлар, куяннар, тавыклар асрыйм. Шуның янына яшелчә бакчасы, кышка унбишләп трактор йөге печән әзерләргә кирәк. Барысына да өлгерәбез, чөнки йокыдан иртәнге дүрттә торабыз. Дөрес, кышын соңрак – биштә. Мин күп балалы гаиләдә үстем. Менә әнием – Зинаида Андреевна, – дип таныштыра безне хуҗа, – 1 гыйнварда аңа 90 яшь тулачак. Ул әлегә кадәр хуҗалыкта эшли, казлар карый. Безне тәрбияли. Тыңлыйбыз, без бит балалар. Өлкәннәр әйткәнгә каршы килмибез. Әнинең 17 оныгы, 19 оныкчыгы бар. Аз дигәндә дә әле, өстәл янына 30 кеше җыелабыз. Иң якыннарыбыз...

Бәби туса, аны 40 көн буена күрсәтергә кушмыйлар. Шуннан соң гына котларга дип, туганнар килә башлый. Үзара телефоннан шалтыратышып, кем нәрсә алып киләсен сөйләшәләр. Кемдер хуплу пешерә, кемдер – бәлеш. Өстәлне дә үзләре әзерли. Яшь әнинең вакыты юк. Ул чәй ясап кына тора. Ә кунаклар «тәпи юа», күңел ача. Ничек юмыйсың инде – кеше туган бит!

– Ә димләү? – дип сорыйм. – Сезнең авылда кәләш янына элеккечә яучылар җибәрәләрме әле?

– Әйе-е-е, – дип, бертавыштан җавап бирәләр Крайновлар. – 2019 елны олы кызыбызның йөргән егете безнең гаиләдә каршылады. Алар инде сигез ел дуслашып йөрделәр, без аны бала вакыттан ук беләбез. Бәйрәм итеп утырабыз шулай, ә ул кинәт кенә: «Әти, мин сезнең кызыгызның кулын сорыйм!», – димәсенме. «Мин каршы түгел, сине күптән беләм, күз алдында үстең», – дип җавап бирдем. Ул сикереп торды да каядыр чыгып йөгерде. Чәчәкләр, конфетлар һәм балдак тотып кире килде һәм: «Әти-әниемне дә чакырыйм әле?» – ди. Булачак кодалар белән бергәләшеп бәйрәм иттек, ә 8 гыйнварда Раштуадан соң ярәшергә килделәр. 11 кеше. Бездә кодаларның саны так булырга тиеш. Җөп сан булса, яхшыга юралмый. 15 февральдә – никах, аннан соң туй булды.

Тагын бер үзенчәлекле йола бар әле. Туй көнне кияү ягыннан берәр туганы кәләшнең әти-әнисеннән тавык урлый – икенче көнне яшь килен өй токмачы кисеп, тавык шулпасы пешерергә тиеш. Хәзер инде кызның әниләре тавыкны алдан ук әзерләп куя, кодаларга әзер тавык кына биреп җибәрә.

АВЫЛ ТУРЫНДА

1986 елга кадәр Сөнчәледә Мәдәният йорты чиркәү бинасында урнашкан була. Яңа клуб төзегәч, чиркәү торгызыла. Авыл халкы акча җыя, Чистайдан ура кайтарта, үз көчләре белән күтәрә, түбәсен яба. Бүген анда службалар үтә, ә төзелә торган кәшәнәдә балалар өчен якшәмбе мәктәбе ачарга ниятлиләр.

– Көнкүреш мәсьәләләрне авыл җыелышларында хәл итеп барабыз, – ди Сергей Петрович. – Соңгы елларда үзара салымга шактый күп эшләр эшләнде. Нигездә, юллар. Хәзер теләсә кайсы урамга кереп була. Ә элек ничек иде? Машиналарны үзәк урамда – безнең өй янында калдырып китәләр иде дә өйләренә хәтле җәяү кайталар. Коеларны торгызабыз, зират юлына таш салдырырга планлаштырабыз. Эшне дә өмә белән башкарырга яратабыз, тәмле әйберләрне дә аерым-аерым ашауны күз алдына да китермибез. Өстәлеңдә бүген нәрсә – анысы мөһим түгел, бәйрәм хуплуымы, җәйге окрошкамы – барыбер. Булганына шөкер әйтә беләбез. Безнең чуваш милли ризыкларының төп ингредиенты – кунакчыллык. Сөнчәлегә рәхим итегез!

Японияне сакэсыз, Россияне аракысыз, Шотландияне вискисыз, Кубаны ромсыз күз алдына китереп булмаган кебек, чуваш йортын да традицион сыра яки өйдә ясалган квастан башка күз алдына китереп булмый… Эчемлекнең составында бары тик табигый ингредиентлар гына: колмак, чүпрә, шикәр, борынгы рецептлар буенча шыттырып киптерелгән арыш, солы яки арпа оны, чөгендер, кипкән җимешләр һәм, әлбәттә, кое суы. Сăра ике төрле була – бераз исерткеч яки бөтенләй алкогольсез.

Чувашча варениклар (эремчек, җиләк-җимеш, суганлы төйгән бәрәңге, кәбестә белән) хуран кукли дип атала. Кайнар килеш каймак яки ак май белән ашыйлар.

Чувашларның бөтен бәйрәмнәрендә дә пешерелә торган ризык – хуплу. Ул сөткә-майга изгән яки төче камырдан кызарып тора торган итеп пешерелгән түгәрәк бәлеш, эчлегенә бодай ярмасы, ит, суган һәм бәрәңге салалар. Русларның тавык бәлешенә яки татарча бәлешкә охшаган. Чын хуплу мичтә пешә, өстәлгә чыгарып куйгач кына кисеп алалар. Аны болай ашыйлар: башта капкачын ашап куялар, аннан соң – эчлеген, шуннан соң гына төбенә чират җитә. Кайчакта эчлегенә йомырка, балык яки дуңгыз салосы кушалар. Бәлешне мичтән алуга, кап-кайнар итеп тә, бераз суытып та ашарга була.

Автор: Алёна Кутыркина

ТАТАРСТАННЫҢ БАРЛЫК АККАУНТЛАРЫНДА ДА

Сәяхәтләр оештыру осталыгы буенча блогерларга тиңнәр юк. Аккаунтларында күпсанлы тиктормас һәм тынгысыз кешеләрне үз артларыннан ияртә алар. Чит илләргә чыгуны тыю да сәяхәтләрне туктатмады – коронавируска бәйле катгый карантин чорында да, режимны йомшарткан бүгенге көндә дә – Татарстаныбызның искиткеч матур урыннары барлык туристлык аккаунтларында урын алды. «Минем арттан ияр!» – дип чакыра блогерыбыз Алёна Кутыркина. Һәм аңа ияреп, Байлар Сабасына – туристлар өчен бик кызыклы районга юл тотабыз!

Казаннан сәгать ярымлык юл – туристлар өчен чын хәзинә, байлык тулы сандыкка тиң урын. Монда искиткеч матур табигать тә, тарихи урыннар да, интерактивлык өчен шартлар да бар. Ә биредәге йорт-җирләрнең, ишегалларының матурлыгыннан һәм чисталыгыннан безнең блогерыбыз бөтенләй телсез калды. Бераз сөйләшә алу сәләте кире әйләнеп кайткач та ул, бертуктаусыз: «Нинди искиткеч авыл!», «Нинди гаҗәеп урын!», «Әйтеп-аңлатып кына булмый, моны бит күрергә кирәк икән!» – дигән соклану сүзләрен кабатлады. Шуңа күрә без күп сөйләп тормыйбыз, күзәтәбез, фотографиягә төшерәбез һәм укучыларыбызны үзләрен бу матурлык белән хозурланырга чакырабыз.

Автор фотосы

МИҢГӘР: АВЫЛНЫҢ ГҮЗӘЛЛЕГЕ КАЯН БАШЛАНА?

Миңгәр авылына XVII гасыр уртасында нигез салына. Хәзер ул – гадәти генә авылны тылсымлы гүзәллеккә һәм керем чыганагына әйләндерә алу үрнәге, югыйсә, авылны бары яратырга һәм аны үстерү өчен тырышлык куярга гына кирәк булган. Миңгәр сүзенең борынгы огуз теленнән «чыганак» дип тәрҗемә ителүе очраклы түгелдер. Авыл бик матур табигать кочагында урнашкан. Кызрата тавы (Хозер Гата тавы) бу урыннарга тагын да күбрәк ямь өсти – әйтерсең лә, Сөембикә манарасын ниндидер могҗиза белән Казан Кремленнән бирегә күчереп куйганнар.

– Күчерелмәсе, – дип тынычландыра безне миңгәрләләр һәм горурланып өстәп куя. – Ул Сөембикәдән сигез метрга биегрәк! Анда Minger Tower кунакханә йорты урнашкан.

Һәм бу, әлбәттә инде, туристлар өчен аеруча мөһим. Бигрәк тә Сабантуйга килүчеләр өчен. Миңгәр сабантуен сабантуйның да Сабантуе, диләр! Гаҗәеп Сөембикәгә тагын бер кат карагач, моның шулай булуына шик калмый.



МӘДРӘСӘ МУЗЕЕ: МӘККӘДӘН ТУРЫДАН-ТУРЫ ТРАНСЛЯЦИЯ ҺӘМ ИМАМ ТАЯГЫ

Мәдрәсә музее 1893 елда ук төзелгән бинада урнашкан. Гаҗәеп кызыклы һәм катлаулы язмышка ия мәдрәсә. XVIII гасыр ахырында уку йорты буларак ачылган мәдрәсәнең тышкы кыяфәте – нәкъ макетта күрсәтелгәнчә. Заманында Европадагы иң зур авыл мәдрәсәләренең берсе була. Бирәдә 300 шәкерт белем алган.

Сугыш вакытында бинаның икенче катын утынга сүтәләр. Сугыштан соң, 60 нчы елларда, бирәдә мәктәп урнаша, аннары – мәктәп склады. Бинаны әле күптән түгел, 2015 елда гына, реставрацияләп, анда музей ясыйлар. Без хәзер нәрсә күрәбез соң? Проект авторлары музей эшен күпьяссылыклы итеп оештыра алган, бер залында Мәккәдән турыдан-туры трансляция бара, ә икенчесендә – Саба районының барлык мәчетләре буенча виртуаль турда катнашырга мөмкин.

Мәдрәсәдәге реаль экспонатлардан имам таягын, укучы урындыгын, бинаны реставрацияләгәндә чормада табылган портфель һәм бөтиләрне атарга була.

БАЙЛАР САБАСЫ – БОРЫНГЫ ДИҢГЕЗ ТӨБЕ

Байлар Сабасы шәһәрдән килүчеләрнең күзләрен төрле төсле чәчәк түтәлләре, авылча гади һәм сөйкемле сыннары белән иркәли, андый скульптуралар хәтта янгын частен дә бизәп тора икән.

Сабинка елгасының яр буе бүгенге көндә өлешчә реконструкцияләнә. Су агымын киңәйтергә һәм территорияне тагын да ямьләндерергә ниятлиләр.

Хәзер биредә ниндидер осталар тарафыннан агачтан зур уем эшләп куелган. Ул сабалыларга бу урынның кайчандыр борынгы диңгез төбе булуын искәртеп тора. Ә бүген биредә үзенчәлекле балалар мәйданчыгы урнашкан, уйнар өчен шугалаклар һәм баудан үрелгән парк эшли.

ЛЕСХОЗ БИСТӘСЕ: УБЫРЛЫ КАРЧЫККА – КУНАККА

Иң тылсымлы һәм әкияти тәэсирләр аласың килсә, Лесхоз бистәсенә юл тотарга мөмкин. Анда Саба урман хуҗалыгы тарихына багышланган үзенчәлекле музей бар. Җирле урман хуҗалыгы белән 28 ел буе Нургали Миңнеханов – Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның әтисе җитәкчелек иткән. Аның исемендәге гадәти булмаган дендрология бакчасына экскурсияне туристлар алдан ук броньлап куя. Һәм монда чынлап та карарлык әйберләр җитәрлек: тропик үсемлекләр утыртылган өч зал, фито-бар, гаҗәеп матур аллеялар, осталык дәресләре өчен бүлмә, «Әкияттә кунакта» зонасы һәм үләннәр җитештерү линиясе.

«Әкият» территориясендә әлегә эшләр дәвам итә, әмма хәзердән үк Шүрәле белән танышырга, Убырлы карчык йортын карарга, өч аю янында кунакта булырга һәм теләк теләргә мөмкин. Сабалылар ышандырып әйтә: хыяллар, һичшиксез, чынга ашачак.



ПАНДЕМИЯ ЯШӘҮ РӘВЕШЕН ҮЗГӘРТТЕ



Гөлназ Сафина, Американың Нью-Джерси штатында яшәүче милләтәшебез, – пандемия һәм үзенең яңа тормышы турында.

– **Биредә без 2018 елның августыннан бирле яшибез. Грин карта ярдәмендә күченеп килдек.** Америкага китү, беренче чиратта, тормыш иптәшем Марсельнең теләге булды. Аның биредә сеңлесе яши. Тугыз ел элек, ул да, грин карта отуда катнашып, Америкага киткән иде. Хәзер алар гаиләсе белән – бер тирәдә, аралашып яшибез.

Казаннан без гаилә белән – ирем, улларыбыз Раил һәм Камил белән күчендек. Ул чакта балаларның берсенә – 9, икенчесенә 7 яшь иде. Хәзер инде бишәү булдык, узган ел төпчек улыбыз туды. Аңа Рүзәл дип исем куштык.

Казанда мин балалар бакчасында тәрбияче булып эшләдем. Америкада да шул юнәлештә эш эзләдем һәм таптым. Рус телле балалар өчен шәхси балалар бакчасы бар, шунда урнаштым. Балага узгач, эштән китәргә туры килде. Тормыш иптәшем компьютер җиһазлары сата торган оешмада эшли.

Инглиз телен начар белгәнгә күрә, монда килгәч тә, башта рус телен аңлаган кешеләр белән танышу ягын карадым. Шулай ук татарларны да эзли башладым. Интернеттан Нью-Йорк татарлары оешмасын эзләп таптым. Аларның үз биналары бар. Һәм Марсель белән алар янына танышырга бардык. (Без яшәгән шәһәр Нью-Йоркка бик якын, ярты сәгатьлек кенә юл.) Ул Корбан бәйрәменә багышланган кичә иде. Анда безне бик җылы каршы алдылар. Милли ризыклар белән чәй эчтек.

Узган ел биредә Сабантуй узды. Аны Нью-Йорк татарлары ассоциациясе оештырды. Бәйрәмгә йөздән артык кеше килгән иде.

Уйнадык, җырладык, биедек – бик күңелле булды. Кызганыч, быел мәгълүм сәбәпләр аркасында, Сабантуй узмый калды.

Америкада яшәүче татарларның вотсапта үз төркемнәре бар. Шунда бик теләп аралашабыз. Пандемия вакытында хәтта Zoom платформасы ярдәмендә видеоконференция дә оештырдылар. Хәзер бер-беребезне күреп тә беләбез.

Уку системасына килгәндә, монда ул Россиядәгедән бик нык аерыла. Иң беренче эш итеп шуны әйтим: монда дәүләт балалар бакчалары юк, бары шәхси генә. Әниләр эшкә чыккан очракта, балаларны шунда бирәләр. Дүрт яшьтән соң балаларны мәктәп каршындагы классларга йөртергә була. Бу түләүсез, тик урыннар санаулы. Быел, мәсәлән, мондый класска керергә теләүчеләр шулкадәр күп булган, хәтта ата-аналарның гаризаларын лотерея форматында уйнатканнар. «Бәхетлеләр»не шулай билгеләгәннәр.

Балалар беренче сыйныфка алты яшьтән керә. Унбер ел укыйлар. Укулар тугызынчы яртыда иртәнге ашны ашаганнан соң башлана. Дәресләр өченче яртыга кадәр бара. Инглиз телен начар белү сәбәпле, безнең балаларга башта уку авыррак бирелде. Башка җирләрдән күчеп килгән балалар өчен инглиз телен аерым программа белән укыталар, сәгатьләр саны да күбрәк. Безнең балалар да шулай укыды, әле дә шулай дәвам итәләр. Хәтта җәйге каникулда да видео аша укытучылар элемтәгә чыга – инглиз телен шомарталар.

Россия белән чагыштырганда, Америкада балаларга өй эшләре бик аз бирелә. Дәрес әзерләү ун-унбиш минутны ала. Аны бала мөстәкыйль рәвештә үзе эшләп куя. Казанда яшәгәндә, өй эше белән сәгатьләр буе утырган Раил улыбыз мондагы рәхәтлеккә сөенеп бетә алмый.

Пандемия монда да яшәү рәвешен үзгәртте. Әйе, башка илләрдәге кебек, Америкада да бөтен кибетләр, күңел ачу үзәкләре ябылды. Маска-перчаткалардан йөри башладык. Кече эшмәкәрлеккә бик авырга туры килде. Хәер, ишеткәнемчә, зур-зур кибетләр дә бөлгенлеккә төште. Һичшиксез, халыкның матди хәле авырайды.

Безнең гаиләгә пандемиянең тискәре нәтиҗәсе булмады, шөкер. Ирем ничек эшләсә, шулай эшләвен дәвам итте. Алар хезмәт куйган оешма ябылмады, өйдән эшләделәр. Балалар да март аеннан башлап онлайн рәвештә укыдылар. Уку елын җай гына тәмамладык.

Белгәнемчә, пандемия вакытында эшсез калган кешеләргә дәүләт пособие түләде. Аның күләме хезмәт хакына бәйле. Мисал өчен, бер танышым атнасына 1 мең доллар алып торды. Дәүләт апрель аенда 2018-2019 нчы елларда салым түләгән һәр олы кешегә (Америка гражданы булмаса да) - 1200 доллар, балаларга 500 доллар акча бирде. Шушы көннәрдә һәр укучы бала исеменә 416 доллар салынган карта килде. Бу акчаларга без азык-төлек алырга тиешбез, карта алты ай дәвамында гамәлдә.

Тагын ике ай дәвамында һәр теләгән кешегә бушка ризыклар тараттылар. Аның аерым билгеләнгән сәгате бар иде. Машина килеп туктый. Анда киң таралган ризыклар – коры иртәнге ашлар белән бергә, сөт, йомырка, балык, консервланган азык-төлек тә бар иде. Балалар мәктәптә укымаса да, һәр көнне мәктәпкә иртәнге, төшке ашны барып алырга мөмкин булды.

Хәзерге вакытта хәл тотрыкланды дисәм була. Парклар, сәүдә үзәкләре ачылды. Рестораннар хезмәт күрсәтә башлады. Ләкин әле һаман җәмәгать урыннарында маска-перчаткалардан йөрү мәҗбүри.

Сагынуга килгәндә... Баштагы мәлдә бик еладым. Ник кенә туган якны ташлап киттек, дип, бәргәләнгән чакларым еш булды. Әнине, туганнарны, дусларны бик сагындым. Аллага шөкер, хәзер тынычландым инде. Күңелне тырный торган бердәнбер әйбер – әниемне бик сагынам. Көн саен видеоэлемтә аша сөйләшсәк тә, барыбер ул җитми...

Америкага күченгәнебезне белгән танышлар: «Вәт, сезгә бәхет елмайган», – диләр. Әйе, биредә яшәргә җиңелрәк кебек. Тик һәр нәрсәнең уңай, тискәре ягы була. Монда да шулайрак. Бүтән мохит, бүтән кешеләр...

Мохит дигәннән, биредә балалар өчен уен парклары шулкадәр күп, кайсына барырга белмәссең. Алар бик яхшы җиһазландырылган. Мисал өчен, безнең балалар җәй буе фонтанлы мәйданда яттылар. Ул резинадан эшләнгән, суы җылы. Шунда бала-чага су коена, уйный.

Укулар беткәч (биредә уку елы июнь азагына кадәр бара), балалар белән ике айга Казанга кайтырга теләгән идек. Пандемия аркасында килеп чыкмады. Әле каенанам белән каенатам да биредә. Балаларын күрергә дип Америкага февраль аенда ук килгәннәр иде. Юллар ябылу сәбәпле кайта алмый калдылар. Бер караганда, аның шулай булуына сөендек тә. Каенанам белән каенатамның яше җитмешкә җитеп килә, үзизоляция шартларында Казанда аларга кыенрак булыр иде, ашарларына, даруларга чыгарга уңайсыз булыр иде, дибез. Яннарында ярдәм итәр кешеләре юк.

Гаиләдә татарча, русча аралашабыз. Казаннан китаплар алып килдек. Балалар туган телләрен онытмасыннар, дибез. Минем әле инглиз телем һаман начаррак, чөнки аралашу юк. Ә балалар ике ел дигәндә рәхәтләнеп инглизчә сөйләшәләр. Шулай итеп, безнең гаиләдә өч тел яши – татар, инглиз, рус телләре... ■

Әзерләде: Руфия Фазылова

ОНЛАЙН БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ОНЛАЙН-ЭКСКУРСИЯЛӘР ТУРЫНДА



Гүзәл Хисмәтуллина, бизнес-тренер һәм TeamSoft компаниясенә нигез салучы, – без булган урыннарны да, без булмаганнарын да ничек итеп яхшырту турында.

– Без көтмәгәндә генә ике төрле дөньяда яши башладык: реаль һәм виртуаль. Һәм бу виртуаль дөньяның үз өстенлекләре булуы ачыкланды.

Өйдә, диванда утырган килеш кенә, дөньяның иң яхшы концерт мәйданчыкларында булырга, театраль куелышлар карарга яки үзеңнең онлайн-туган көнеңә Җир шарының төрле почмакларыннан туганнарыңны чакырырга мөмкин.

Әйе, син әле тагын Париж урамнары буйлап онлайн-экскурсияләргә йөри яки Һинд океаны ярында үткәрелгән онлайн-медитация вакытында күкрәгеңне тутырып диңгез һавасын сулый аласың.

Һәм бу хис-кичерешләр телевизордан трансляция караудан күпкә текәрәк.

Һәм, әлбәттә, хәзер теләсә кайсы татар, дөньяның кайсы почмагында булуына карамастан, онлайн-Сабантуйда катнаша ала.

Ә йоклар алдыннан китап укырга хәзер газиз әниең генә түгел, ә Чулпан Хаматова яки Алиса Фрейдлих килә ала, теләсәң, сиңа Салават үзе «бишек» җырын башкара…

Болар барысы да бер хакыйкатьне ачып бирде – безнең бергәләп бәйрәм итү, сәяхәт кылу, күңел ачу һәм ял итү мөмкинлеге булырга тиеш, һәм без хәзер болардан баш тарта алмыйбыз инде…

Дөнья безгә хәзер якынрак һәм аңлаешлырак була башлады һәм кайвакыт башка илдәге берәү белән онлайн очрашу оештыру, күршең яки бер үк шәһәрдә яшәүче дустың белән күрешүгә караганда, күпкә җиңелрәк булып чыкты.

Ләкин тере аралашуны бернәрсә дә алыштыра алмый-тәмле бәлеш пешереп, камера каршына дусларын яки туганнарын чакырган кешеләрнең күбесе әнә шул турыда әйтә.

Әйе, хәзерге вакытта бер өстәл артында утыра алмаганга күрә, бераз моңсу, әмма без бергә, без янәшә…

Һәр медальнең ике ягы бар. Һәм кимчелекләр дә җитәрлек.

Дөнья бик тиз үзгәрергә мөмкин икән – без моны бүгенге заман шартларында үз күзләребез белән күрә алдык.

Ә дөнья үзгәргәндә, без аның белән бергә алга таба бер адым ясыйбыз, чикләрне узабыз, яңалыкларга өйрәнәбез, үзебез дә үзгәрәбез.

Шул рәвешле кемнәрдер үткәннәрне югалтудан моңсуланып яшәсә, икенчеләре исә яңа мөмкинлекләр ача.

Безнең сайлау мөмкинлеге туды.

Һәм сайлый алуның кыйммәтен тагын да ныграк аңлый башладык. Шул ук вакытта без сәламәтлек, гаилә һәм көнкүреш ыгы-зыгысында онытылып торган башка кыйммәтләрнең безнең өчен никадәр мөһим булуына инандык.

Хәзер без үзебезне чынбарлыкта да, виртуаль дөньяда да бертигез рәхәт хис итә алабыз.

ТЕРЕ ЭНЕРГЕТИКА ДОНАТЛАРДАН ШӘБРӘК



Антон Салакаев, «Волга-Волга» ВИАның художество җитәкчесе һәм солисты, – онлайн концертка күпме тамашачы җыеп булуы һәм моның ни өчен мәңге дәвам итә алмаячагы турында.

– Бу коронавирус безнең барыбызны да нык кына уятып җибәрде. Иң гаҗәбе шул: без анда күп кенә плюслар да таптык – бу урында мин, әлбәттә, авырулар һәм иң аяныч нәтиҗәләр турында әйтмим...

Вирус турыдан-туры кагылмаган кешеләр үз көчләрен, үз мөмкинлекләрен булдыра алган кадәр тупларга тырыштылар һәм, мөгаен, бизнесларын, эшләрен тагын да активрак алып бара башлаганнардыр. Чөнки тиз арада тулы изоляция шартларында яшәүнең, эшләүнең һәм акча табуның җиңел түгеллеге ачыкланды.

Онлайн-концертларны бушлай башлап җибәрдек – үз формабызны саклап калу өчен дә, җанатарларыбызга ярдәм буларак та, аларга без монда, янәшәдә дип әйтү өчен дә.

Соңыннан без онлайн-концертлар белән акча эшләп булуын да аңладык. Барыннан да элек, бу, кем әйтмешли, донатлар белән бәйле тарих иде. Син аерым ресурсны тоташтырганда, теләсә кайсы тамашачы акча күчерә ала.

Шул ук вакытта син, офлайн-концертлардан аермалы буларак, билгеле бер бәя күрсәтмисең. Анда бит син билет сатып аласың һәм концертка арзанрак бәягә эләгә алмыйсың – билетның бәясе бар. Онлайнда исә һәркем бәяне үзе билгеләде.

Кемдер 50 сум җибәрде, кемдер – 100 не. Берничә мең сум, хәтта берничә дистә мең сум җибәргән кешеләр дә булды.

Акча эшләүнең мондый ысулын куллану яшәргә хаклы. Мондый онлайн-чыгышларны нигездә үз интернет-ресурсларында оештырганда, эш башка. Анда сиңа язылган кешеләр була. Һәм, әлбәттә, концертны бер тапкыр донатларга куйсаң, икенче тапкыр донатларга куйсаң, без бердәй җыемнарга өмет итә алмыйбыз. Алар кимегәннән кими барачак. Бу мантыйкка туры килә торган хәл. Гадәти чыгышлардан аермалы буларак, донатлар белән даими акча эшләп булмый. Бу вакытлыча хәл. Әмма шул арада без акчаны үзебез өчен генә җыеп калмадык. «Волга-Волга» берничә тапкыр хәйрия чыгышлары да ясады – дәвалануга яисә махсус җиһазлар сатып алуга мохтаҗ авыру балаларга акча җыйдык. Җыелган акчаларны хосписта тәрбияләнүчеләр өчен Анжела Вавилова фондына күчердек.

Безнең өчен тагын бер кызыклы тәҗрибә – онлайн-корпоративларда катнашу булды. Корпорацияләр өчен без берничә концерт бирдек инде. Мәсәлән, Уралдагы бер металлургия компаниясе өчен уйнадык, алар оффлайн концерт планлаштырган булганнар, нәтиҗәдә һәркем концертны үз өендә – онлайн карады.

Безнең тагын берничә глобаль проектыбыз булды, алар буенча төркемебез Россия һәм Татарстанның зур платформаларында чыгыш ясады. Болары бушлай, үз иҗатыбызны алга җибәрү максатында. Мондый концертларны караучылар саны 500 000 гә кадәр җитте.

Быел без үзебезнең бишенче «Волга-Волга» фестивален онлайн ысулда үткәрдек. **Узган ел ахырында без проект ребрендингы, яңа формат турында хыялланган идек, әмма аның безнең өчен никадәр яңа һәм гадәти булмаячагын күз алдына да китермәгән идек.**

Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгы ярдәме белән без яңа мәйданчыкта искиткеч сәхнә эшләдек. Яктылык, тавыш куелды, бик күп операторлар эшкә кушылды. Фестиваль программасында 20 башкаручы катнашты. Безгә «Безнең Татарстан» рәсми платформасы ярдәм итте.

Фестивальне 500 000 ләп тамашачы карады. Оффлайнда без бу кадәр тамашачыны җыя алмас идек. Бу яшь коллективлар өчен бонус булды. Онлайн-формат безгә фестивальнең стиль юнәлешен киңәйтергә булышты. Гадәттә без рок-стилистикада эшләсәк, быел барлык стиль һәм юнәлеш вәкилләрен чакырдык. Техно да, электрон музыка да, татар башкаручылары да булды. Тик тере зал энергетикасы гына булмады.

Гомумән, онлайн темасы кызыклы, әмма бу даими булачак, ул «сәүдәне алга этәрүче» дияргә ярамый. Кешеләр иртәме-соңмы сине карамый башлаячак – «һаман шул ук нәрсә» диячәк. Музыкант ай саен яңа альбом чыгара алмый бит – бу физик яктан мөмкин түгел.

Аннары артистларны терелэй күрмәгәндә, телевизор яисә компьютер экранынннан гына караганда, тиешле нәтиҗәгә ирешелми – тере тавыш, җанлы аралашу юк. Мондый режимда ике-өч ай яшәү – бер хәл. Әмма моны кешеләр белән даими аралашу яисә акча эшләү чарасы итү турында сүз алып барырга ярамый.

Без барысы 10 онлайн-концерт куйдык. Бу бик яхшы тәҗрибә булды. Бәлки әле айга бер яки ике тапкыр онлайн-концертлар куюны һәм яңа җырлар һәм программалар күрсәтүне дәвам итәрбез. Мөгаен, ул бушлай булыр. Өстәвенә, хәзер яңадан гастроль тормышы көйләнә башлады, һәм без моны эшли алырбыз кебек.

Гомумән алганда, бу вакыт арасында онлайн-концертлар безгә мораль яктан бик булышты. Без кешеләрнең аларны кызыксынып каравын тоеп тордык. Музыкантлар да студиядә очрашу, бу программаларны әзерләү мөмкинлегенә ия булды. Дөресен әйткәндә, иҗади планда без карантинны тоймадык – даими рәвештә нәрсә беләндер шөгыльләнергә, нидер уйлап табарга, төрле проектларда катнашырга кирәк булып торды.

«КЕРӘШӘ»ләр килде!

Бу чын мәгънәсендә югары пилотаж үрнәге иде – башка эпитетлар кирәк тә түгел. Алты ‹‹МиГ-29››ның Казансу өстендә ясаган могҗизаларын күзәтеп торган тамашачыларның хис-тойгылары шулкадәр көчле иде, аларны хәтта битлекләр дә яшерә алмады.

Атаклы «Керәшә»ләр («Стрижи») пилотаж төркеме чыгышы Казанда 25 июльдә узган «Мин күкне сайлыйм» традицион бәйрәменең бизәгенә әйләнде. Үз эшенең осталары идарә иткән «Миглар» югары оешканлык һәм маневрлык үрнәген күрсәтте. Сәгатенә 700–800 километр тизлектә очканда, ике янәшә машинаның канатлары арасында нибары бер метр ераклык калган мизгелләрдә, очкычлар синхрон рәвештә, бер механизм кебек, күкне сөзде, «бочка», «үлем элмәге» һәм башка шундый катлаулы элементлар ясады. Аннары җилпәзә кебек күк йөзенә чәчелде, ләкин, тамашачыны сокландыруын дәвам итү өчен, берничә мизгелдән тагын бергә кушылды.

«Беренче очыш» төркеменең чыгышы да тамаша ягыннан «керәшә»ләрдән калышмады. Илебез һәм халыкара ярышларда югары пилотаж җиңүчеләре авиация акробатикасы буенча ирешкән класс дәрәҗәләрен чираттагы тапкыр раслады, үзләреннән соң күктә символик язу да калдырды: «100 лет ТАССР» – быел бәйрәм нәкъ менә ТАССРның 100 еллыгына багышланган иде. Аның төп өлешендә Татарстанда эшләнгән стратегик ракета йөртүче Ту-160 «Аккош»ы һәм илнең оборона нигезе булган Ту-22М3 очкычлары катнашында һава парады узды.



«ТАТЭНЕРГО» ЯШЬЛӘР ПЛАНЕТАСЫ

Иң зур энергетика компанияләреннән саналган «Татэнерго» АҖ компаниясе яшьләре, тармак гигантларының күпчелеген артта калдырып, РФ Энергетика министрлыгының Бөтенроссия конкурсында «Яшьләр сәясәте» номинациясендә җиңү яулаган.

Компаниянең яшь кадрлары – 1500 гә якын кеше – оешмада эшләүчеләрнең 30 процентын тәшкил итә. 2019 елда гына да яшьләр өчен 239 чара үткәрелгән. Яшь кадрларны мондый кайгырту генераль директор Рәүзил Хаҗиев казанышы булып тора, ул яшьләр белән стратегик хезмәттәшлекне өстенлекле юнәлешләрдән берсенә саный.

Уңышлар һәм һөнәри бәйгеләрдә җиңүләр «Татэнерго» АҖ яшьләр оешмасы активистлары командасының бердәм тырышлыгы нәтиҗәсе булып тора. Җитәкчеләре – «ТР предприятие һәм оешмалары яшьләре берлеге» Советы рәисе, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләренең «XXI гасыр лидерлары» XV Бөтенроссия конкурсы җиңүчесе Айдар Сәгыйтдинов. Инициативалы яшь егетне җитәкчелек тиз арада күреп ала һәм аның алдына шактый катлаулы бурыч куя. Нәтиҗәле эшне тиз арада спортчыларча һәм системалы оештырып, Айдар аны уңышлы үти. 2015 елда ул «Татэнерго» АҖ идарәсенең беренче спартакиадасын оештыра, һәм шул вакыттан бирле үзен җәмәгать эшеннән башка күз алдына да китерә алмый.

– Спорт ярышларында һәм үзешчән сәнгатьтә мин иң баштан ук үзем дә катнаштым, чөнки шәхси үрнәк уңышлы эшнең нигезен тәшкил итә, – дип сөйли Айдар. – Һәм бу эш мине үзенә суырып алды. Яшьләр сәясәте нәтиҗәсендә һәм җитәкчелек ярдәме белән безнең кадрлар карьераларында уңышка ирешә. Кешеләрдә җаваплылык хисен, командада эшләү күнекмәләрен һәм инициатива күрсәтүне яратам, чөнки без, яшьләр, идеяләрне үзебез дә тәкъдим итәргә тиеш!

Яшь кадрлар эштән соң да үзара аралашуны дәвам итә, һәм җитәкчелек актив энергетикларның теләсә нинди башлангычларын хуплый. Үз эшен моннан өч ел элек иҗат конкурсында катнашудан башлаган, «Татэнерго» АҖ идарәсе яшьләр комитеты рәисе, «Талантлар университеты» остаз-эксперты Борис Гурулевны да хәзер инде компаниянең яңа әйдаманнарыннан берсе дип атап була.

– Бу бик кызыклы эш, – ди Борис. – Моңа кадәр мин Яр Чаллы Җылылык электр станциясендә хезмәт куйдым, анда да КВНда, шәһәр чараларында гел катнаша идем. Яшьләрнең барлык тәкъдимнәре, ярыш рухы минем өчен бик мөһим.

Казан ТЭЦ-1 яшьләр оешмасы рәисе, компаниянең Казан зонасы буенча рәис урынбасары Регина Мөхәммәтханова яшь кадрларның ачык вәкиле булып тора. Ике кыз үстерә, компаниягә ул декрет ялыннан соң әйләнеп кайткан. Һәм шундук коллегаларыннан куәтле уңай көч алган – аны компаниянең барлык филиаллары яшьләр оешмаларының яңа берләштерелгән структурасына эшкә чакырганнар. Нәтиҗә күз алдында: Регина – «Һөнәрендә иң оста» шәһәр конкурсының җиңүчесе, республика бәйгесенең призеры.

– Тормыш гөрли: бездә бик күп төрле чаралар үткәрелә. Компаниянең генераль директоры Рәүзил Мәгъсумҗан улы безгә зур ярдәм күрсәтә, – ди Регина, елмаеп. – Безнең проектлар арасында түбәндәгеләрен аерып күрсәтеп була. Балаларны яклау көненә без «Татэнерго»да эшләүчеләрнең мәктәпкәчә яшьтәге сабыйларына тәгаенләнгән «Балаларга энергетика турында» китабын әзерләп бастырдык, «Территория смыслов» форумында катнаштык. Бу искиткеч аралашу тәҗрибәсе һәм көчле эмоцияләр бирә, нәкъ менә шуның өчен без үз эшебезне яратабыз да.

Казан җылылык челтәрләре яшьләр комитеты рәисе Гөлшат Хәкимҗанова, яшьләр оешмасында 2015 елда форумда катнашканнан соң, илһамланып эшли башлаган. Ул һәрвакыт актив составында булган, соңгы вакытта исә чараларны оештыру эшендә дә күбрәк катнаша:

– Безнең арада яңа кешеләр пәйда була тора, һәм миңа аларның безгә ярдәм итәргә теләве ошый. Бу аңлатып булмый торган рәхәт хис – кешеләрне җәлеп итү һәм кире элемтәне күрү. Хәзер без ТР Яшьләр эшләре министрлыгының грантын откан «Татэнерго» яшьләр премиясе» проектын әзерлибез.

Филиаллардагы барлык активистлар да коллектив өчен Май чабудан башлап Яңа елга кадәр бөтен бәйрәмнәрне әзерли, Минзәләдәге интернат-мәктәпкә шефлык итә, мәктәпләрдә энергияне саклауга багышланган һәм экология дәресләре үткәрә, пенсионерлар турында кайгырта. Һичшиксез, яшьләр оешмаларында эшләү кешене еш кына бөтенләй башка яктан ача һәм аның һөнәри үсешенә ярдәм итә.

Чыннан да, компания җитәкчелегенең һәм шәхсән Рәүзил Хаҗиевның яшьләр инициативаларына игътибары күп оешмалар кызыгырлык. Яшьләрнең торак шартларын яхшыртуда катнашу да, спорт инвентарен сатып алу да, командировкалар өчен түләү дә моңа дәлил булып тора. Хоккей командасын җыю, корпоратив форма тегү һәм барлык шартлар белән тәэмин итү кирәкме? Бусы да проблема түгел!

«Татэнерго» компаниясенең данлыклы команда рухы шулай формалаша. Бирегә Татарстан яшьләре үз иҗат потенциалын тулысынча ача ала.

Реклама. Фото «Татэнерго» АҖ тарафыннан тәкъдим ителде

ТАЛАНТЛАР УНИВЕРСИТЕТЫ

2015 елда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме буенча «Талантлар университеты» төзелгән иде. Хәзер инде порталында 70 меңнән артыграк кулланучы булган әлеге университет яшь татарстанлыларга остазлар ярдәмендә уңышка ирешергә ярдәм итә.

Университет һәр яшь татарстанлының интеллектуаль-иҗат потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру максатыннан булдырылган иде. Барлык студентларның да үз белеме белән уртаклашучы остаз-белгече бар, ул һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер һәм шәкертләрен һөнәри бурычларны үтәргә илһамландырып тора. Аның белән бергә студент үзенең шәхси планын төзи һәм гамәлгә ашыра, бу вакытта үзенең алга китешен күзәтә һәм тәҗрибәлерәк кешедән кирәкле ярдәм ала. «Талантлар университеты» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләренең интеллектуаль-иҗат потенциалын үстерүне күз уңында тоткан «Перспектива» концепциясен һәм «Татарстан Республикасында 2015–2022 елларда талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган булып тора. Бүгенге көндә «Талантлар университеты» – Татарстанда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә дә талантлы һәм сәләтле мәктәп балаларын һәм студентларны, остазларны, белгечләрне, ата-аналарны берләштергән зур команда. Мәсәлән, «Талантлар университеты» порталында 70 меңнән артыграк кулланучы теркәлгән, алар өчен 35 тән артыграк сервис булдырылган.

Кем университет студенты була ала соң? 12 яшьтән 30 яшькә кадәрге мәктәп укучысы, студентлар һәм яшь белгечләр, шулай ук әле 35 яше тулмаган галимнәр. Бирегә Конкурс чаралары республика реестрына кертелгән олимпиада һәм конкурсларда җиңүчеләр яки призлы урыннарга лаек булучылар кабул ителә. «Талантлар университетының» барлык белем бирү программалары актуаль, һәм алар компанияләр, республиканың әйдәп баручы югары уку йортлары белән берлектә формалаштырыла – аны тәмамлаучыларга соңыннан эш урыннары гарантияләнергә тиеш. Студентларның шәхси үсеш планнары дүрт база шартын истә тотып төзелә: үзеңне кызыксындырган тармакта иң шәп белем алу; үзеңнең көчле якларыңны һәм «үсеш зоналарын» белү һәм аңлау; үзеңне һәм үз компетенцияләреңне реаль проектларда сынау; үзеңә һәм әйләнә-тирә мохиткә рефлексив караш. Аеруча мөһиме шул: һәр студент компетенцияләрне үстерү өчен үзенә белем алу программасын мөстәкыйль сайлый – тәкъдим ителгән вариантлардан сайлап ала яки үзе мохтаҗ булганны сорый.

Укыту процессында студентларга остазлары – педагоглар, галимнәр һәм махсус укытылган һәм яшьләрнең һөнәри үсешендә катнашырга әзер булган башка белгечләр ярдәм итә. 2015 елдан бирле остазлык программалары буенча 5 меңнән артыграк педагог һәм предприятие белгече укытылган. Мондый үзенә күрә квалификацияне күтәрү остазларга балалар белән эшкә яңача карау, үз компетенцияләрен яхшырту һәм мәгариф процессына инновацияләр кертү мөмкинлеген бирә.

– 2015 елда мин «Талантлар университеты» остазларының ачык бергәлегенә кушылдым һәм «Талантлар җитештерү белән идарә итү» курсы кысаларында «Тренерлар өчен тренинг» модулен үттем. Миңа үз эшемдә ярдәм итә торган һәрнәрсә мөһим. Бирегә миңа экспертлар белән танышу һәм эшләү, фикердәшләр бергәлегенә керү мөмкинлеге туды. Күреп торам: белем бирә торган модульләрне үткәннән соң, остазлар бергәлегенә кергән укытучыларның

Реклама. Фотолар «Талантлар университеты» тарафыннан тәкъдим ителде

балалар белән эшләүгә карашы үзгәрә. Алар мәктәп баласын башкача кабул итә башлый һәм укучыны яңа дәрәҗәгә күтәрә, – ди «Талантлар университеты» остаз-белгече Ольга Антипина.

Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче яшь белгечләр белән эшкә аерым игътибар бирелә. Алар мастер-класслар, дистанцион форматта лекцияләр үткәрә, университет студентларын төрле юнәлешләрдәге иң шәп халыкара практикалар белән таныштыра. Дәүләт программасының иҗтимагый-һөнәри экспертизасын «Тататлар университетының» фәнниэкспертлар советы үткәрә. Әлеге мөһим органга әйдәп баручы галимнәр, эш бирүчеләр, социаль-икътисади тормышның төрле тармакларына караган инновацион эшкуарлар керә. Экспертлар бергәлеге лидерларының күп булуы дәүләт программасын гамәлгә кертүнең даимилеген һәм бәяләү сыйфатын тәэмин итә.

«Талантлар университеты» коллективының чагыштырмача яшь булуына карамастан, инде бүген үк аның эше иң югары дәрәҗәдә танылган һәм педагогик процесс өчен үрнәк булып тора. Мәсәлән, 2018 елда университет остазларын әзерләү һәм үстерү практикасы Стратегик инициативалар конкурсында Идел буе федераль округында иң яхшы дип табыла. 2019 елның 12 мартында исә Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Советы утырышында сәләтле һәм талантлы балалар-яшьләр белән эшләү буенча Татарстан Республикасы тәҗрибәсе «Талантлар университеты» мисалында презентацияләнә. 2019 елның июнендә Rukami идеяләр һәм технологияләр фестивале үткәрелә, шул ук елның 5 декабрендә исә Сочидагы «Глобаль технологик лидерлык» форумында «Талантлар университетының» технологик энтузиастлар әзерләү буенча практикасы Rukami проектыннан номинациядә иң яхшы дип табыла. Бу күпсанлы казанышлар һәм уңышлар стратегиянең нәтиҗәлелеге һәм яшь буынны укытуда дөрес сайланган юл турында сөйләргә мөмкинлек бирә.

> Университет эшчәнлеге нәтиҗәсендә республиканың иң сәләтле балалары, иң кыю һәм эшлекле яшьләре, үзләренә дөрес һөнәр сайлау, тормышта үз юлларын табу, үзләрен ачу, югары хезмәт баскычларына ирешү мөмкинлеге ала.

УНИВЕРСИТЕТ ТАЛАНТОВ
КАЗАНЬ

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин фәрманына ярашлы рәвештә илдә «Сириус» белем бирү үзәге моделе буенча төбәк үзәкләре оештырыла. Мәсәлән, 2019 елның 28 маенда Татарстан Республикасы Хөкүмәте белән «Талант һәм уңыш» мәгариф фонды арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланган. «Талантлар университеты» базасында «Сириус» үзәге моделе буенча сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга булышу максатыннан республика үзәге формалаша. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Республика олимпиадалар үзәгенең «Дуслык» сәламәтләндерү-укыту комплексы моның өчен төп мәйданчык булып тора. 2020 елның 1 июненнән өч юнәлеш – фән, сәнгать, спорт – буенча үзәкнең профильле сменалары эшли башлаган. Кызыксынган мәктәп балаларының һәркайсы сайлап алу турын үтәргә һәм аларда катнашырга мөмкин.

Республика үзәгенә ярдәм «Мәгариф» милли проекты кысаларында тормышка ашырыла, аның буенча профильле программаларны үткәрү өчен югары технологияле җиһазлар һәм инструментарий сатып алына. «Сириус» моделе буенча республика үзәге төзелү оешма үсешендә мөһим этапка әйләнә. Ел дәвамында 2 меңгә якын мәктәп баласы өч атналык профильле программаларда катнашачак. Әлеге проект балаларга Татарстан югары уку йортлары һәм компанияләренең әйдәп баручы галимнәре һәм белгечләре белән иңгә-иң куеп эшләү мөмкинлеген бирәчәк.

Университет эшчәнлеге нәтиҗәсендә республиканың иң сәләтле балалары, иң кыю һәм эшлекле яшьләре, үзләренә дөрес һөнәр сайлау, тормышта үз юлларын табу, үзләрен ачу, югары хезмәт баскычларына ирешү мөмкинлеге ала. Эш бирүчеләр һәм фәнни бергәлек остазлык институты ярдәмендә буыннар алмашын тәэмин итә һәм иртәгә яңа Татарстанны төзеячәк алмаш – булачак һөнәрмәндләр үсешен актив күзәтә.

РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН: ЧОРЛАРНЫ ТОТАШТЫРГАН ГЫЙЛЕМ ИЯСЕ

Автор: Илдус Заһидуллин

Ризаэтдин Фәхретдиннең беренче фоторәсеме. Уфа, 1892 ел.

Ризаэтдин Фәхретдин – татар тарихында җуелмас эз калдырган шәхес. Кадими мәдрәсәдә дини белем алган кеше ничек итеп энциклопедик характердагы, күпчелеге бүген дә чыганак дәрәҗәсендә файдаланырлык фәнни һәм публицистик хезмәтләр язарлык гыйлем иясенә әверелгән соң? Мәгърифәт таратучы мулла, гыйлемле казый, актив журналист һәм мөхәррир булып киткән? Бу язмабызда шушы сорауларга җавап эзләп карарбыз.

Ризаэтдин Фәхретдин биографиясенең мөһим этаплары ул яшәгән урыннар белән тәңгәл килә.

Беренче этапны авыл чоры дип билгеләргә мөмкин. Ул Ризаэтдиннең балачагын, үсмер, яшьлек, ир-егет булган елларын, 32 яшенә кадәрге гомерен үз эченә ала.

Икенче этап – беренче Уфа чоры (1891–1906), Мәхкамәи шәргыйядә казый булып эшләгәндә тарихчы, мәгърифәтче һәм язучы буларак танылу алган еллары.

Өченче этап – Оренбург чоры, Ризаэтдиннең башта «Вакыт» газетасы редакциясендә, 1908–1918 елларда мәшһүр «Шура» журналының баш редакторы булып эшләгән еллары.

Дүртенче, соңгы этап – икенче Уфа чоры (1918–1936). Дини идарәдә казыйлык, 1921 елдан мөфтилек вазыйфасын башкару вакыты.

Фотолар автордан алынды

БЕЛЕМГӘ СУСАУ

Ризаэтдин 1858 елның 31 декабрендә Самара губернасы Бөгелмә өязе Кичүчат авылының мулласы Фәхретдин Сәйфетдинов гаиләсендә дөньяга килә (этисе метрика кенәгәсенә 1859 елның 4 гыйнвары дип язган. Шушы дата рәсми кулланыла – авт.). 5–6 яшендә ул әнкәсеннән укырга өйрәнә, ә җиде яшеннән мәктәп бусагасын таптый башлый. Башта ике ел абзыйларына ияреп Түбән Шәнчәле (Чыршылы) мәдрәсәсенә йөри. 1867–1868 елларда уку елын Чистайда, җизнәсе Гыйльман Кәримигә ияреп барып Закир ишан Камалов мәдрәсәсендә үткәрә. Җизнәсе мулла булып билгеләнү сәбәпле укуын монда дәвам итә алмыйча, 1869–1889 елларда Түбән Шәнчәле мәдрәсәсенә кайта.

Шәкерт вакытында гадәт итеп алган үзлегеннән белем туплауны тормыш кагыйдәсе итеп, җитешмәгән гыйлемнәрне Ризаэтдин гомере буе җыйган.

Мәдрәсәдә вакытта хәлфә вазыйфасын башкарганда Фәхретдингә игътибар иттергән тырышлыкларының кайберләре – 1887–1888 елларда шәригать буенча мирас бүлү кагыйдәләре һәм гарәп теле морфологиясе уку әсбабларын бастыру.

Фәхретдиннең шәхес һәм голәмә буларак үсешенә берничә олуг шәхеснең хезмәтләре зур йогынты ясый. 1884 елның соңгы саныннан башлап «Тәрҗеман» газетасын даими алдырып, Исмәгыйль Гаспринскийның яңарышка өндәгән фикерләре белән рухланган. «Тәрҗеман»да күтәрелгән мәсьәләләрне фикерләп һәм үзе укыткан кадими мәдрәсәдә күңеле белән бәргәләнеп, ул публицистик рухта «Китаб әл-игътибар» (1888) исемле хезмәтен бастыра. Анда Фәхретдин халыкны алга җибәрү өчен мәгариф системасын яңарту проекты тәкъдим итә, гамәлдәгесенең укуны оештыру тәртибен һәм программаларын кискен тәнкыйтьли, рус гимназияләренә охшаш һөнәргә өйрәтә торган белем йортларын ачарга өнди, яңа тип мәктәпләрнең төп эшләү принципларын ачыклый: дөньяви фәннәрне балаларның туган телендә өйрәнү, аларны сәгатьләп укыту, сәгатьләп ял иттерү, билгеле бер вакытта үзләштерелгән белемнәрен бәяләү һәм таныклап бирү.

Фәхретдин Шиһабетдин Мәрҗанинең «Нәзурат әл-хак фи фәдийәт әл-гашаи вә ин ләм йагаб әш-шәфәкъ» («Эңгер-меңгер төшүдәгә бәйсез рәвештә кичке намазның кирәклеге турында хакыйкатькә бер караш») исемле хезмәте белән танышкач, мәдрәсәдәге остазы бу хәзрәтне дошман күрсә дә, алдагы елларда галимнең барлык яңа китапларын укып бара. 1886 елның җәендә Казанга барып, аның белән күрешә, ләкин хәзрәт шул көнне Буага никах мәҗлесенә китеп бару сәбәпле, аралаша һәм дәресен тыңлый алмый кайта. Ризаэтдиннең беренче китаплары белән танышкан Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) аның турында әйткән «Бу егет өметле. Мәсләгендә дәвам итсә, яхшы хезмәт итәр!» дигән сүзләре авторга вакытында килеп җиткән һәм аның күңелендәге иҗат ялкынын көчәйткән дип уйларга нигез бар.

Фәхретдин тормышында төп фикер алгарышы 29 яшендә – 1888 елның җәендә Санкт-Петербургта мөселман фәлсәфәчесе Җамалетдин әл-Әфгани белән аралашудан соң башлана. Шушы очрашу тәэсирендә хәлфә үзендә башланган үзгәрешне болай тасвирлый: «Мин Җамалетдин шәехтән ишеткән сүзләрнең хак булуына инандым, күп сүзләрнең мәгънәләрен аңлый башладым, аларны күңелгә салдым, мөстәкыйль рәвештә фән белән шөгыльләнә башладым. Аллаһка шөкер, мин үземнең инануларымны да тәртипкә сала алдым, гыйбадәт кылу һәм ураза тоту кебек бар гамәлләремне кабаттан тикшеп чыктым, төрле шәрехләрне, тәфсирләрне, аеруча хәдисләр гыйлемен, китапларны өйрәндем, вакытлы матбугат һәм яңа басылган әсәрләр белән шөгыльләндем». Нәкъ шушы очрашудан соң Фәхретдин үзенең мәгърифәтче һәм тарихчы буларак программасын кора, максатчан рәвештә үзлегеннән фән белән шөгыльләнә башлый.

Шушы белем һәм тормыш тәҗрибәсе белән 1889 елның җәендә Илбәк авылына гаиләсе белән күченеп, икенче имам вазыйфасына керешә. Үзенең мәгърифәтчелек программасын тормышка ашырып, берьюлы ике бина җитештерә: берсе – үзенең гаиләсе өчен йорт, икенчесе – мәхәллә балаларын укыту өчен мәктәп.

АБРУЙЛЫ ДИН ВӘ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Имамлык һәм мөгаллимлекнең мәшәкатьләреннән тәм табып мәгърифәт таратучы авыл мулласы гаме белән яшәп ятканда, Фәхретдин тормышында гаять зур үзгәреш була. Мөфти М. Солтанов, китаплары белән танышкач «бу яшь кешедә өмет зур, үзен табып китерегез дип», Ризаэтдинне сөйләшергә Уфага чакырта. Фәхретдиннең казыйлыкка риза булуының төп сәбәбе – гыйлем белән шөгыльләнергә мөмкинлек булмасмы дигән яшерен уй була.

Фәхретдин Мәхкамәи шәргыягә 1891 елны 20 февралендә килә. Шул ук елның җәендә аңа ахун дәрәҗәсе бирелә.

Уфага Фәхретдин гаиләсе – 1885 елда өйләгән хатыны, Чубыткы авылы ахуны Габденнасыйр кызы Нурҗамал, уллары Габдеррахман (1887) һәм Габделәхәд (1889) белән күчә. Уфада гаиләсе ишәя: Габдерәшит (1892), Зәйнәп (1893), Хәсән (1897–1899), Сәгыйть (1900), Хәсән (1901–1902) туа. Төпчек кызы Әсма, Оренбургка күченгәч, 1906 елның 28 июнендә дөньяга килә.

Биредә казый белемен арттыру юнәлешендә армый-талмый эшли. Беренче эш итеп, үзе әйтмешли, «мәдрәсәләрдә вакытымда китап күрергә хәсрәт чигеп гомеремне уздырганым өчен, тешем вә тырнагымнан арттырып» шәхси китапханә туплый башлый. Берничә елдан соң мәдрәсәдә вакытта бастырган китапларында җибәргән хаталарын күреп алып, гарәп, фарсы, төрек телләрен тирәнтен өйрәнә, русчасын шомарта.

Мөфти Солтанов эшне оештырганда казыйларның шәхси кызыксынуларын исәпкә алган, шулай ук аларга инициатива күрсәтергә мөмкинлек биргән. Фәхретдингә Мәхкамәи шәргыянең архивын тәртипкә китерү йөкләнә. Үзе бу хакта «Иске язуларны күрергә булган теләк вә борынгы кешеләр хәлләрен күз алдына китерәчәк мәгълүматны эченә алган кәгазьләрне киләчәк буын өчен саклап язып куюга булган мәхәббәт ошбу икътидарым өстендә булган хезмәткә керешүгә мине мәҗбүр итте», – дип яза.

Казыйның тагын бер бик мөһим эш юнәлешен гомумиләштереп «руханиларны тәртипләндерү» дип атарга мөмкин. Бу өлкәдәге эшчәнлегенә матур нәтиҗә булып 1898 елны дөнья күргән «Танзимат» исемле җыентыгы тора. Автор китапта Мәхкамәи шәргыя эшчәнлеге турында мәгълүматлар, метрика текстларын язу өчен үрнәкләр, яңа туган балаларга атап «матур исемнәр» исемлеге урнаштыра. Казый муллаларның җаваплылы-

Күренекле фикер иясе, дин галиме, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, язучы Ризаэтдин Фәхретдин 1887 елдан 1917 елга кадәрге актив иҗат чорында 65 китап бастыра. Октябрь инкыйлабыннан соң аның эш ритмы өзелә: 1936 елда вафат булганчы, башка китаплары басылмый, фәнни эзләнүләр белән шөгыльләнү мөмкинлеге дә нык чикләнә. Шуңа күрә аның иҗат мирасы турында сүз барганда, иң беренче чиратта, XIX–XX гасырлар чигендәге 30 ел вакытны күздә тотарга кирәк.

Ризаэтдин Фәхретдин гаиләсе белән. Сулдан уңга: Габдерәшит, Риза казый, Габдрахман, Зәйнәп, Габделәхәд, Нуржамал. Уфа, 1900 ел.

гын арттыру максатында руханиларны судка тарту турында дәүләт кануннарыннан өземтәләр, 1891–1896 елларда аның үзе тарафыннан язылган һәм Мәхкамәи шәргыя тарафыннан кабул ителгән муллаларның вазыйфалары, метрика тутыру Кагыйдәләрен һәм аларга югарыда аталган Өстәмәләрне, Эчке эшләр министры тарафыннан руханилар эшчәнлегенә кагылышлы яңалыклар кертүче һәм аларның хокукларын билгеләүче циркулярларның текстлары белән таныштыра.

Мәхкамәи шәргыянең эшләнлеген яхшырту турында уйлап, Фәхретдин 1905 елның 10–15 апрелендә мөфти чакыруы буенча Уфада узган голәмәләр корылтаена дини идарәнең яңа уставы проектын әзерли. Корылтай үзенең проектын Фәхретдин төзегән текстка нигезләнеп, аны төгәлләштереп һәм үзгәртеп эшләп чыга. Бу хезмәт казыйны руханилар арасында милләт күләмендәге ислам институтлары җитәкчесе, гыйлем иясе, чиновник, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе итеп таныта.

Казый булып торганда Фәхретдин Станислав лентасында муенга аса торган «Тырышлык өчен» көмеш (1894) һәм алтын (1897) медальләр белән бүләкләнә. 1905 елны аңа Николай II указы нигезендә 10 ел җәмәгать хезмәтен бик яхшы башкарганы өчен «личный почетный гражданин» дәрәҗәсе бирелә, шулай итеп ул крестьяннар түли торган дәүләт салымнарыннан азат ителә.

ФӘНГӘ ВӘ ӘДӘБИЯТКА ТУГРЫЛЫК

Казый 1897 елны үзенең тарих буенча беренче хезмәтен – Оренбург каласы янындагы Сәгыйть (Каргалы) турында китабын яза. Гыйльми эшчәнлеген дәвам итеп, ике сәяхәтнамә – Мәрҗанинең 1880 елны хаҗга сәяхәте һәм татар сәүдәгәре Исмәгыйль Бикмөхәммәтовның иптәшләре белән 1751 елда Сәгыйть бистәсеннән чыгып китеп, Бохарада, Һиндстанда, Госманлы дәүләтендә йөргәндә теркәп барган язмаларын эшкәртеп һәм шәрехләп бастыра.

Уфада галимнең киләчәктә яңа әсәрләр белән дәвам ителәчәк төп иҗат юнәлеше формаша. Ул да булса – мәшһүр шәхесләрнең тормыш юлларын өйрәнү һәм аларның тәрҗемәи хәлләрен бастыру.

Беренче юнәлешкә юл борынгыдан башлап XX йөз башына кадәр яшәгән мәшһүр шәхесләр хакында мәгълүматлар тупланган «Асар» исемле биобиблиографик хезмәттән башлана. Фәхретдин 1900 нчы елда дөнья күргән «Асар»ның беренче кисәгенә язган кереш сүзендә үзенең зур программа буенча эзләнүләр башлаганын шәрехләп, ахыргы максатын шушылай билгели: «Әдип вә галимнәре булмаган халык бәхетсез; мәшһүр кешеләрне оныткан халык сакланмас; әдәбияты булмаган халык рухсыз» диелгән сүз хәтерләрдә. Шуңа күрә халкыбызның мәшһүр кешеләрен җыеп таныту өчен ошбу китапны язарга ният иттем. Әсәр төрки-татар дөньясында зур дәрәҗә казанган хезмәт булып әверелә. Беренче һәм икенче томнарда һәммәсе 470 шәхеснең тормыш юлы тасвирланган.

1903 елны мөселман дөньясында билгеле хатынкызлар хакында («Мәшһүр хатыннар», 1903) хезмәтен бастыра, аларның тормышын үрнәк итеп китерә. Шулай ук яңа форматта, очерклар тибында, «Мәшһүр ирләр» – ислам дөньясының күренекле фәлсәфәчеләренә, дин галимнәренә багышланган хезмәтләргә дә алына. Авторның «Ибне Рөшди» (1905) исемле китабы шушы сериядән дип билгеләнә.

Фәхретдинның икенче бер максаты «җәдит рухлы яңа кеше тәрбияләү максатында әсәрләр язу» була. Җәмгыятьне белемле итү, рухи агарту һәм әхлакландыру буенча эшчәнлек, гомумән, мәгърифәтчелек идеологиясен пропагандалаган шәхесләргә хас. Моңарчы язылган хезмәтләрдән аермалы буларак, бу өлкәгә Фәхретдин алып килгән төп яңалык – үгет-нәсихәт педагогик алымы аша җәдитчеләр идеологиясен тарату: «камил кеше» формалаштыру, ягъни белемгә омтылучы, гыйлемен милләтне үстерү өчен кулланучы, эшчән, югары әхлаклы шәхес тәрбияләүне махсус төзелгән программа буенча тормышка ашырудан гыйбарәт. Автор тәрбия-әхлак темасына язган текстларын күп кисәкләрдән торган «Гыйльме әхлак» хезмәте дип атый.

Ул мөрәҗәгать иткән, үтемле сүз кулланып үзгәртергә омтылган объектларны гомумиләштереп, бер-берсенә бәйле булган ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Казый, беренче чиратта, төрле җенестәге һәм яшьтәге мөселманнарның тормыштагы статусына (кечкенә бала, мәктәп баласы, яшүсмер егет яки кыз, ялгыз яки гаилә корган, әти-әни булган) атап вәгазьләү-дидактик рухта хезмәтләр яза.

Икенче мөһим объект итеп җәмгыятьнең төп күзәнәге булган гаилә һәм гаилә әгъзалары алына. Авторның бу өлкәдәге иҗаты үз гаиләсе тәҗрибәсенә таянып, уларын һәм кызларын күздә тотып та язылган булуы текстларны тормышчан итә. Энциклопедик белемле, киң эрудицияле шәхес мәгърифәтчел позициядән

«Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы идарәханәсендә. Беренче рәттә (сулдан уңга): Габдрахман Фәхретдинов, Фатыйх Кәрими, Ризаэтдин Фәхретдин, Закир Рәмиев, Борһан Шәрәф; икенче рәттә: Рәкыйб Рәкыйби, Гыймад Акчура, Ярулла Вәли. Оренбург, 1915 (?) ел.

торып, яңарыш тарафдарлары арасында хатын-кыз хокукларын мөселман (татар) дөньясында беренчеләрдән булып яклап чыга.

Казыйның бу хезмәтләре мәктәп-мәдрәсәләрнең уку китабына әверелдергән, алар дистәләрчә тапкыр басылып, үсеп килүче берничә буынны XX гасыр башында җәдитчелек идеологиясе кысаларында әхлакый һәм рухи тәрбияләүдә зур роль уйнаганнар.

Риза Фәхретдин мәгърифәтчелек идеяләренә нигезләнгән ике повесть иҗат итә: «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1898), «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903). Бу әдәби әсәрләрдә европача белем алган, гаилә анасы гына булмыйча, милләт анасы булырга лаеклы идеаль хатын-кыз образы тудырыла, һәр кеше тормышта эш-гамәлләренә лаек бәяне ала дигән фикер уздырыла.

ҮЗ ЧОРЫНЫҢ ИНТЕЛЛЕКТУАЛЫ

Күренекле татар байлары бертуган Закир һәм Шакир Рәмиевләр чыгара башлаган «Вакыт» газетасында эшләргә чакыруны кабул иткәч, 47 яшьлек Фәхретдин барлык вакытын яраткан шөгыленә багышлау мөмкинлеге ала.

Фәхретдин 1909 елны «Асар»ның 204 күренекле шәхеснең тормышлары хакында текстлар урнаштырылган 3 нче томын тәмамлый. «Мәшһүр ирләр» баш астында атаклы ислам дөньясы философлары һәм интеллектуаллары тормыш юлларын яктырткан «Әбел-Галәэ әл–Мәгарри» (1908), «Имам Газали» (1909), «Ибне Тәймия» (1911), «Ибне Гарәби» (1912) китапларын бастыра. Биредә аның шушы юнәлештә язылган Мөхәммәт пәйгамбәр тормышына багышланган китабын (1908), «Ибне Гарәбшаһ» (1909), «Әхмәд бай» (1910), «Әхмәт Мидхәт әфәнде» (1913), «Шәйхе Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» (1917) хезмәтләрен дә әйтеп китми мөмкин түгел.

Рәмиевләр, Фәхретдиндә зур интеллектуал мөмкинлекләре барлыгын күреп, 1908 елны аның өчен махсус «Шура» журналын ачалар һәм финанслыйлар, баш редактор дилбегәсен галимгә тапшыралар. Фәхретдиннең «Шура»да төрле темаларга багышланган 300 дән артык мәкаләсе басыла. Бу хисапка әле төрле белешмә-мәгълүматлар, кечерәк рецензияләр керми.

Фәхретдиннең Оренбург чоры иҗатында ислам дине нигезләрен пропагандалау һәм дини-теологик хезмәтләр язу яңа күренеш буларак бәяләнергә хаклы. Хәдис гыйлеменә багышланган «Җәвамигуль-кәлим шәрехе» исемле дини-теологик хезмәте (1908) татар дини һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикеренең әһәмиятле бер ядкаре булып санала.

Баш редакторның «Шура»да басылган күпсанлы публицистик мәкаләләре аны XX гасырның күренекле галиме, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе дип таныта. Алар татар иҗтимагый фикере үсешен һәм җәмгыятьтәге мәдәни барышны өйрәнү өчен мөһим чыганак булып тора.

«ӘМАНӘТЛЕ ҺӘМ ТУГРЫ СҮЗЛЕ ЗАТ»

Мөселманнар тарафыннан беренче тапкыр сайланган мөфти Галимҗан Баруди Фәхретдингә биргән тирән эчтәлекле бәясендә болай дип яза: «Гыйльми куәте яхшы, гарәп телен белүе төзек, иң мөһим булган хәдис гыйлемен белүче, юлы һәм дөрес рәвеше белән яхшы исем хасил иткән. Ислам тарихында, аеруча галимнәр тормыш юллары турында яхшы мәгълүматы бар. Бу илләребездә (Казан, Болгар һәм Кыпчак вилаятендә) үткән галимнәр һәм мәшһүр затлар хакында гүзәл әсәрләре бар. Диндә һәм иманда ныклы, дини вазыйфаларында тугры, әхлагы сабыр, чыдамлыгы күркәм, аз сүзле, күп эшле, һәркемгә хәерлек теләүдә, әманәтле һәм тугры сүзле зат». Ләкин Октябрь инкыйлабы киләчәктә аның галимлек эшчәнлегенә балта чаба.

Яңа хакимият элеккеге вакытлы матбугатны тыя. Яшәү өчен чыганаксыз калгач, ул беренче Бөтенрусия мөселманнары съезды карары нигезендә (1917 елның 1–11 май көннәре) казый итеп сайланудан файдаланып, Уфага күченә. Галимҗан Баруди авырганда һәм аның вафатыннан соң, авырсынып булса да, мөфти вазыйфаларын башкара. 1922 елны үзен мөфти итеп сайлангач, большевикларның ислам институтларын, дини традицияләрне тар-мар итеп юкка чыгаруының шаһиты була: яклау сорап зар елаулар мәхәлләләрдән Диния нәзарәтенә агыла гына.

Советлар илендә аның хезмәтләренең дә, галим буларак үзенең дә кирәге калмый. Бер китабы да үзе исән чагында совет хакимияте елларында кабат басылмый. Большевикларга Фәхретдин мөфти сыйфатында мөселман дөньясының данлыклы һәм абруйлы шәхесе буларак кына кирәк була. Кызы Әсма әтисенең: «Язган китаплар искә төшерелми, берәр нөсхә булган әсәрләр юкка чыгачак, исәнлекне кызганмыйча эшләүләр үз халкыбыз өчен файдасыз калыр», – дип ачынып әйткән сүзләрен китерә.

Әлбәттә, ул күпмедер дәрәҗәдә гыйльми эзләнүләрен дәвам итә. Ләкин гомерен багышлаган хезмәтләренең кирәксезгә әверелүен күреп йөрәгә әрнегән, рухы сынган, киләчәккә өмете калмаган шәхеснең эш нәтиҗәләре турында басылмаган кульязмалары дөнья күргәч кенә сөйләшергә мөмкин булачак.

Риза Фәхретдин 1936 елның 12 апрелендә вафат була. «Мине мөфтиләр янына мәчет ишек алдына күммәгез» дигән васыятен үтәп, туганнары аны Уфа каласының мөселман зиратында җирлиләр.

РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛАНЫҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Автор: Руфия Фазылова

Фото: «Татар-Информ» МА

Үзем турында: «Каршылыклы, бәйсез», – дигән фикер ишеткәлим. Тик... бәйсез кеше бармы икән? Безне бит дөньяда нидер бәйләп тота. Туганлык хисе, милләтпәрвәрлек, ниндидер идеягә тугрылык – уйлап баксаң, болар барысы да сине аерым кысаларга кертә. Яшен генә бәйсез, яшен генә ялгыз! Бөтенләй бәйсез булсак, без дә, яшен кебек, тиз арада атылып югалыр идек.

Әлбәттә, мин үзем ышанган фикерне башкаларга да җиткерергә омтылам. Әгәр дә тирә-юньдә һәммәсе караны ак дип тәкърарлап торса, акны ак дию дә кайчак кыюлык таләп итә. Хакыйкатьтән тайпылмаска тырышам. Бу да җиңел түгел, чөнки дөнья белән ялган идарә итә. Ләкин мин тәгаен беләм, ялган ятьмәсенә эләксәм, Шигърият мине шунда ук ташлап китәчәк. Ә ул, Туфан әйтмешли, безнең иң илаһи сөйгән ярыбыз, ташласа, рухи үлем булыр иде...

Дөресен әйткәндә, кешеләрнең күбесе җисми яктан гына тере бит, чөнки рухиятсез яшәве җиңелрәк. Бу безнең заманга аеруча хас. Кулланучылар җәмгыяте, диләрме әле? Ә мин нәни генә җәмгыятьтә – иҗатчылар дөньясында яшәргә тартышам. Менә шул тартышта каршылыклар килеп чыга инде. Каршылыклы булуым шуннандыр.

Мөнбәрдән дә, көндәлек тормышта да, билгеле, күңелеңдәген әйтеп бетереп булмый. Калганнары – шигырьләрдә. Анда читләтеп тә туры тидерү мөмкинлеге бар.

Тумышым белән Чувашиянең Комсомол районыннан. Безнең якта татар авыллары мул тормыш белән яши, авыллар бетү проблемасы юк. Моның хикмәте – халыкның эш яратуында. Мул тормыш өчен көнне төнгә ялгап эшләргә кирәк. Бездә халык хөкүмәттән көтеп ятарга өйрәнмәгән. Үзе кыймылдый. Тәгәрмәчкә таяк кына тыкмасыннар!

Безнең якларда, җир аз булу сәбәпле, элек-электән читкә чыгып эшләү булган. Мин үсмер чакта авыл ир-атларының күбесе читкә «шабашка»га чыгып китә иде. Өйләр салалар, терлек фермаларын сиплиләр, тагын шуның ише төзелеш эшләре... Аны ул заманда «калымга китү» дип тә әйтәләр иде. Күрәсең, борынгыдан калым түләргә түл җыю өчен шулай «ягага» (читкә) чыгып эшләү булган.

Мин дә унбиш яшьтә, авыл ирләренә ияреп, Чувашиянең бер районында «шабашка»да эшләдем. Нык малай идем, 75 килолы! Аннары да шактый йөрелде. Бигрәк тә студент елларда – Пермь, Киров өлкәләренә кадәр чыктык.

Шыгырдан, Урмай, Тукай кебек эре авылларда хәл тотрыклы, алар зурая, киңәя. Шыгырдан үзе кечкенә бер шәһәр кебек. Ваграк авылларның киләчәге, әлбәттә, томанлырак. Балалар аз туа бит хәзер. Эш табу да җиңелдән түгел.

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Ркаил Зәйдулла, 1962 елның 23 гыйнварында Чувашиянең Комсомол районы Чичкан авылында туган. Башлангыч мәктәпне – туган авылында, урта мәктәпне күршедәге Чурачык авылында укып тәмамлый. 1984 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укып чыга. 1985–1987 нче елларда – «Яшь ленинчы», 1987–1989 нчы елларда – «Татарстан яшьләре», 1989–2009 нчы елларда «Идел» журналында эшли, баш мөхәррир вазыйфасын башкара. Бүгенге көнгәчә поэзия, драматургия, публицистика өлкәсендә актив эшчәнлек алып бара.

Ркаил Зәйдулланың аерым әсәрләре инглиз, төрек, үзбәк, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителеп, төрле басмаларда дөнья күргән.

Китаплары: «Кояшлы күзләр» (1984), «Урыс кышын озату» (1988), «Күрәзә» (1993),«Ил» (2000), «Татар таҗы» (2004), «Ташка ордым башны» (2008), «Сабантуй сөлгесе» (2011), «Саташкан сандугач» (2012), «Сары кирмән хәзинәсе» (2017), «Янды сөю чатырлары» (2018).

Ркаил Зәйдулла – Татарстанның халык язучысы, Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, ТР Дәүләт Советы депутаты.

Туган авылым Чичкан безнең якта уртачарак авыл санала, 200 дән артык хуҗалык. Ләкин кайбер йортларда бүген карт белән карчык үзләре генә яшәп ята. Шулай да буш йортлар юк диярлек. Соңгы елларда туган авылга кире кайтып төпләнүчеләр дә күренгәли. Тугызъеллык мәктәп эшли. Димәк, өмет бар әле. Безнең нигездә энекәш гаиләсе белән яши. Әнәй исән, Аллага шөкер. Сеңлем дә гаиләсе белән авылда гомер итә. Мин инде үземне бу мәсьәләдә акыл өйрәтергә бик үк хаклы дип санамыйм – чыгып киткән кеше бит. Якташларыма ышанам. Алар бетә торган халык түгел.

Шагыйрь – олы исем. Олыгая-олыгая, үземне шагыйрь дип атарга кыенсына да башладым әле. Миннән алда нинди бөек шагыйрьләр булган, үзем күреп-аралашып калганнары да күпме! Ә дөньяда?! Вакыт кына үз бәһасен бирер. Мин бакыйлыкка киткәч, кем дип таныйрлар бит әле?! Шуңа алдан кычкырып куймыйк. Әлегә мин язучы. Бөтен жанрда язам, бары тик, Аллага шөкер, ошак (донос) кына язганым булмады. Язмасын да язарга! Халкымның милли үзаңын аз гына булса да кузгата алсам, шуңа канәгать булыр идем. Минем яшьтә шуннан артыгына ымсыну инде урынсыз. Хәер, монысы да бик олы теләк.

Бүгенге әдәбиятны еш кына тәнкыйтьлиләр. Тукай әйтмешли, «тәнкыйть – кирәкле шәйдер». Анысы шулай, тик Тукай да үзен тәнкыйтьләгәнне өнәп бетермәгән. Нинди тәнкыйть бит. Шәхесеңә тукынсалар, бу инде тәнкыйть түгел, хәкарәтләү. Тәнкыйтьне яратмыйм, диярга телем әйләнми. Хәзер, кызганычка каршы, чын тәнкыйть, әдәби, гыйльми тәнкыйть юк дисәң дә була. Мине яшь чакта ук тәнкыйтьләүчеләр булды: Туфан Миңнуллин, Мансур Вәлиев… Әмма аларның тәнкыйте минем күңелемне төшермәде, алар миннән тагын да зурракны көтеп, планканы югары куеп тәнкыйтьләделәр. Хәерхаһлы булып.

Әдәбият сөючеләрнең төрлесе бар. Язучыларның да төрлесе… Шуның белән кызыклы бит инде, һәркем бертөсле язса, бик күңелсез булыр иде. Минем буында гына да кемнәр генә юк! Ул элек тә шулай иде. Кырык ел шушы өлкәдә кайныйм, төрлесен күрдем. Укучы үз зәвыгына тиң язучыны сайлый. Мин язучыларны эресенә, вагына бүлмим. Һәркем үз йөрәге биеклегендә.

Депутатларның да төрлесе бар. Төгәл беләм – кайберләре, мәсәлән, нәкъ минемчә фикер йөртә, ләкин шуны кычкырып әйтә алмый. Мин бераз циниктыр, бәлки, ләкин кеше шулай яратылган: ул башта, һичшиксез, үзе турында уйлый. Сүзенең, гамәленең нәтиҗәсен күз алдына китерә. Җил уңаена атлавы җиңелрәк бит. Мин исә бер партиядә дә тормыйм, фикеремне курыкмыйча әйтә алам. Аннары миңа, шагыйрь буларак, әлегә күпмедер ташлама да бар төсле. Киләчәктә ни булыр тагын…

Абруй. Дөресен генә әйткәндә, ул хакта уйлаганым юк. Хакимияттәгеләрнең абруе бар инде ул. Власть үзе тирәсендә шундыйрак аура барлыкка китерә. Кәнәфидән төшүгә, ул абруй эреп каядыр юкка да чыга. Халык мәхәббәте дигән нәрсә дә бик шартлы – бүген күккә күтәрә, иртәгә таптап китәргә дә күп сорамый…

Каләм әһелләренең хәле бөтенләй бүтән. Хәзер бит халык тормышында әдәбият элеккеге заманнардагы кебек әһәмиятле роль уйнамый. Элек тә, совет власте вакытында, аның ролен ясалма күперткәннәр дип уйлыйм. Ул чагында да үз иманы хакына сүзен өздереп әйтүчеләр сирәк-мирәк кенә булган. Күбесе шуның өчен кыен да ашаган. Мин Сталин заманын әйтмим, анда кайсы корбан, кайсы җәллад… Хакимияткә ләббәйкә дип торучыларны да атып үтергәннәр. Бер гөнаһсызга юк ителгәннәре дә бик күп.

Чын әдип хәлдән килгәнчә намуслы булырга тиеш. Менә шул. Ә пычранмый калу бу тормышта җиңел түгел. Мин дә куркам, әлбәттә. Куркак дип әйтүләреннән куркам. Ләкин бер риваять бар. Арыслан артыннан: «Әйдә көрәшик, әйдә көрәшик!» – дип өзми-куймый бер эт йөгерә икән. Арыслан, аңа игътибар итмичә, үз юлын дәвам итә. Эт шул вакыт: «Минем белән көрәшергә курыкты, дип, данымны таратам хәзер!» – дигән. Арыслан түзмәгән, җавап биргән: «Эт белән көрәшкән дип даным чыкканчы, куркак дип әйтүләре хәерлерәк булыр», – дигән…

> – ТР Дәүләт Советы утырышында, мәктәпләрдә татар телен укытуны туктаусыз прокуратура тикшергәнгә шаккатып, борчылып чыгыш ясадым. Билгеле, системаны үзгәртә алмыйм. Әмма әйтүем хак булсын. Әлегә бу мәсьәлә буенча тикшерүләр турында ишетелми, ләкин андый хәл кабатланмас, дигән ышаныч та юк…

Депутат буларак икътисад өлкәсендә эшләмим. Аның үз белгечләре бар. Мин мәдәният, мәгариф биләмәсендә. Анда инде үземне чит кеше дип санамыйм. Дөрес, мин кызыксынучан кеше. Ун еллар элек альпинистлар белән Тянь-Шаньга (Тәңре таулары) менгәндә, тау җене йоктыручы Рафаэль Ишморатов (Риза Ишморатның улы) миңа XX гасырның бөек икътисадчысы – Фридрих фон Хайекның «Коллыкка юл» әсәрен укырга биргән иде. Хайек аны 1944 елда язган, ләкин хәзер дә безнең өчен шулкадәр актуаль ул… Күптән түгел аның «Индивидуализм һәм икътисадый тәртип» дигән әсәрен укыдым. Кереп киткәч, барысы да аңлашыла. Хайек фәлсәфәче дә, бәлки, шуңа укыр өчен кызык.

ТР Дәүләт Советы утырышында, мәктәпләрдә татар телен укытуны туктаусыз прокуратура тикшергәнгә шаккатып, борчылып чыгыш ясадым. Билгеле, системаны үзгәртә алмыйм. Әмма әйтүем хак булсын. Әлегә бу мәсьәлә буенча тикшерүләр турында ишетелми, ләкин андый хәл кабатланмас, дигән ышаныч та юк…

ТР Дәүләт Советы депутатларының яртысыннан артыгы татарча белә. Ләкин татарча чыгыш ясамый. «Ешрак татарча сөйләсәгез, халыкның күңеле булыр иде», – дип, коллегаларыма мөрәҗәгать иттем. Биюче бии-бии остара, дигәндәй, аларның күбесе әдәби телдә чыгыш та ясый алмыйдыр, ләкин белгән кадәр сөйләсәләр, шомарырлар иде. Әнә Камил Нугаев һәр чыгышын татар телендә җиткерә бит. Моның бер авырлыгы да юк. Ни дисәң дә, Дәүләт Советы (тиздән атамасы үзгәрәчәк инде аның) трибунасы ул шактый югары мөнбәр. Аннан сүз татарча ишетелсә, телебезнең абруе күпмедер артыр иде.

Тормыш без дигәнчә генә бармый, дөнья бит. Мөдәрристәгечә: «Тимерченең авыр чүкечедәй килеп төшә Вакыт, йәнчә генә – Бар да була ул дигәнчә генә!» Нишлим – ятам уйланып, түшәмгә карап…

Гаиләмә килгәндә, гаиләм әйбәт. «Ир – баш, хатын – муен» дигән гыйбарә бар бит. Гадәттәгечә, хатын муен гына түгел, баш та булырга ымсына инде. Мин аңа юл куярга тырышам, җәл түгел. Тик хатын моңа һаман ышанып бетми…

Дәүләт Советында аерылып торам – үзара «җәяүле депутат» дип атыйлар. Язучыларга хезмәт хакы түләнми. Шулай да китапларым чыгып тора. Аннан мин бит драматург та әле. Пьесаларны сәхнәгә куйсалар, халык та йөрсә, тама бераз. Акча яшәрлек булса, җиткән. Артыгы кирәкми.

Балаларга карата төрле чак була. Каты бәрелмим, гадел булырга тырышам. Алар күңелләре белән мөстәкыйль, мин исә моны иң зур хәзинә дип саныйм. Фикердә бәйсезлек, гамәлдә мөстәкыйльлек – иң кыйммәтлесе! ■

PRESSA



ИШТӘСЕ

Автор: Луиза Янсуар

ВАКЫТ БЕЗНЕКЕМЕ, БЕЗ ВАКЫТНЫКЫМЫ?

Бу ике әсәрне укыганда әнә шул сорау торды алдымда. Һәр икесендә дә аңа җавапны төрле яссылыктан эзлиләр. Һәм төрле ысуллар белән табалар. 2020 елда басылып чыккан яңа китаплар арасындагы бик тә үзенчәлекле икесен сезнең игътибарга тәкъдим итәм.

АУТЕНТИК ӘДӘБИЯТ, ЯКИ ТОРМЫШ ПУЛЬСАЦИЯСЕ

Яңа заман Латин Америкасы әдәбияты турында сүз чыкканда, без әле һаман да, беренче эш итеп, Гарсиа Маркесны искә төшерәбез. Аннан кемдер Кортасарның барлыгын ваемлап ала, Коэльоны искә төшерә... Ә менә Төньяк Америка белән Көньяк Америка арасындагы чиктә торган Мексика әдәбияты турында без гомумән аз беләбез. Дөрес, әдәбият сөючеләр Карлос Фуэнтес, Октавио Пас (соңгысы Нобель премиясе лауреаты) исемнәрен, кайберәүләр хәтта ки әсәрләрен дә белә. XX йөз азагында Мексика культурасына кызыксынуны антрополог Карлос Кастанеданың Дон Хуан турындагы китаплары да кыздырып җибәргән иде. Әмма сүз аутентик әдәбият турында бара икән, биредә бит әле тәрҗемәнең дә тиешле югарылыкта булуы әһәмиятле.

Мария Александрова тәрҗемәсендә «Фантом Пресс» нәшрияты бастырып чыгарган «Дом падших ангелов» романы безгә әнә шул аутентик тәмне тәкъдим итә. Иге-чиге, башы һәм азагы юк тормышның сүз һәм кәгазь фактурасына күчкән бер вариациясен. Шулай итеп, без бүгенге Мексика әдәбиятының матур бер үрнәге белән танышу бәхетенә ирешәбез.

Де Ла Круслар исемле Мексика кланы турындагы гаилә сагасы иң яхшы эпик әсәрләр традициясендә язылган, шул ук вакытта Урреа стереотиплардан азат һәм текст белән гаҗәеп иркен, стихияле эш итүе белән дә аерылып тора. Дәрәҗәле American Book Awards һәм Пулитцер премияләре лауреаты Луис Альберто Урреа – бездә әллә ни яхшы тәрҗемә ителгән язучы түгел, гәрчә ул бүгенге испан телле әдәбиятның әйдәп баручы әдипләреннән берсе һәм күпсанлы романнар, публицистик басмалар авторы булса да. «Дом падших ангелов» романы безгә аны, романист буларак, бар колачында ачарга мөмкинлек бирә.

Магик реализмга караган «Латин Америкасы бумы» инде узган булса да, Урреа бу традицияләрне үзенә бер юнәлештә дәвам итә. «Дом падших ангелов», Гарсиа Маркесның сагасы кебек үк, полифониясе һәм гаҗәеп үзенчәлекле менталь кодлар системасы белән аерылып тора. Бу әсәрнең теле һәм стиле сихерле, үзенә бөтереп алып кереп китә һәм кайнап торган тормыш сурәтен тудыра. Әсәр гаҗәеп дәрәҗәдә детальле, динамик агышлы, ул беразга гына да игътибарны читкә җәлеп иттерми. Иң сокландырганы – Урреа гадәти нәрсәләрне дә чын сәнгати югарылыкта күрсәтә белә.

Романның сюжет линиясе бик гадәти: зур бер гаиләнең, ягъни тулы бер кланның башлыгы, патриархы үлем алдында тора. Ирексездән, «Осень патриарха» романына сылтама укыла, әмма бу –

Фотолар: livelib.ru, readrate.com сайтларыннан алынды

беренче карашка гына. Туган-тумачалары «Өлкән Фәрештә» («Старший Ангел») дип атап йөрткән төп каһарман шактый озын һәм вакыйгаларга бай гомер кичергән булса да, үзеннән соң җиренә җиткереп бетермәгән эшләре өчен борчыла, кайбер нәрсәләрне иртәрәк тәртипкә салмаганы өчен эче поша. Моннан да бигрәк, аның олы бер теләге бар – бөтен гаиләне бергә җыеп, туган көнен уздыру. Аннан тыныч күңел белән китә дә алыр идем, дип уйлый ул. Әмма бу ниятнең каршылыклы ягы да бар: мөнәсәбәтләр шактый катлаулы булган бу гаиләдә бөтенесе бергә... нибары күмү йоласына гына җыела. Анда да талашмыйча, әрепләшмичә, кайчак хәтта йодрыкларын эшкә җикмичә, аерылыша алмыйлар. «Ничек үлмичә торып барысын да бергә җыярга соң?» – дип баш вата Өлкән Фәрештә.

Әсәр искиткеч шәп ирония белән тозланган-борычланган: Урреа тормышны эстетиклаштырып торуны кирәк тапмый, барысын да ничек бар шулай тәкъдим итә укучысына. Әмма бу тормышчанлыкның үз стиле һәм эстетикасы бар. Шуның белән ул искиткеч чынлыкка ирешә дә. Роман де Ла Круслар нәселенең шәҗәрәсе белән ачылып китә. Шунда ук ике жанр берләшә – югары, рухи стильдәге Библия белән үз заманында «плутовской роман» буларак билгеле булган романнар өслүбе. Һәм бу синтез гаҗәеп рәвештә органик яңгыраш, аһәң ала, бик тә табигый, килешле, ыспай тоела.

Өлкән Фәрештә үз әнисен күмү йоласына соңга калырга мөмкин иде.

Барысы да аннан алда килеп җитәчәк. Юк. Булмас. Мексиканлылар бер хатаны ике мәртәбә кабатламый.

Ул, үз диагнозы турында белеп алганнан соң, һәр иртәне бер уй белән уяна. Шул уй – аның будильнигы. Китәргә вакыты җиткән кеше ничек итеп хаталарын төзәтә ала? Менә бу иртәдә дә ул шул ук уй белән уянды. Аны күзне камаштыра торган иртәнге яктылык белән беррәттән шик-шөбһәләр уратып алды. Вакытны һәм үзен саткан тәнен, җисемен каһәрли-каһәрли, ул тирә-ягына күз салды һәм имәнеп китте. Караваты читендә әтисенең өрәге утыра иде.

Картлач, аның «Пэлл-Мэлл» пачкасыннан чирткән төпчекне суырып ләззәтләнгән хәлдә, болай дияргә кирәк тапты:

– Бик авыр йөк ята синең иңнәреңдә. Торырга һәм эшкә тотынырга вакыт.

Шулай диде дә, кинәт төтен спиралена әверелеп, түшәмгә таба мәтәлеп юкка да чыкты.

– Телең нәрсә сөйләгәнне колагың ишетсен, – дип пышылдады Өлкән Фәрештә аның артыннан.

Челт-челт күзләрен йомагалап алды. Ул үз нәселе өчен гомер буена тере сәгатькә тиң булды. Ә менә хәзер... Янәшәдә йоклап яткан хатынына төртте:

– Без соңга калдык, Флака, – диде.

– Булмас! – дип сөрән салды хатыны. – Йа Ходам! Һәм шунда ук караваттан сикереп торды.

– Мин әниемне күмәргә вакытында барып җитә алмаячакмын, соңга калам, – дип эндәште ул Дөньялыкка.

Ул беркайчан да беркая да соңга калмый иде. Бүгенге көнгә кадәр. Алай гына да түгел, Өлкән Фәрештә гомере буена «мексика вакыты» дигән каһәр суккан төшенчә белән көрәшеп килде. Ул кагыйдәләр аны акылдан яздыра иде. Әгәр кичке ашны алтыга билгелиләр икән, тугыздан да иртәрәк аның башланмаячагын көт тә тор. Әле тугыздан да иртәрәк килсәң, аптырауларын да көт: янәсе, син нәрсә, ычкындыңмы әллә?! Чын мексиканнар кичке ун тулмыйча ашка утырамыни?!

Әсәрнең буеннан-буена әлеге Америка җирлегенә килеп урнашып та үзтәңгәллеген, менталитетын гаҗәеп дәрәҗәдә саклаган нәселнең маҗаралары шулкадәр тәмле итеп сурәтләнә ки, син андагы кешеләрне үзеңнең туган-тумачаларың кебек хис итә башлыйсың. Монда барысы да шундый чын: иң югары идеаллар, хыял-өметләр дә, хатагөнаһлар да, оят гамәлләр дә... Бу әсәрдәге типлар һәм характерлар шулкадәр куе, җете бизәкләр белән төшерелгән ки, алар күз явын ала. Чуарлыгы, төсләр кокофониясе белән. Ирексездән күз алдына Диего Ривера мураллары белән Фрида Калоның нәни картина-порталлары килеп баса...

Бу әсәрдә хаклылар яисә хаксызлар, хәләл яки хәрам юк... биредә дертләп торган тормыш пульсациясе генә бар. Һәм ул, үз эченә бөтереп алып, әсәрендерә, кайсыдыр бер ноктада катарсиска китерә.

ЧОР ҺӘМ ШӘХЕС, ЯКИ СОРАУЛАР АЧЫК КАЛГАНДА...

Джей Парини атаклы немец фәлсәфәчесе Вальтер Беньяминның соңгы көннәре турында язган әсәрен без рус телендә Александр Александров тәрҗемәсендә укып хозурлана алабыз. АКШ та Паринига карата инде шактыйдан «әдәби биография остасы» дигән исем кулланыла, ул бу жанрда чынлап та югары кимәлдәге әсәрләре белән танылган автор. «Азбука-Аттикус»ның «Иностранка» сериясендә дөнья күргән әлеге китабы да һичшиксез бестселлерлар исемлегенә кертелгән.

Әсәр 1996 елда ук басылып чыккан булса да, рус телендә ул үз укучысына быел гына килеп иреште, 20 елдан артык вакыт узганнан соң. Күрәсең, бу кызыксыну һәм романны укучы хозурына чыгару нияте аның экрандагы тормышы башлану белән дә бәйле. Хәзерге вакытта Парини романы буенча фильм төшерелә, анда фәлсәфәче Беньямин ролен танылган актер Колин Ферт башкара. Сүз уңаеннан, бездә Беньямин хезмәтләре тәрҗемә ителгән һәм берничә кат бастырылган, ул яңа заман фәлсәфәчеләре арасыннан рус укучысы иң яратып укый торганнардан исәпләнә.

Әлеге фәлсәфәче турында, аз да түгел, күп тә түгел, «заманга карашны үзгәртүче» дигән фикер таралган. Ул әле бер үк вакытта культура өлкәсендәге

теоретик, әдәби тәнкыйть остасы, эссеист, публицист һәм тәрҗемәче дә. XX гасырның иң күренекле акыл иясенең фикерләре модернизмны аңлау өчен ачкыч буларак бәяләнә, бүгенге чор мәдәни барышын ваемлаган постулатлар буларак кабул ителә.

Аның биографиясе дә җәлеп итәрлек, кайбер тәнкыйтьчеләр болай ди: «әлеге биографияне язып торырга да кирәкми, ул теләсә нинди интеллектуаль роман өчен нигез була ала». Вальтер Беньяминның бөтен тормышы диярлек мосафирлыкта уза: Веймар республикасында килеп туган кризисның һәм иҗтимагый вазгыятьнең шаһиты булган фәлсәфәче, нацистлардан качып, Парижга барып чыга, аңарчы коммунистик идеологиягә багынып, СССРга сугылган була. 1940 елда Париждан да китәргә мәҗбүр ителә, Испаниягә барып сыена. Ул үзенең рухи идеаллары сыенырлык утопия утравын да гомере буена эзли. Байопик классик кысаларда – каһарманның үлем ноктасыннан башлана һәм флэшбекларга корылган булуы белән бик тә гадәти канвага утыртылган булып тоела. Әмма Парини әсәрендә «фишка»лар кулланмаса, мавыктырмаса, Парини булмас иде, билгеле. Һәм лирик-поэтик теле, сурәтләү чаралары белән сихерләмәсә дә, Парини булмас иде:

Инде ун елдан артык вакыт узды, бәлки, аннан да күбрәктер, тик мин әле дә аның тавышын ишетәм. Ул тавыш кипкән үләннәрдә кыштырдый, кинәт кенә җилдә кубарыла, дулкыннар шавына яшеренеп яңгырый, йә ишетелеп куя. «Әгәр мин Палестинага киткән булсам, – ди иде ул, – бәлки, барысы да башкача булган булыр иде. Хәер, кем белә. Мин бит һәр борылыш каршында озаклап таптанып басып торам». Бу юлларны Беньямин 1931 елда язган булган, әле китү мөмкинлеге бар чакта. Китә калса, фикердәшләр эргәсендә яшәгән, исән калган булыр иде. Ник соң үзен харап итәргә кирәк булды аңа, аңламыйм?! Мин аңа вакыты җиткәч университетта эш табып бирер идем, йә булмаса – берәр мәктәпкә урнаштырыр. Мөгаллимнәр кайда да кирәк. Китапханәдә дә урын табылыр иде үзенә. Аңардан менә дигән кульъязмалар сагында торучы чыгар иде ләбаса, сәнгать әсәрләрен бәяләүче. Вальтер Беньямин кадәр белем кемдә бар тагын?!

Тик Европадагы хәлләрнең мондыйга ук барып җитәчәген хәтта ул да белмәгәндер, дип уйлыйм. Беньямин андый ерткычлыкны күрәзәлек итә алыр кеше түгел иде, юк. Дөресен генә әйткәндә, ул реаль тормышны гомумән аз ваемлый иде. Сәясәт мәсьәләсендә аны – бу сүзне әйтүдән курыкмыйм – белдексез, хәтта хөрәсәнрәк дияргә дә мөмкин. Ә менә әдәбият турында ул барысын да белә иде! Мифтагы Тезей сыман, текст лабиринтына кереп китә дә, мәгънә йомгагын, әйтерсең, үз йөрәгенә тоташкан җеп сыман чишә. Ә аннары, Минотавр белән күзгә-күз очрашып, аны аяктан егып, бер куркусыз кабат яктылыкка әйләнеп кайта.

Европа аңы үзенең сакчысын, тәхет биләргә тиешле затлы варисын югалтты, гаҗәп аһәңгә ия җырчысын, шаһзадәсен. Дөрес, бу хакта күпчелек белми дә. Хәер, беләсләр дә, аларга барыбер. Ләкин мин беләм: бу дөньяга Беньямин кебек икенче берәү әле тагын туармы-юкмы… мөгаен, тумас…

Һәм менә мин биредә, Испания чигендә басып торам: ун елдан артык гомер элек дустымны үлем сагалаган урында. Әйе, ул минем дустым иде, һәм мин аның каберен үз күзләрем белән күрергә тиеш. Шикшөбһәләр, ымсынулар калмасын өчен. Һәм биредә булган фаҗигане ваемлар өчен дә. Югыйсә, ул хакта уйлаган саен, төн уртасында шыбыр тиргә батып уянам…

Хикәяләү төп дүрт персонаж исеменнән бара – болар Беньяминны гомеренең төрле чорларында белгән кешеләр. Бу дүртәүнең уй-фикерләре полифониясенә каһарманны кыска гына вакыт аралыгында белгән очраклы персонажларның тавышлары да кушылып китә – аңа Испаниягә килергә ярдәм иткән ханым, Беньямин үз-үзенә кул салган кунакханәнең хуҗабикәсе һ.б. Әсәрдәге барлык геройларның да прототиплары бар диярлек, автор хәтта аларның барысы белән дә шәхсән очрашып аралаша. Әмма Парини, романны флешбекларга корган хәлдә, тигез линиядән баш тарта: 1940 елгы вакыйгалар һәрчак үткән-бүген-киләчәк ракурсыннан бәяләнә.

Паринины без лирик биография остасы буларак беләбез, шуңа да ул каһарманының көндәлекләрен, мемуарларын мулдан файдалана, алардан да тере тарих ясый. Беньяминның фрустрацияләрен тасвирлауда да интим детальләрне иркенләп куллана. Шуңа да бездә үтә якын, хәтта ки хисси яссылыктан кабул итү тойгысы туа.

Әсәрдәге каһарманы аша Парини сәясәт турында да, тарихи барыш турында да аерым бер детальләр аша сөйли. Һәм безгә, беренче карашка, икенче планда калган кебек тоелган чор, дәвер сурәте кетмәгәндә-уйламаганда үтә дә кырыс сулышы белән килеп бәрелә: кабул ителгән карарлар, тормышка ашырылган җәзалар, кире кайтарып булмас хәлиткеч гамәлләр рәвешендә. Беньяминдагы ваемсызлык вакыт-вакыт эчне пошыра, ачуны кабарта, әмма тора-бара без аның ни өчен шулай эшләгәнен аңлый башлыйбыз, бу юлның кая китерәчәген дә тоемлыйбыз. Тик без аны туктата алмыйбыз, безгә андый көч бирелмәгән. Хәтта герое чынбарлыктан алынмаган булса да, Парини аны аямас иде, дип уйлыйм.

Бер диалог вакытында философ бик тә гыйбрәтле һәм характерын тулысынча ача торган сүзләр әйтә: «Минем өчен иң мөһиме – сәясәт тә, җәмгыятьтәге вакыйгалар да, хәтта ки мәхәббәтләрем дә түгел, ә минем эшем», – ди ул. Без аңлыйбыз: менә шушы – аның юлы. Һәм ул үз юлын баштанаяк ваемлый. Шуңа да без аны шундый итеп хәтеребезгә кертеп калдырабыз: менә, Беньямин Париж урамнары буйлап Бальзакны, Прустны, Бодлерны укып йөри, тирә-юньдә хет туплар шартласын, аның аларда гаме юк. Ул үзенең стихиясендә, үл үз йөрәге югарылыгында…

Шул рәвешле Парини шәхес белән чор фаҗигасен бер үк вакытта параллельдә дә, әмма каршы куеп та күрсәтә. Кирәкме ул шәхескә чорының сагында булу һәм аның кайсыдыр бер позициясен сайлап, нинди дер идеологиягә хезмәт итү, әллә юкмы? Ә сорауны автор һәммәбез өчен дә ачык калдыра. T

www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС | ТАТ
ТАТАРСТАН
Подписка!
Где купить журнал "ТАТАРСТАН"
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Тормышны яратып яшәсәң...
Лотфулла Фәттахов иҗаты
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
10 августа 2020
07 августа 2020
06 августа 2020
Мөхәммәтҗан Хәсәенов – беренче мөфти
Тарих сәхифәләре
Мөслимнең туган якны өйрәнү музее
Тормышны яратып яшәсәң...
Лотфулла Фәттахов иҗаты

Реклама 16+

махсус проект

«ТАТАРСТАН» ЮБИЛЯРЛАРЫ

55

ЧЫГАРЫЛЫШ

Гүзәлия Сафина, «ТАИФ» АҖ генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары, август аенда үзенең юбилеен билгеләп үтә.

Эдуард Галиев,
«ТГК-16» АҖ
генераль директоры

САННАР ДӨНЬЯСЫНДА ГАРМОНИЯ ТУДЫРГАН ШӘХЕС

– Хөрмәтле Гүзәлия Мөхәррәмовна!

Сезне «ТГК-16» хезмәткәрләре коллективы һәм үз исемемнән олы юбилеегыз белән ихластан тәбрик итәм!

Бер бөек хатын-кыз әйткәнчә, матурлык гүзәл ул, ә максатка ирешү белән туа торган үз-үзеңә ышаныч хисе дөньяда иң гүзәл әйбер булып тора. Сезнең тормыш сукмакларыннан һәрвакыт бик ышанычлы баруыгызны, талант, шәхси сөйкемлелек һәм һөнәрмәндлек белән яңадан-яңа үрләр яулавыгызны әлеге гыйбарә бик төгәл чагылдыра. Сез үз язмышыгызны финанс тармагы белән бәйләгәнсез һәм, анда искиткеч уңышларга ирешеп, зур абруй яулагансыз.

Сезнең хезмәт биографиягез – эшкә сәләтлелек, интеллект, активлык, җаваплылык һәм гел алга – куелган максатка юнәлүнең нинди уңышларга китерүенә менә дигән мисал ул. Коллегаларыгыз Сезнең лидерлык сыйфатларыгызны һәм стратегик күрү сәләтегезне яхшы белә, нәкъ менә шулар Сезгә республикада һәм илдә иң хөрмәтле икътисадчылардан берсенә әйләнергә ярдәм иткәндер дә. Сезгә эшлекле рациональ мөнәсәбәт һәм затлылык, искиткеч игътибарлылык һәм максатчанлык, һәрвакыт дөрес карар кабул итү сәләте хас. Үз күнекмәләрегезгә һәм белемегезгә таянып, Сез саннар дөньясында гармония тудыргансыз, озак еллар буе җитди нәтиҗәләргә китерергә сәләтле көйле структура булдыра алгансыз.

«ТАИФ» АҖ генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары сыйфатында Сез Татарстанда һәм Россиядә әйдәп баручылардан булган Компанияләр төркеменең финанслар секторын контрольдә тоту бурычларын хәл итәсез. Югары компетенцияләрегез һәм бай тәҗрибәгез Сезгә коллегаларыгыз ихтирамын яуларга, шулай ук Россия һәм Татарстанның атказанган икътисадчысы мактаулы исемнәренә лаек булырга ярдәм иткән. Сез үз һөнәрегез буенча 25 елдан артык хезмәт куясыз һәм инде үзегез дә уңыш символы булып торасыз. Тәҗрибәле икътисадчы, аналитик фикер сөрешенә ия кеше буларак, Сез зур Россия холдингында исәп-хисап һәм контрольнең нәтиҗәле системасын булдыргансыз. Сезнең көндәлек тырышлык нәтиҗәсендә дә бүген «ТАИФ» зур активларга ия һәм куәтле җитештерү потенциалы, дөрес идарә итү формасы һәм югары дәрәҗәле менеджменты булган иң зур сәнәгый-инвестицион компанияләр төркемнәреннән берсе булып тора.

Без Татарстанның халкын да, төп нефть-химия комплексларын да җылылык һәм энергия белән тәэмин итә торган «ТАИФ» Компанияләр төркеме составындагы тотрыклы баш предприятие саналган «ТГК-16» АҖ үстерүгә Сез керткән өлешне югары бәялибез. Безнең предприятие шул исәптән Сезнең эшчәнлек нәтиҗәсендә дә куллнучылар өчен тарифларны арзан дәрәҗәдә саклап килә.

Хөрмәтле Гүзәлия Мөхәррәмовна! Чын күңелдән Сезне – акыллы җитәкче, шәп икътисадчы, үз эшенең чын остасын һәм искиткеч кешене – туган көнегез белән котлыйбыз! Сезгә ихлас күңелдән җаваплы вазыйфагызда яңа уңышлар һәм перспективалы проектлар телибез! Бәхет, дәрт-дәрман, уңыш һәм нык сәламәтлек Сезгә! Юбилеегыз котлы булсын!

Реклама

Фото «ТГК-16» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Илшат Фәрдиев, «Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры, Россия Чаңгы федерациясе вице-президенты, август аенда үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Леонид Анисимов,
«Грань» ҖЧҖ
генераль директоры

УҢГАНЛЫК ҺӘМ МАКСАТЧАНЛЫК ҮРНӘГЕ

– Хөрмәтле Илшат Шәехович!

Юбилеегыз уңаеннан шәхсән үземнән һәм «Грань» ҖЧҖ коллективы исеменнән ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз.

Үз эшеңә намуслы мөнәсәбәт белән куелган максатларга ничек ирешеп булганны көндәлек хезмәтегез белән дәлилләп, Сез зур уңышларга ирештегез. Һөнәрмәндлек, оештыру таланты, тәвәккәллек, таләпчәнлек һәм актив тормыш позициясе Сезнең абруйның нигезен тәшкил итә. Сезнең эшчәнлек тирән хөрмәт уята: Сез энергетика сәнәгате үсешенә генә түгел, тулаем Татарстан үсешенә дә зур өлеш керттегез. Республика аграр комплексында алдынгы урыннардан берсен биләгән зур авыл хуҗалыгы холдингы белән грамоталы идарә итүегез аерым хөрмәткә лаек. Россия Чаңгы федерациясе вице-президенты сыйфатында илдә чаңгы спортын үстерү буенча хезмәтләрегез бәһаләп бетергесез, шул исәптән Сезнең саллы ярдәм нәтиҗәсендә дә спорт һәм физкультура белән шөгыльләнер өчен шартлар тудырыла.

Тормыш юлыгызда рухыгызга якын кешеләр, ышанычлы дуслар, чын фикердәшләр – колачлы проектларны бергә башкарып чыкканда таяныч булырлык шәхесләр күбрәк очрасын! Сезнең эштәге фидакарьлегегез киләчәктә дә куелган максатларга ирешергә мөмкинлек бирсен, актив тормыш позициягез, дәрт-дәрман һәм тәвәккәллек белән куәтләнеп, тагын да югарырак һөнәри уңышларга китерсен!

Реклама

Фаил Камаев,
Татарстан
Республикасының
Тукай муниципаль районы
башлыгы

ЛАЕКЛЫ АБРУЙ ҺӘМ ТАНЫЛУ

– Хөрмәтле Илшат Шәехович!

Шәхсән үз исемемнән һәм Тукай районы халкы исеменнән юбилеегез уңаеннан иң җылы котлауларыбызны һәм иң изге теләкләребезне кабул итегез!

Һөнәрмәндлек, тәҗрибә, зирәклек һәм хезмәт сөючәнлек, стратегик фикерләү һәм дөрес карарлар кабул итү осталыгы, кешеләр белән эшли белү сәләте нәтиҗәсендә Сез лаеклы абруй һәм танылу яуладыгыз.

Сез оештырган «Агросила холдинг» Тукай районы икътисади тотрыклылыгының нигезе булып тора. Без Сезнең бәһаләп бетергесез тәҗрибәгезгә һәм авыл хуҗалыгы бизнесын үстерүдәге заманча алымнарыгызга таянып эш итәбез. Районыбыз Сезнең белән тыгыз хезмәттәшлектә ирешкән уңышларын киләчәктә дә саклар, авыл кешесенең хезмәте исә дәрәҗәле булып калыр, дип ышанабыз.

«Челтәр компаниясе» ААҖ генераль директоры сыйфатында Сез төбәкнең энергетика тармагын уңышлы үстерәсез. Тукай районының мактаулы гражданины буларак, Сез һәрвакыт безнең белән янәшә, гел ярдәм күрсәтергә әзер. Сезнең булышлыкта гамәлгә ашырылган күпсанлы социаль проектлар өчен район халкы Сезгә рәхмәтле һәм Сезнең белән горурлана. Бу сезнең рәхимле йөрәкле, игелекле кеше булуыгызны күрсәтә!

Эшчәнлегегез Сезгә киләчәктә дә уңышлар китерсен, һәр көнегез иҗат энергиясе белән тулсын, Сезнең белемегез, тәвәккәллек һәм максатчанлыгыгыз республикабыз муллыгын арттыру буенча хезмәтегездә ышанычлы юлдаш булсын!

Хөрмәтле Илшат Шәехович! Сезгә һәм якыннарыгызга ихлас күңелдән нык сәламәтлек, оптимизм, бәхет, муллык, иминлек телисебез килә!

Фото «Грань» ҖЧҖнан, Тукай районы матбугат хезмәтләреннән алынды

Рәшит Хәбибуллин, «ИнститутАгроТрансПроект» ҖЧҖ, «Спектр» Инжиниринг компаниясе» ҖЧҖ генераль директоры, сентябрь аенда үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә

Мәҗит Салихов,
«ТР ТЭДИ» ДАУ башлыгы

ЫШАНЫЧЛЫ КЕШЕ

– Хөрмәтле Рәшит Зиннәтович!

Шәхсән үзем һәм «ТР Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ коллективы исеменнән Сезне ихлас күңелдән юбилеегыз белән котлыйм!

Республика транспорт тармагын үстерүдәге олы хезмәтегез өчен минем ихтирам сүзләремне кабул итеп алыгыз. Сез күп еллар дәвамында туган Татарстаныбызга хезмәт итәсез, аның ныгуына, автомобиль юллары тармагын үстерүгә үз өлешегезне кертәсез. Һөнәри эшчәнлегегезнең һәр юнәлешендә үзегезне нәтиҗәле идарәче, ышанычлы кеше итеп күрсәттегез.

Хәзер Сез тормышыгызның иң уңышлы үрендә торасыз – бай тәҗрибәгез зирәк акыл белән гармониядә, бик күп нәрсә эшләнгән инде, киләчәк исә яңа планнар белән ымсындыра. Сезнең белән күптән таныш булуыма шатмын, безне инде озак еллар буе эшлекле мөнәсәбәтләр һәм күркәм шәхси аралашу бәйли. Сез – зирәк җитәкче дә, юл хуҗалыгы тармагында югары классны белгеч тә, һәр яктан уңай кеше дә.

Хөрмәтле Рәшит Зиннәтович! Барлык хыялларыгыз тормышка ашсын! Сезгә озын гомер, рухи ныклык һәм яңа уңышлар, сәламәтлек, бәхет, иминлек һәм муллык телим! Янәшәгездә тугры дусларыгыз булсын, гел уңыш юлдаш булсын!

Реклама

Ринат Мөхьянов,
«Мосты РТ» ҖЧҖ
генераль директоры

ҮЗГӘ ЯЗМЫШЛЫ КЕШЕ

– Хөрмәтле Рәшит Зиннәтович!

Шәхсән үзем һәм компаниябез хезмәткәрләре коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәм!

Бүген без Сезгә, үзгә язмышлы кешегә, изге теләкләребезне җиткерәбез. Сезнең тормышыгыз – үзегез сайлаган һөнәр буенча озак еллар буе тырышып эшләү, заманча автомобиль юллары инфраструктурасын булдыру өчен армый-талмый хезмәт кую. «ИнститутАгроТрансПроект» ҖЧҖ һәм «Спектр» Инжиниринг компаниясе» ҖЧҖ генераль директоры вазыйфасында Сез дәүләт масштабындагы мөһим эш белән уңышлы шөгыльләнәсез – республиканың транспорт тармагын үстерәсез. Оештырылганнан бирле Сез җитәкләгән институт Татарстан юл-транспорт комплексы объектларын проектлау өлкәсендә лидер булып тора.

Чын һөнәрмәндләр һәм искиткеч намуслы кешеләр турында сүз чыкса, һәрвакыт Сезнең исемне атыйлар. Эшлекле абруегыз нәтиҗәсендә Сез һөнәри бергәлектә ихтирам һәм танылу яуладыгыз, Сез – РФ һәм ТРның атказанган төзүчесе, Россия транспорт академиясенең транспорт докторы һәм Россиянең мактаулы юл хезмәткәре. Сезнең белән танышлыгыма һәм аралашып яшәвемә шатмын, сезнең шәхси һәм эшлекле сыйфатларыгызны югары бәялим һәм хөрмәт итәм.

Хөрмәтле Рәшит Зиннәтович, туган көнегездә Сезгә эшегездә уңышлар һәм яңа җиңүләр телим! Үзегезгә һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек, бәхет, уңышлар юлдаш булсын!

Реклама

Фотолар «ТР ТЭДИ» ДАУ, «Мосты РТ» ҖЧҖ матбугат хезмәтләреннән алынды

Фоат Вәлиев,
«Алексеевскдорстрой» ААҖ директорлар советы рәисе

ЭШКӘ ТУГРЫЛЫК

– Хөрмәтле Рәшит Зиннәтович!

Шәхсән үземнең һәм предприятиебез хезмәткәрләре коллективы исеменнән юбилеегыз белән иң ихлас котлауларыбызны кабул итегез!

Бүгенге истәлекле көндә Сезгә – минем рухыма якын булган һәм транспорт тармагы өчен бик күп эшләгән кешегә – үземнең ихтирамымны белдерәсем килә. «ИнститутАгроТрансПроект» ҖЧҖ һәм «Спектр» Инжиниринг компаниясе» ҖЧҖ җитәкчесе сыйфатында Сез бу куәтле оешмаларны төбәк юлларын яхшыртуда яңадан-яңа җиңүләргә алып барасыз. Бүләкләрегез һәм мактаулы исемнәрегез Сезнең һөнәрмәндлегегезгә иң шәп дәлил булып тора. Сез – РФ һәм ТРның атказанган төзүчесе, Россия транспорт академиясенең транспорт докторы.

Сез уртак бурычны хәл итү максатында фикердәшләр, автомобиль юлларын проектлауда зур тәҗрибәгә ия, югары белемле профессионал-проектлаучылар коллективы туплый алгансыз. Принципиаль тормыш позициягез, республика мәнфәгатьләренә тугрылыгыгыз һәм тәҗрибәгез уңышлы эшчәнлек һәм лаеклы абруй өчен нигез булып тора. Сезнең тирән фикерле, алдан күрүчән, ихластан эшкә бирелгән булуыгыз, кешеләр белән уртак тел табып эшли алу сәләтегез коллегаларыгыз һәм партнерларыгызда хөрмәт уята. Сезнең белән күптән яхшы таныш булуыма, эшлекле мөнәсәбәтләребезгә шатмын, Сезне югары класслы белгеч һәм ышанычлы партнер буларак югары бәялим.

Хөрмәтле Рәшит Зиннәтович! Сезгә киләчәктә дә эшегездә уңышлар, бәхет, ныклы сәламәтлек телим! Юбилеегыз котлы булсын!

Равил Гарипов,
«Каздорстрой» ААҖ директорлар советы рәисе

НӘТИҖӘЛЕЛЕК, ТӘҖРИБӘ, ҺӨНӘРМӘНДЛЕК

– Хөрмәтле Рәшит Зиннәтович!

Шәхсән үземнең һәм безнең компания хезмәткәрләре коллективы исеменнән юбилеегыз белән ихлас котлауларыбызны кабул итеп алыгыз!

Туган көнегездә Сезгә, чын профессионал, рухыма якын кешегә, югары дәрәҗәле белгечкә, үземнең ихтирамымны белдерәм. Сезнең барлык хезмәт эшчәнлегегез туган республикабызның транспорт тармагын үстерү, Татарстан халкы һәм кунакларына уңайлы юл инфраструктурасын камилләштерү белән бәйле. Хәзерге вакытта Сез «ИнститутАгроТрансПроект» ҖЧҖ һәм «Спектр» Инжиниринг компаниясе» ҖЧҖ җитештерү коллективларын җитәклисез, анда бер максат тирәсендә берләшкән фикердәшләр командалары туплый алгансыз.

Тәҗрибәле җитәкче, югары класслы практик, ярдәмчел кеше – Сезне күпләр нәкъ менә шундый яктан белә. Россия транспорт академиясенең транспорт докторы дәрәҗәсе, РФ Транспорт министрлыгының «Россиянең мактаулы юл хезмәткәре» күкрәк билгесе, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, «Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе» һәм «Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе» исемнәре Сезнең казанышларыгызга дәлил булып тора.

Хөрмәтле Рәшит Зиннәтович! Киләчәктә дә һөнәри уңышлар, үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек телим!

Реклама

Фотолар «Алексеевскдорстрой» ААЖ, «Каздорстрой» ААЖ матбугат хезмәтләреннән алынды

ЗУР ӘТРӘЧ: ТАРИХ КАЙДАН БАШЛАНА?

«Татарстан» журналының август санын сәяхәтләргә багышларга уйладык. Борынгы бабаларыбыз яшәгән атаклы авылларны барлап, сәяхәт өчен Тәтеш районының Зур Әтрәч авылын сайладык. Ничек яшәп ята монда халык? Ә менә ничек...

ЗУР ӘТРӘЧ

Автор:
Руфия Фазылова

МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ КИРӘК!

Әтрәчтә безне гармун, җыр-моң белән каршы алдылар. Борынны кытыклап кайнар бәлеш исе дә бөркелде. Гармунчы тальянында өздерә генә.

– Гармунчыгыз мәдәният йортында эшлиме әллә? – дип соравымны бирәм Зур Әтрәч авыл җирлеге башлыгы Илнур Юнысовка.

– Юк, фермада бозаулар карый, – ди ул.

Җирле артистларның чыгышын карагач, танышуга күчтек. Зыялы, кәләпүшле агай – борынгы Болгар дәүләте шәһәре Мең өйле Шонгатны торгызу Фонды директоры Мөнир Вәлиев, камзуллы, сөйкемле апа – авылның остабикәсе, җирле шагыйрә Роза Фәйзуллина, гармунчы ир-ат Васыйл Юнысов икән...

– Алардан башка авылда, районда бер чара да узмый, – диде Зур Әтрәч авылы Мәдәният йорты җитәкчесе Илһам Хәйбуллин.

Зур Әтрәчтә бүген 96 йорт бар, 308 кеше яши. Кызганыч, тугызъеллык мәктәп ябылган, башлангыч сыйныфлар гына калган. Ләкин инде җирле халык балаларның күрше авылга йөреп укуларына күнгән. Аларны бүген икенче мәсьәлә борчый – Мәдәният йортының бинасы тузган. Җыр-моңга гашыйк халык өчен бу чын-чынлап фаҗигагә тиң. Шуңа карамастан, Мәдәният йортыннан кеше өзелми. Авыл апаларыннан торган «Кызыл миләш» ансамбле эшли. Бер генә бәйрәмне дә, истәлекле көнне дә болай гына уздырып җибәрмиләр. Җыелышып спектакльләр дә куялар икән.

– Безнең җирлеккә өч авыл – Зур Әтрәч, Кече Әтрәч, Никифоровка керә, – диде авыл җирлеге башлыгы Илнур Юнысов. – Узган ел Кече Әтрәчтә Мәдәният йорты салынды, ә биш ел узмыйча, бер авыл җирлегендә ике мәдәният үзәге төземиләр. Тәртибе шундый, әмма район җитәкчелеге бу турыда белә, планда каралган.

– Капиталь ремонт программасында да катнашып булмыймы? – дим җитәкчегә.

– Яңаны төзү очсызгарак чыга. Район башлыгы бу проблема хакында белә. Авыл халкының җырга-моңга сәләтен дә күреп тора. Шуңа күрә берәр җае чыгар, дип өметләнәм. Әле менә киләсе елга яңа ФАП бинасы кайтырга тиеш. Документларны, урынны әзерләдек инде. Анысы да авылга бик кирәк, агач ФАП бинабыз искерде.

Зур Әтрәчкә килгәч тә, чишмәләрнең күп булуына игътибар иттек. Иң гаҗәбе – аларның барысы да каралган, «йортлы» булган. Мондый күренешне бөтен җирдә очратмыйсың.

– Ул чишмәләрнең күбесен үзсалым акчасына ясадык, – диде Илнур Юнысов. – Башта – бер урамныкын, аннан соң икенчесен. Авылда гомер-гомергә чишмәләр күп булган, халык шуннан эчәргә су алган. Йортларга су кергәч, чишмәләргә игътибар кими башлаган иде. Менә шуңа күрә тотындык бу эшкә.

Зур Әтрәчтә үзсалым акчасын 1 мең 200 сумнан җыялар. Соңгы елларда башкарылган эшләр – юл салу, электр баганаларына утлар кую һ.б., барысына да шуннан тотылган.

Фото: Александр Ефремов

– Туган авылымның исемен халыкка чыгарасы килде, – ди Мөнир Вәлиев.

Без дә «Әтрәч укулары» була торган җирне – Изгеләр зиратын карап чыктык. Бу урынны җыйнак кына итеп эшләп куйганнар.

Хәтта бүгенге көндә дә Изгеләр чишмәсе суы белән дәваланучылар бар икән.

1236 елдан алып 1326 елга кадәрге вакытны үз эченә алган кабер ташлары бүгенгәчә сакланган.

«ИЗГЕ ҖИРДӘ ЯШИБЕЗ...»

Һәр авылның үз аксакалы, хөрмәткә лаек кешесе була. Зур Әтрәчтә ул, һичшиксез, Мөнир Вәлиев. Элеккеге укытучылар булмый дигәндәй, ул әле дә һөнәренә тугры калган – аң-белем таратуда, эзләнүдә. Мөнир абый укытучы, 45 ел мәктәптә физика, математика, химия фәннәрен укыткан. Директор урынбасары булып та эшләгән. Ә менә лаеклы ялга чыккач, туган як тарихы белән кызыксынып киткән. Хәер, яңа гына кызыксынып киткән, дисәң, дөрес булмас, мәктәптә эшләгәндә үк үзләренең нинди тарихи җирдә яшәүләрен укучыларга сөйли торган булган ул.

– Тугызъеллык мәктәбебезне башлангычка калдыралар дигәч, бик борчылдым, – диде Мөнир әфәнде. – Мәктәбе дә булмагач, авыл бетә бит. Ә Зур Әтрәч кебек тарихлы авыл бетәргә тиеш түгел. Шуңа күрә туган авылымның исемен халыкка чыгарасы килде.

Шушы теләк белән Мөнир Вәлиев археограф Марсель Әхмәтҗанов янына бара. Галим Шонгат территориясендәге 21 таштагы язуларның эчтәлеген язып бирә.

– Бабайлар сөйләве буенча, андый кабер ташлары безнең җирлектә бик күп булган, – диде Мөнир Вәлиев. – Тик гасырлар дәвамында югалып беткән. Кайберләре җир астына убылган. Шунысын тәгаен беләбез: иллегә якын таш күрше Ямбухтино авылындагы чиркәү фундаментына салынган. (Әлеге авыл да 1552 елга кадәр татар авылы саналган). Мин ул ташларның тәрҗемәләрен алып кайттым. Алар 1236 елдан алып 1326 елга кадәрге вакытны үз эченә ала.

Шәһәрне монгол яулары тар-мар иткәнче, биредә акча сугылган. Җирлектә әлегә кадәр бакыр тәңкә калдыклары очрый икән. Археологлар да күп тапкырлар борынгы тәңкәләр тапкан.

– Әле без бала чакта да көчле яңгыр яугач, ике тау арасындагы чокырдан тәңкәләр елга булып ага иде, – дип дәвам итте Мөнир Вәлиев. – Ул акчалар иран динарына охшаган. Алар өч төрле металлдан сугылган – алтын, көмеш, бакыр. Алтыннары безнең гасырларга кадәр бик сакланып калмаган. Ә менә бакыр акчаларны әле дә очратырга була. Татарстан Республикасы Милли музеенда Әтрәч кырларыннан табылган 48 меңнән артык акча бар. Тик, ни кызганыч, алар хәзерге көнгә кадәр җентекләп өйрәнелмәгән. Шулай да тәгаен әйтә алабыз, бу җирләрне монгол яулары тар-мар иткәнче, биредә акча сугылган.

Мөнир Вәлиев 2009 елда «Әтрәч укуларын» оештырып җибәрә. Авылның, районның өлкән кешеләрен җыеп, Изгеләр зиратына баралар. Әрвахлар рухына дога кылалар. Елдан-ел «Әтрәч укулары»ның географиясе, даны арта бара. Соңгы елларда ул бөтен республикага билгеле җыенга әйләнә. Дөрес, быел әлеге чара булмаган. Сәбәбе әлеге дә баягы коронавирус белән бәйле, халыкны күпләп җыярга ярамый бит.

Без дә «Әтрәч укулары» була торган җирне – Изгеләр зиратын карап чыктык. Бу урынны җыйнак кына итеп эшләп куйганнар. Авылдашлардан җыелган көнкүреш әйберләрен туплап, бер музей булдырганнар. Шунда ук азан әйтер өчен сәхнә, утыргычлар ясаганнар.

– ТР Югары Советы депутаты булганда, Туфан Миңнуллинга мөрәҗәгать иттек, – диде Мөнир әфәнде. – 2009 елда ул үзе откан грант акчасына бу борынгы зиратны тимер рәшәткә белән әйләндереп алырга ярдәм итте.

Шул ук елда зират кырыйларына буеннан-буена агачлар утыртканнар. Зират тирәсен карап тору – борынгы Болгар шәһәре Мең өйле Шонгатны торгызу Фонды директоры өстендә.

– Фондның исеме бар да, җисеме юк шул, – диде Мөнир Вәлиев. – Без бит иҗтимагый оешма, ягъни дәүләттән бер тиен дә акча алмыйбыз. Бер гектар җирне дә җыелган сәдака акчаларына чаптырам, шактый зур мәйдан бит. Аз-маз булса да иганәчеләр ярдәм итә, зур рәхмәт аларга!

Зират астында зур булмаган чишмә ага. Аны Изгеләр чишмәсе дип атыйлар. 2007 елны анда һәйкәл белән чардуган куйганнар. Риваятьләргә караганда, Булат Тимер яулары Әтрәч шәһәрлеген кырып киткәннән соң, әлеге урында чишмә ага башлаган. Җирле халык аның турында: «Суы изге», – ди. Хәтта бүгенге көндә дә Изгеләр чишмәсе суы белән дәваланучылар бар икән.

«КҮҢЕЛЕМДӘ – ТУРГАЙ ТАВЫШЫ»

Авылның ак әбисе – Роза Фәйзуллина белән дә якыннан таныштык. Авылның хөрмәткә лаек кешесе ул. Күпкырлы талант иясе, дисәм, төчерәк килеп чыгар кебек, әмма бу шулай. Авыл хатын-кызларын, балаларны дин сабакларына өйрәткән ул, бүген дә аннан башка авылда бер аш та узмый.

Роза апа шигырьләр дә яза. Узган ел «Күңелемдә – тургай тавышы» исемле китап бастырып чыгарган. Шигырьләре үзе кебек самими, эчкерсез. Җыентыкта туган ягына, авылына багышланган шигырьләре күп.

Моннан тыш, Зур Әтрәчнең остабикәсе «Кызыл миләш» исемле ансамбль дә оештырган. Лаеклы ялга чыккан авыл апалары һәр чарага аерым чыгыш әзерли – җырлыйлар, бииләр. Район күләмендә уздырыла торган бәйгеләрдә, бәйрәмнәргә дә еш баралар.

– Лаеклы ялга чыккач, бу кадәр тынгысыз тормыш булыр димәгән идем, – ди үзе Роза апа. – Бабаем – Ислам, мәчеттә имам булгач, мин дә дингә тартылдым. Акрын-акрын мәчеткә хатын-кызларны чакыра башладым. Рәхәт бер очрашуларга әйләнде ул. Бездә халык бик актив. Җыр-моңга да хирыс, берсе дә ялындырып тормый. Шуңа күрә очрашуларны мәчеттән тыш, авылның Мәдәният йортында да дәвам иттек.

Менә шулай «Кызыл миләш» ансамбле оеша. Ни кызганыч, артист апаларның барысы белән дә танышып булмады – 65 яшьтән өлкән кешеләргә бергә җыеларга киңәш ителми бит.

Роза апа белән шактый озак аралаштык. Китәргә җыенганда гына ул безгә ыргак белән эшләнгән матур урындык җәймәләре бирде. Бактың исә, ул әле бәйли дә икән!

– Тыныч кына телевизор карый алмыйм, – диде ул. – Кул тик торырга тиеш түгел.

– Гел бәйлисез ахры? – дим, капчыктагы җәймәләрнең күплегенә ишарәләп.

– Җәй көне бәйләмим, бакчадан бушап булмый. Көзгә кергәч, кулга ыргак алам. Бу җәймәләрне кыш буе бәйләдем.

– Ә нишләтәсез сез аларны? – дим.

– Бүләккә бирәм. Балалар, оныклар күп, Аллага шөкер. Кунакка барганда да күчтәнәчкә алып барам. Бәйләү миңа бик ошый. Шул вакытта илһам да килә – шигырь язам.

– Ярты гасыр гомер бергә узган бит, – диде Ислам абый. Роза апа да, бабаена елмаеп карап:
– Шигырь язарга утырганымны күрсә, комачауламас өчен, ишекләрне ябып куя.

Юнысовлар гаиләсе: алар гел икәү.

Роза апа безгә урындык җәймәләрен күрсәткәндә, Ислам абыйга күз салам. Гомер иткән хатынына ихлас бер елмаю, мәхәббәт белән карап торды ул.

– Ярты гасыр гомер бергә узган бит, – диде Ислам абый.

Роза апа да, бабаена елмаеп карап:

– Шигырь язарга утырганымны күрсә, комачауламас өчен, ишекләрне ябып куя. Сәхнәдә җырлап-биеп йөргәнемне дә ярата, бер сүз әйткәне юк. Бик аңлашып, бер-беребезгә карата хөрмәт белән яшәдек. Аллаһы Тәгалә безгә тигез картлык насыйп иткән, шуңа бик сөенәм.

ҖЫРЛАП ЯШӘҮ

Зур Әтрәчнең тагын бер гаиләсе турында сөйләми мөмкин түгел – Юнысовлар. Васыйл абый белән Мәрзия апа 29 ел бергә гомер итә икән. (Безне шаккатырган гармунчы Васыйл абый инде). Бергә дию бу очракта бик туры килә. Алар гел икәү: иртән-иртүк фермага бозаулар карарга китәләр. Кайткач, өйдәге мал-туарны ашаталар. (Хуҗалыкларында унлап баш мөгезле эре терлек бар). Җәй буе икәү бергә чиләк-чиләк җир җиләге җыйганнар, бакчада да бергә...

Гармунчы кешедән, әлбәттә, иң беренче бу шөгыле турында кызыксындык.

– Гармунда уйнарга кем өйрәтте? – дигәч, Васыйл абый болай дип җавап бирде:

– Миңа биш яшь булганда, апам кияүгә чыкты. Атлар җигеп, зурдан кубып туй уздырдылар. Яшь кияү, миңа инде җизни була бит, бик оста гармунда уйнады. Шул вакыттагы кызыгуларым... Бу турыда белгәч, җизни миңа үзенең иске гармунын бирде. Һәм яңа иске гармунда аз-азлап уйнарга өйрәндем. Үсмер чакта бик уйналмады, күрәсең, кызыксыну башкага булган. Соңрак бер туганыбыз үлде, аның гармуны бар иде. Шул гармунны миңа бирделәр. Һәм көн дә уйный башладым. Кырык биш яшемә үземә яңа гармун алдым. Бүген инде безнең өйдә баян, синтезатор да бар. Кайчакта төнге уникедә дә шуларда уйнап утырам. Илһам килсә, тиз генә китми.

Чынлап та, Васыйл абыйдан илһам тиз генә китмәде. Арттыру түгел, бер сәгать тирәсе безнең янда гармунда уйнап, җырлап торды ул. Тормыш иптәше Мәрзия апа иренә кушылып җырлады... Карап торырга бик күркәм күренеш!

Эш кешеләре турында сүз чыккач, шул теманы дәвам итү кирәктер. Зур Әтрәчтә тагын бер нәрсә сөендерде: җирләргә хуҗа бар, алар колхоз системасы буенча яшиләр. Күрше авыл егете Радик Нургалиев, колхоз таркалгач, эшне үз кулына алган. Нәтиҗәдә җирле халык эшсез калмаган. Монысы бер уңай ягы булса, икенчесе – авылда уза торган чараларга җитәкче даими рәвештә ярдәм итә икән.

...Зур Әтрәчтә көне буе йөреп тә, бер тамчы арылмады. Әле киресенчә, ниндидер бер көч тә җыеп кайттык. Моның сәбәбен төрлечә юрап карадык. Беренчедән, дүрт-биш чишмәнең суын эчтек. Алда әйтелгәнчә, аларның шифалы үзлекләре бар. (Авыл җирлеге башлыгы чишмә суын хәтта тикшерүгә дә алып барган. Һәм анда, чынлап та, организм өчен файдалы элементлар барлыгы ачыкланган). Икенчедән, җирле халыкның эчкерсезлеге җанга рәхәтлек бирде. Якын туганнар белән күрешкәндәй булдык. Өченчедән, авылның урыны тарихи. Заманча сүз белән әйтсәк, энергетикасы рәхәт. Менә шулар барысы бергә кушылып, безне ял иттерде булса кирәк. Сезгә дә, хөрмәтле укучыларыбыз, Зур Әтрәчкә барып, бу тарихи урыннарны күреп кайтырга киңәш итәбез. Үзегез белән савыт алырга да онытмагыз. Изге чишмә суының шифасын сез дә тоярсыз. Монысында шик юк...

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН:

Мөнир Вәлиев, борынгы Болгар дәүләте шәһәре Мең өйле Шонгатны торгызу Фонды директоры:

– Зур Әтрәч – бик борынгы авыл. Ул өч чорны колачлый: протоболгар чоры, болгар чоры, монгол чоры. 1552 елдан бүтән тарих белән яшәп китә. Без, көчебез җиткәнчә, авыл тарихында казындык. Чынлап та, безнең эрага кадәр үк шушы урында кешеләр яшәгән дияргә җирлек бар. Авылның борынгы исеме Әтрәч түгел, ә Мең өйле Шонгат. Аның исеме елга белән бәйле – Үләмә елгасы кушылдыгында Шонгат елгасы башлана. Шәһәрне шушы елга исеме белән йөрткәннәр. Аның Биләр, Болгарга караганда да зуррак икәне билгеле – 6 мең 500 йорты булган.

Әтрәч исеменең килеп чыгышы Болгар тарихы белән бәйле. Әтрәч – тәхәллүс. Болгарлар, сәрбиләр белән бергә, Төркиягә каршы сугыш алып баралар. Нәтиҗәдә Истамбул шәһәрен алалар. Истамбулдан ерак түгел Әтрәч исемле тау була. Менә шул тау итәгендә безнең борынгы бабалар җиңүне бәйрәм итә. Аннан кайткан сугышчылар бу исемне үзләре белән туган якларына алып кайта. Т



Алсу Троицкая:
Казан–Сөнчәле.

СОҢАРМАДЫК!

Ромашково паровозы турындагы иске матур совет мультфильмын хәтерлисезме? Артык яшь булганга яисә хәтерегез начарлануы аркасында хәтерләмисез икән, паровоз тарафыннан өч тапкыр әйтелгән төп фикерне җиткерәбез: «Әгәр без туктамасак һәм беренче сандугачны ишетмәсәк, без бөтен яз аена соңарачакбыз!» Әгәр беренче ландышларны күрмәсәк, бөтен җәйгә соңарачакбыз. Әгәр кояш баешына сокланмасак, бөтен гомеребезгә соңарачакбыз. «Чөнки һәрбер кояш баешы – тормышта бердәнбер».





Руфия Фазылова:
Казан–Болгар.



Татьяна Вафина:
Казан–Кама Тамагы.

Мультфильмның мәгънәсе «Татарстан»ның август кәефенә бик тә якын – туган яклар буйлап сәяхәт иткәндә, без, туктап, кояш баешына, таң атуга, кыңгыраулар һәм ромашкаларга сокландык, кошлар сайравын, чишмәләр чылтыравын тыңладык. Һәр сәяхәттән «Татарстан» журналистлары үзләренең тәэсирләрен алып кайтты – шулай итеп, тулы бер альбом – көнбагышлар альбомы барлыкка килде. Әгәр без көнбагышлар арасында фотоларга төшмәгән булсак, августка гына түгел, тулы бер елга соңарыр идек. Көнбагышлар елга бер генә тапкыр чәчәк ата бит.

Әмма без соңармадык! Чөнки кояшлы көнбагыш кырлары безне һәр борылышта, А пунктыннан Б пунктына баручы һәр маршрутта көтеп тора иде.

Александр Ефремов:
Казан–Мамадыш.

ТАССР

Празднование 100-летия
Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең
100 еллыгын бәйрәм итү

1920-2020

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 100 ЯШЬ